ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ
МӘГАРИФ, МӘДӘНИЯТ, ФӘН ҺӘМ МИЛЛИ МӘСЬӘЛӘЛӘР КОМИТЕТЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

КАЗАН ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ

КАЗАН ШӘҺӘРЕ ЯҢА САВИН РАЙОНЫНЫҢ «103 НЧЕ РУС-ТАТАР ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ



# Халык шагыйре Фәнис Яруллин иҗатына багышланган укучыларның һәм укытучыларның “Мин тормышка гашыйк” исемле II республика фәнни-гамәли конференциясе материаллары

Казан, 8 февраль, 2022 ел

УДК 821.512.145
ББК 83.3
Я78

Редколлегия: Хабибуллин Р.Н. – Казан шәһәре Яңа Савин районы “103 нче рус-татар урта гомуми белем бирү мәктәбе” директоры; Зиатдинова Н.В. – Казан шәһәре Яңа Савин районы “103 нче рус-татар урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең милли мәгариф һәм тәрбия буенча директор урынбасары; Хамидуллина Э.Х. – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты мәгариф идарәсенең Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары буенча бүлек башлыгы урынбасары; Ильясова И.М. – Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары буенча мәгълүмати-методик үзәкнең милли белем бирү буенча методисты

Фәнни мөхәррир: филология фәннәре кандидаты С.Г. Минһаҗева

Төзүчесе: Н.В. Зиатдинова

Я78 Халык шагыйре Фәнис Яруллин иҗатына багышланган укучыларның һәм укытучыларның “Мин тормышка гашыйк” исемле II республика фәнни-гамәли конференциясе материаллары (Казан, 8 февраль, 2022 ел) / төз.: Н.В. Зиатдинова. – Казан, 2022. – 75 б.

Конференция Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының “2021-2022 уку елына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының чаралар планын раслау турында”гы 13.08.20021 ел, № 1042/21 боерыгы белән расланган 2021-2022 уку елына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының календарь планын үтәү йөзеннән  һәм Ф.Яруллинның иҗади мирасын өйрәнү һәм пропагандалау, шулай ук сәләтле һәм талантлы яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итү, аларны тикшеренү һәм иҗат эшчәнлегенә җәлеп итү, укучыларның һәм укытучыларның милли мәдәниятнең рухи кыйммәтләренә җәлеп итү максатыннан үткәрелде.

Җыентыкта фәнни-гамәли эшләр тезислары һәм укучыларның үзләре иҗат иткән шигырьләре, шулай ук Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының (үзләре язган) шигырьләре һәм хикәяләре урын алды.

Материалларның эчтәлеге, фактларның дөреслеге өчен авторлар һәм фәнни җитәкчеләр җавап бирә.

Җыентык укучыларга, укытучыларга, югары уку йортлары студентларына һәм киң катлам әдәбият сөючеләргә адреслана.

# I. Фәнис Яруллиның шәхесе һәм иҗаты

## Татар әдәбиятын үстерүдә Фәнис Яруллин иҗатының роле

Ахметов Нияз, 8 нче сыйныф
Аксубай районының “Иске Ибрай урта мәктәбе”
Җитәкче: Ярмухаметова Р.В.

Фәнни эшемнең максаты: халык шагыйре Ф.Яруллинның иҗатын тулырак ачу, татар әдәбиятын үстерүдә аның иҗатының ролен төгәлрәк билгеләү.

Эшнең актуальлеге: Фәнис Яруллинның язмышы беркемнекенә дә охшамаган. Башта – мәктәп, аннары институт бетереп, үзенең хезмәт юлын газета яки журнал редакцияләрендә башлап җибәргән язучылардан аермалы буларак, ул әдәбиятка шактый ук тормыш тәҗрибәсе туплаган, зур фаҗигаләр кичерергә өлгергән шәхес буларак килеп керә. Ул беренче әсәрләрендә үк үзенең эчке дөньясын: шатлык-кайгыларын, сагыш-моңнарын, уй-гамьнәрен, җиңү-җиңелүләрен, яшермичә безгә ача. Ф.Яруллин җәмгыятьтә иң беренче шәхес булырга тиешлеген үз әсәрләре аша күрсәтә алды.

Төрле жанрларга караган әсәрләре Ф.Яруллинның эзләнү һәм табышларын гына түгел, бәлки әдипнең яңарыш чоры татар әдәбиятында тоткан урынын тулырак ачыклау ягыннан да игътибарга лаеклы.

Ф.Яруллин әсәрләрен һичбер авторныкы белән бутап булмый. Теленең байлыгы, сыгылмалылыгы, әсәрләрдә буш җөмләләрнең булмавы, иң тирән кичерешләрне дә гади һәм аңлаешлы итеп ача белүе, тормыш проблемаларын күтәрүдәге новаторлык - болар барысы да аның олы язучы, шәхес икәнен раслый. Кайбер язучылар гади генә вакыйганы да катлауландырып бирергә яраталар. Ф.Яруллин исә, киресенчә, катлаулы вакыйгаларны, тирән фикерләрне халык бер укуда тотып алырлык, аңларлык итеп яза. Аның талант үзенчәлеге дә шундадыр, мөгаен.

Фәнни–тикшеренү эше барышында максатыма ирештем дип уйлыйм. Татар халкының горурлыгы – Фәнис Яруллин иҗаты турында билгелекүләм материал тупланды.

Әдипнең шигърияттен, прозасын, драматургиясен һәм балалар әдәбиятын тикшергәннән соң, йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: аның үзенчәлеге тирәнтен фикер йөртә, гап-гади тоелган тормышыбызда бик күп матурлыклар, катлаулы вакыйгаларны чын рәссам каләме белән сурәтләп бирә белүдә; гыйбрәтле вакыйгаларны, тетрәндергеч язмышларны, беренче карашка сәер күренгән кешеләрне әсәрләренә герой итеп алып, чын сәнгать әсәрләре тудырды. Аның иҗаты татар әдәбиятында үз урынын, үз укучысын тапты.

## Фәнис Яруллинның әкиятләрендә уңай һәм тискәре геройлар

Ахтямова Ильвина, 4 нче сыйныф
Казан шәһәренең “175 нче гимназиясе”
Җитәкчеләр: Әхтәмова Г.М., Зарипова А.А.

Мин әкиятләр укырга бик яратам. Уку дәресләрендә халык авыз иҗаты әкиятләрен дә, автор әкиятләрен дә укыдык. Андагы мавыктыргыч, серле, тылсымлы вакыйгалар мине кызыксындырды. Өстәмә рәвештә әкиятләр укуны дәвам иттем. Шуңа күрә бу тема бик якын, шуңа күрә фәнни эшемне дә “Фәнис Яруллин әкиятләрендә уңай һәм тискәре геройлар” дип билгеләдем.

Гипотеза: Фәнис Яруллин әкиятләрендәге уңай геройлар һәрвакыт яхшылык эшләргә сәләтле. Тискәре геройлар һәрвакыт начарлык кына эшли.

Максатым: Фәнис Яруллинның “Зәңгәр күлдә Ай коена”, “Алабай белән Соры”, “Алсу чәчәк” әкиятләрендәге уңай һәм тискәре геройларны табу.

Максаттан чыгып, мин үз алдыма түбәндәге бурычларны куйдым: бу әкиятләрне уку; уңай һәм тискәре геройларны аерып күрсәтә белү;нәтиҗәләр ясап, үз фикеремне белдерү.

Методлар, ысуллар: өлешчә анализ;чагыштыру; әсәрләр арасында уртаклык; йомгак.

Өйрәнү объекты һәм предметы: Фәнис Яруллинның әкиятләре.

Фәнни эшнең структурасы: кереш, төп өлеш, йомгаклау өлешләреннән һәм әдәбият исемлегеннән тора.

Фәнни-тикшеренү эшен башкарганда, авторның "Серле дөнья"китабын, интернет ресурсларын, "Татар теленең аңлатмалы сүзлек" китабын кулландым.

Теманың актуальлеге. Бүгенге көндә дә яхшылык эшли белү кебек сыйфат бик актуаль. Фәнис Яруллин әкиятләрендә нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнлеген аңлау алгы планда тора. Автор баланы яхшы гамәлләр эшләргә, мохтаҗларга ярдәм итәргә, ачык күңелле ярдәмчел булырга, начар эшләрдән ерак торырга өнди.

Фәнни эшне башкарганда, куелган гипотеза ачыкланды. Әйе, чыннан да, Фәнис Яруллин әкиятләрендәге уңай геройлар бары тик яхшылык кына эшли дигән нәтиҗә ясый алабыз. Ә тискәре геройлар бары тик начарлык эшләргә омтылуын Бака, Чуртан, Аждаһа, Соры образлары ярдәмендә күрдек.

Һәрвакыт яхшылык яманлыкны җиңә. "Яхшылык эшлә дә, суга сал", "Яхшылыкны хайван да онытмый", – дигән татар халык мәкальләре. Без яхшылык эшләргә омтылырга тиеш.

## Әкият ул тылсым яки хыял дөньясы гына түгел

Ашит Диләрә, 5 нче сыйныф
Казан шәһәренең "Ф.Г.Аитова исемендәге 12 нче татар гимназиясе"
Җитәкче: Насыйбуллина Г.З.

Әкият тылсым яки хыял дөньясы гына түгел",– дип язган иде Мәхмүт Әхмәтҗанов "Шәһри Казан" газетасының бер санында. Моңа өстәп, "Әкият ул – могҗизалар кыры ", дип тә әйтәсем килә. Чөнки әкиятче барлык матур уй - хыялларын, өметләрен, максатларын әкияткә нигез итеп ала, шуны балалар дөньясына гына түгел, олылар күңеленә дә орлык итеп салып куя. Без Фәнис абый Яруллинның иҗатын гаделлек юлыннан киләчәккә ышанып бару өчен балаларга канат була ала торган иҗатка тиңлибез.

Язучы иҗатының башлангыч чорында ук балалар әдәбиятына "баласытып" карамаган. Балалар өчен нинди генә генә жанрда иҗат итмәсен, сокландыргыч әсәрләр тудырган. Аның балалар өчен язылган әкиятләре – шуның бер үрнәге. Бу әкиятләр балаларның хыялын кузгата, аларның серле күңел сандыгына ачкыч таба. Чөнки алар балалар рухына, аларның табигатенә туры килердәй итеп язылган, балаларга таныш тормыштан алынган, халык иҗатындагыча гади, җыйнак, поэтик бизәкләргә бай.

Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Республикабызның халык шагыйре Фәнис абый Яруллин иҗаты белән танышкач, безнең күз алдына иксез-чиксез диңгез килеп баса. Шул диңгезнең төбендә ул иҗат иткән шигырьләр дә, проза һәм драма әсәрләре дә, әлбәттә, без яшь балаларны гына түгел, өлкәннәрне дә үзенә җәлеп иткән, әдәп һәм әхлак тәртипләренә өйрәткән әкиятләре дә көмеш ай кебек ялтырап ята. Без, балалар, "тегеләй эшләмә", "болай уйларга ярамый" дигән өлкәннәр сүзләрен колак яныннан гына уздырабыз. Ә менә гыйбрәтле әкиятләрне укыгач, алар эчтәлегеннән чыгып, нәрсә яхшы, нәрсәнең начар икәнлегенә төпләп төшенәбез.

Фәнис абый Яруллинның балалар өчен язылган әкиятләренә күз салсаң, алардагы философиягә, мавыктыргыч сюжетка, теленең сыгылмалыгына, тәмамлау өлешендәге көтелмәгән борылышларына сокланмый кала алмыйсың.

Автор "Йолдыз тапкан кыз" әкияте белән безгә масайма, тәкәбберләнмә, үзеңне башкалардан өстен куйма, байлыкка омтылма, байлык ул – беркөнлек, гадилектә – матурлык дигән гыйбрәтле фикерләрен җиткерә. Сюжет сызыгына салынган капма-каршы ике вакыйга

безне, ягъни балаларны, яшәү кануннарына өйрәтә, явызлыкның һәрвакыт явызлык булып кайтасына төшендерә.

“Яралы торна” әкиятенең башлам өлешендәге торналарны озатудагы матур моңсулык әкренләп күңел тетрәндергеч моңсулыкка әйләнә. Бу моңсулыкта яралы торна сагышы да, иптәшләренең аны югалту хәсрәте дә, кешеләрнең явызлыгына протест хисләре дә бергә тупланып, укучы күңелен айкый. Матурлыкка кул сузучыларның җәзалануын тели. Матурлыкның явызлыкны җиңә алуын исбатлаучы бу әкияттә без торналар мисалында бердәмлек, бер - берең турында кайгырта белү сыйфатларын да күрәбез.

Югарыда карап үтелгән әкиятләрдә Ф. Яруллин иң мөһим нәрсә итеп физик көчне түгел, әхлакый сафлыкны, намусны һәм вөҗданлылыкны куя.

Ә менә Фәнис абыйның “Тылсымлы ачкыч” әкиятен баланың фикерләү сәләтен үстерергә, телебез байлыгының тирәнлегенә төшенергә, баланың акылын үстерү өчен язылган дияргә була.

Фәнис Яруллинның әкиятләр китабын укып чыккач, шундый фикер туа: әдипнең әкиятләрен теләсә нинди телгә тәрҗемә итәргә мөмкин, чөнки аларны яратып укыячаклар. Фәнис Яруллинга халыкара Андерсен бүләген бирергә дә мөмкин булгандыр. Ул моңа тулынча лаек булган.

## Фәнис Яруллин шигырьләренә язылган җырлар

Басырова Гүзәл, 8 нче сыйныф
Казан шәһәренең “170 нче мәктәбе”
Җитәкче: Гарипова И.Р.

Шагыйрь Фәнис Яруллин үзенең бер анкетасында җыр текстлары турындагы сорауга аларның төп таләбе итеп сюжетлыкны, образларның гади булырга тиешлеген әйтә. Аның фикеренчә, җырның төп вазыйфасы җанны тетрәндерү, кешене тирән уйларга салу, битарафлыктан чыгару. Дөрес, дәртне кузгатучы, борчу-мәшәкатьләрне күпмедер вакытка онытырып торучы шаян җырлар да бар, ди ул. Миңа калса, Ф. Яруллинның шигырьләре үзе куйган таләпләрне үти: сюжетлык бар, образлары гади. Фәнис Яруллин шигырьләренә иҗат ителгән җырлар тирән фикерле, матур, көйләнеп тора. Тиз отып алырдай, тиз хәтергә керердәй булуы да җырның төп үзенчәлекләренә карый.

Поэзиядә Фәнис Яруллинның төп жанры – лирика. Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасы – киң офыклы, тирән фәлсәфәле, халык иҗатына хас нечкә юморлы лирика. Аның шигырьләрен укыгач, хәтта кәефсез йөргәннәрнең дә күңеле күтәрелеп китәдер кебек, ничектер эштән гамь тапмаганнар да кисәк кенә аннан тәм, ләззәт таба башлыйдыр төсле тоела. Татар халкы элек-электән җыр-моңга бик хирыс булган. Иң каты бәгырьлеләрне дә елатырга, нечкәртергә сәләтле ул җыр. Ф.Яруллин: “Матур җыр ул, көчле дару кебек, йөрәкләргә үтә туп-туры...” – ди.

Болар арасында иң популяр җырны ачыклыйсым килде. Барлык җырларын да халык бик яратып тыңлый, башкара, чөнки алар интернет челтәрендә берничә тапкыр урнаштырылганнар. Шулар арасында үзе исән чакта ук киләчәк буыннарга күчәрдәй үлемсез җыры бар. Казан хастаханәсендә ятканда, Ф.Яруллин урта мәктәпне тәмамлый. Бу үрләрне яулауда, аңа укытучыларның ярдәме зур була. Аларга багышлап ,ул “Иң гүзәл кеше икәнсез” дигән шигырен иҗат итә. Аңа композитор Әхмәт Хәйретдинов көй яза. Халыкка бу җырны Миңгол Галиев ирештерә.

Бүгенге көндә радио һәм телевидение аша бик еш Фәнис Яруллинның җырларын ишетәбез. Әлеге җырлар гади телдә язылгангамы, күңелләрне күтәрә, җанга нindидер бер җиңеллек, рәхәтлек бирә. Бигрәк тә мәхәббәт темасына язылганнары табигать күренешләре белән үрелеп бара. Хис белән биеклеккә омтылыш сизелсә дә, Фәнис Яруллин геройлары җирдән аерылып китергә ашыкмыйлар.

# Фәнис Яруллинның “Кыйгак-кыйгак каз кычкыра” әсәренә анализ

Басырова Эльмира, 10 нчы сыйныф
Казан шәһәренең “182 нче политехник лицее”
Җитәкчеләр: Гатауллина А.С., НизамоваЛ.К.

Фәнис Яруллин укучыларны күп еллар буена иҗат җимешләре белән сөендереп яшәде. Ул – күп санлы шигырьләр, повесть-хикәяләр, драмалар һәм матур-матур әкиятләр авторы. Бу олы әдип иҗатында гына түгел, тормыш-яшәешендә дә гаять үзенчәлекле, көчле шәхес. Билгеле булганча, армиядә хезмәт иткәндә, 20 яшьлек чагында Фәнис абый бәхетсезлеккә юлыга, шуның аркасында аяк-куллары йөрмәс була. Хастаханәләрдә, госпитальләрдә дәвалана, операцияләр кичерә, тик файдасы тими. Ул урында яткан килеш, хәрәкәтсез бармаклар белән әкрен-әкрен генә яза башлый һәм иҗат сихеренә бирелә. Фәнис Яруллин әсәрләре туры мәгънәсендә тырышып-тырмашып язылганнар һәм һәркайсыннан җан җылысы бөркелеп тора. М.Вәлиев аның иҗаты турында болай ди:

«Аның кайсы гына әсәрен алып карасаң да – ул тыгыз итеп, хис- кичерешләрне гаять киеренке итеп тасвир кылып язылган булыр. Анда артык эпизодлар ,артык персонажлар да очратмыйсың – шул ук вакытта барысы да гади генә,бик тә гадәти генә тасвир кылына”.

Әлеге хезмәттә без язучының “Кыйгак-кыйгак каз кычкыра”повестена тулы анализ ясадык. Әсәр үзенең темасы, проблемасы белән бик үзенчәлекле. Әйтергә кирәк,татар әдәбиятында мондый вакыйгаларны яктырткан әсәр күренгәне юк иде әле. « Кыйгак-кыйгак каз кычкыра» повестенда Ф.Яруллин бик җитди мәсьәлә кузгата. Әсәрдәге вакыйгалар сугыш чорында башланып китә. Әмма автор күтәргән проблема бүген дә зур әһәмияткә ия. Бу мәсьләгә кагылган икән, димәк, ул язучының җанын тынгысызлый, аңа битараф кала алмый.

Әлеге әсәрендә Ф.Яруллин сугыш чоры хатын-кызларының авыр язмышын сурәтли. Моны Сәхия образы аркылы гына тасвирламый ул. Сәкинә, Мәгъдәнияләр дә тормышларында бәхет тапмыйлар. Мәгъдәния көн-төн эш артыннан чаба, бу аның фаҗигале үлеменә китерә. Сәкинә дә үз гомерендә аз гына бәхет тә күрми. Ирсез генә бала табып, күке сыман аларны ташлап калдыра, ялгызы картая.

Темага бәйләп, Ф.Яруллин төрле проблемалар күтәрә. Хәзерге кешеләрнең еш кына халык әхлагы кануннарыннан читләшүләре шунлыктан, рухи яктан зәгыйфьләнүләрен күрсәтергә тели. Сәкинә һәм Сәхия халык традицияләреннән аерылган, шуңа күрә сынаулар алдында каушап калалар, рухи көч таба алмыйча җиңеләләр. Чын күңеле белән Аллаһга табынучы, гөнаһтан куркучы Зәйнәп әби кызларны дөрес юлдан тайпылмаска өнди, булдыра алганча ярдәм итә. Әмма бу ярдәм генә аз, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен тулаем үзгәртергә, бер-береңә ышанырга, башкаларны рәнҗетмәскә өйрәнергә кирәк.

Хатын-кыз язмышын сурәтләгән әсәрләр татар әдәбиятында аз түгел. Әмма «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра» повесте кузгатылган проблемасы, аның хәл ителеше белән бик үзенчәлекле. Чынлап та, хатын-кызның тормыш йөген сөйри-сөйри дөнья баткаклыгына кереп батуы, ирләр белән тигезләшәм дип, нәфислеген, гүзәллеген җуюы, шуның нәтиҗәсендә дуадак каздай ялгыз калуы җәмгыятебезгә ят күренеш түгел. Хатын-кыз ул дөнья авырлыгын күтәрүче түгел, гаилә учагын саклаучы, киләчәк буын калдыручы бит. Моның өчен аңа бөтен шартлар тудырылырга тиеш дигән идеяне алга сөрә язучы. Ф.Яруллин әсәрләренә хас үзенчәлек – аларның тирән мәгънәле, үткен фикерле булулары. Бу сыйфат «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра» повестен дә читләтеп үтми. Кеше төрле авырлыклардан чыгу юлын эзләргә, табарга тиеш. Сәхия моны яшьли дуамалланып йөргәндә түгел, олыгаеп нигезенә кайтып егылгач кына аңлый һәм бәхетенә юл ала.

## Фәнис Яруллин шигъриятендә яшәеш фәлсәфәсе

Галәветдинова Рузия, 9 нчы сыйныф
Яңа Чишмә районының "Шахмай урта мәктәбе"
Җитәкче: Гыйльманова К.К.

Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, республикабызның Халык шагыйре Фәнис Яруллинның иҗаты күпкырлы. Ул шагыйрь дә, прозаик та, драматург та, әкиятләр остасы да һәм ялкынлы публицист та. Иҗатының кайсы ягын гына алып карама, аның дөньяга, яшәешкә үзенә генә хас фәлсәфи карашын, җәмгыятьтә бара торган процессларга мөнәсәбәтен күрәсең. Шуларны күзләп, шагыйрьнең иҗат сумкаларын барларга һәм фәнни эш эшләргә уйладым.

Эшебезнең төп максаты - Фәнис Яруллинның фәлсәфи характердагы метафизик уйлануларын чагылдырган әсәрләрен уку һәм шул нигездә куелган сорауларга җавап эзләү.

Әлеге максатка ирешүдә түбәндәге бурычларны үтәү күздә тотылды:

1. XX нче гасырның 60-70 нче елларында Ф.Яруллин игътибарын күбрәк җәлеп иткән тышкы дөнья сурәте тасвирланган шигырьләренә күзәтү ясау.
2. 4 нче томга кергән шигырьләрен уку, Инсан һәм Яшәеш арасындагы каршылыкны табу, анализлау;
3. Ф.Яруллинның фәлсәфи идеяләре белән сугарылган шигырьләрен уку һәм анализлау.

Тикшеренү объекты итеп шагыйрьнең фәлсәфи характердагы метафизик уйлануларын чагылдырган әсәрләре алынды. Анализ өчен Ф.Яруллинның биш томнан торган сайланма әсәрләр җыентыгының (2004) дүртенче томына кергән лирик әсәрләрен алдык.

Фәнни-тикшеренү эшен башкарганда тикшеренү, эзләнү, чагыштыру, гомумиләштерү, күзәтү, нәтиҗә ясау алымнары һәм ысулларын кулландык.

Ф.Яруллин шигърияте – һәр сүзен зәвык белән хисси, фәлсәфи һәм иҗтимагый яссылыкка салып үлчәнгән лирика. Әсәрләре шагыйрь шәхесен дистәләрчә каләм иясе арасында индивидуаль иткән сыйфатлардан тукылган.

Ф.Яруллин шигырьләре стилистик гадилеге, милли образлар һәм мотивларга еш мөрәҗәгать итүе игътибарны Инсан һәм Яшәеш арасындагы каршылыкны бәйләнешкә ныграк юнәлтергә ярдәм итә. XX нче гасырның 60-70 нче елларында Ф.Яруллин игътибарын күбрәк тышкы дөнья сурәте биләгән, үз язмышының укучы-халык язмышында, күңелендә эзсез калмавын, аерым урын биләвен тоюдан туган хисләр алып торган булса, соңрак язган шигырьләрендә тормыш-Яшәешнең мәгънәсе, асылы чагылыш таба.

Ф.Яруллинның һәрбер шигыре бер-берсе белән фәлсәфи яктан тыгыз үрелгән, алар мозаик панноның әһәмиятле өлешләре кебек. Аның иҗатында Инсанның бөеклеге, Язмышның мәһабәт катгыйлыгы, бердәнберлеге, тормышның эчке каршылыклардан гына торуы мотивлары алга чыга.

Ф.Яруллинның фәлсәфи идеяләре тормыш хакыйкатен тулы ача: Яшәеш ул - бертуктаусыз аккан, күпкатлы, катлаулы күренеш. Теге яки бу шигырен тудырганда, автор укучыны өйрәтү яки аңа акыл сату максатын куймый, ничек яшәргә кирәгенә артык басым ясамый. Ул, нигездә, адәм баласы туу белән үк Яшәеш диңгезенә, «карурман»ына эләгеп, анда үз юлын табарга тиешлекне, югалмас, изелмәс өчен көрәш алып барырга мәҗбүрлекне ассызыклап бара. Димәк, шагыйрь концепциясендә Яшәеш - җан-рух һичшиксез үтәргә тиешле бер сынау, мәҗбүрият.

Ф.Яруллин поэзиясендә чагылыш тапкан фәлсәфи идеяләрне өйрәнү шундый нәтиҗәләргә китерде: аның фикер офыклары имплицит рәвештә милли мотивларга һәм ислам дине өйрәтмәләренә таяна. Беренче карашка ул әйткән фикерләр дөньялык белән бәйле һәм артык гомуми булып күренсәләр дә, үзе дә кешеләрнең көнкүреш хәятыннан образлар «чүпләсә» дә, фәлсәфилек яссылыгы барлык әсәрләренең яшерен агымы булып кала бирә. Бу хасият – аның шигъриятенең ныклы, тирәндә яткан нигез агымы.

## Фәнис Яруллин иҗатында бала холкын күрсәткән юмор һәм сатира

Ганиев Әмир, 8 нче сыйныф
Казан шәһәренең “113 нче татар-рус мәктәбе”
Җитәкче: Хасанова И.А.

Фәнис абый Яруллинның балалар әдәбиятына керткән зур өлешен әйтми калу мөмкин түгел. Чөнки аның иҗат җимешләре нәни укучыларны көлдерергә һәм уйланырга мәҗбүр итә. Әкиятләр яки балалар өчен язылган поэмалар дисеңме, шуклыкка – җорлыкка корылган шигырьләр дисеңме – боларның һәркайсында олы фикер, саф әхлак һәм матурлыкка омтылу ята.

Әлеге эшемдә мин балаларның күңел дөньясын бөтен матурлыгы белән ачып салган шигырьләрен тәкъдим итәсем килә. Аларның һәммәсе әхлаклы бала тәрбияләү максатын күздә тота.

“Ялкау ялы” шигырендә Фәнис абый Яруллин энемнең вакытны ничек үткәрү турында күз аллавын күрсәтә:

Әти әйтә: «Әй, улым,
Бигрәк әллә нинди син.
Эш турында әйтмим дә,
Ял итә дә белмисең».
Ял итәргә аңарга
Нинди белү кирәктер?!.....

Әлбәттә, әлеге шигырь юлларын укыгач, ирексездән, йөздә елмаю барлыкка килә. Бала үзенә бирелгән буш вакытны ничек файдалы итеп үткәрәсен белми. Моннан тыш, ул гаиләдәге өлкәннәрнең сүзенә дә колак салмый. Шигырьнең ахыргы юлларында баланың әлеге ялкаулык халәте үзен дә ардыра башлавын күрәбез. Фәнис Яруллин әлеге юмористик шигыре аркылы балаларны вакытның кадерен белеп, үзеңә файдалы һәм кызыклы итеп үткәрергә өнди.

“Бәби кемгә охшаган?” шигырендә балалар самимилеге һәм беркатлылыгы сурәтләнгән. Гаиләдә тагын бер нарасый барлыкка килү, күпчелек балалар өчен көтелмәгән хәл буларак кабул ителә. Әти-әни яратуын бүлә алмау, балаларда бер-берсенә карата самими көнчелек туа. Бу хәл миндә дә күзәтелде. Энемне өйгә алып кайткач, туган сорауларга җавапны, мин әлеге шигырьдә таптым. Шигырь юлларының беренче өлешендә, бала энисенең бәби алып кайтуын һәм үзенә булган мөнәсәбәтнең бераз үзгәрүен ачып сала. “Юк өчен тиргәүләр” балага ошап бетми, әлбәттә. Ә “бала кемгә охшаган?” дигән сорауга ул гади генә “бабайга” дип җавап кайтара.

Әлеге проблема беркайчан актуальлеген югалтмый. “Сүзсез генә” шигыре моңа ачык мисал булып тора. Баланың шәхес булып формалашуында җәмгыять, андагы үзгәрешләр, баланы чолгап алган тирәлекнең, аралашкан кешеләрнең тәэсире бик зур. Яшь буынга дөрес юнәлеш бирү, аны төрле тискәре йогынтылардан саклап калу – мәктәп белән ата-ананың бердәм бурычы.

Билгеле булганча, һәр әдип үзенең мөмкинлекләрен ачар өчен төрле формалар эзли. Фәнис Ярулин иҗаты да яңа төсмерләр белән байый. Аның шигырьләрендә тирән лирика белән бергә юмор аерым бер агым булып килеп керә.

Авторның тормыштан кызыклы, көлкеле вакыйгалар эзләве, бер яктан, стиль үзенчәлекләрен яңартып җибәрә. Икенче яктан, автор, вакытлыча гына булса да, фантазиягә бирелеп, үз фаҗигасеннән котылып тора кебек. Шундый авыр хәлдә кешеләрне елмайта, көлдерә алырлык әсәрләр язу – үзе батырлык.

Безнең халкыбыз Фәнис абый кебек көчле рухлы кешеләре белән горурланып яшәргә, аларны хәтереннән мәңге җуймыйча, күңел битләрендә сакларга бурычлы.

Фәнни эшемне “Мин тормышны сөям” шигъри юллары белән тәмамлыйсым килә:

Мин тормышны сөям, сабый бала

Үз әнкәсен сөйгән шикелле.
Никадәрле газап кичерсәм дә,
Ул һаман да матур, сөйкемле.

## Фәнис Яруллинның “Әнә килә автомобиль” әсәрендә юмор һәм сатира бирелеше

Гарипов Вильдан, 9 нчы сыйныф,
Казан шәһәренең “7 нче лицей-интернаты”
Җитәкче: Мансуров А.И.

Фәнис Яруллинның пьесалары жанр төрлелеге белән аерылып тора. Алар арасында комедия, драма, хәтта трагедия дә бар. Пьесаларының күпчелек өлешен комедияләр тәшкил итүе, аларның үзенчәлекле төзелешкә ия булуы, безне шушы эзләнүләргә этәрде дә. Авторның «Әнә килә автомобиль», «Кызларның кызганнары» (1997), «Бер күрешү – үзе бер гомер» (1996), «Койрыксыз сандугач» (1987), «Сөембикә егет сайлый» (1989) һ.б комедияләре сәхнәдә уңыш белән барды. Автор үзе: “...Юмор һәм сатирик шигырьләремдә тормышыбызда адым саен очрап торган кимчелекле якларны күреп, шуларны образлылык призмасы аша бер фокуска туплап бирү ята,” – дип бәяли поэзия өлкәсендәге эшчәнлеген. Бу үзенчәлек аның драмаларында да чагылыш таба.

Фәнни эшебезнең максаты булып, Фәнис Яруллинның драматургиясен жанр үзенчәлеге ягыннан тикшереп бәяләү тора. Авторның комедияләре һич тә бертөрле генә түгел. Аларда көлке тудыру алымнары нигездә бер төсле булса да, һәр әсәр үзенчәлекле ягы белән аерылып тора. Шулай да безне иң кызыксындырганы “Әнә килә автомобиль” әсәре булды.

Драма әсәре сәхнәдә генә тулысынча ачыла, үзенең эчке көчен күрсәтә ала дип санала. Бу яктан комедиянең язмышы бик тә гыйбрәтле. Әсәрнең ике варианты билгеле. Башта аны Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «Әнә килә автомобиль» исеме астында танылган режиссёр М. Сәлимҗанов сәхнәләштерә. Соңрак ул «Менә килә автомобиль» буларак К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсенә күтәрелә.

Беренчесендә сатира өстенлек итсә, икенчесендә лиризм көчәя. Бу әсәрне сәхнәләштергән режиссёрларның эчке халәтенә, дөньяга карашларына гына бәйле.

Комедия асылда шул көлү икәнен аңладык инде. Ә көлү – тәнкыйтьнең иң көчле чарасы, коралы. Ләкин бер каршылык бар. «Юмор йомшак, яратып көлү була. Ул фаш итми, ул җиңелчә шаярту, елмаю, шуклык белән чикләнә, якын шаян мөнәсәбәтне белдерә». Ә Фәнис Яруллин үзе мондый фикердә тора: «Юморымның характерлы ягы – йомшак көлү, – ди ул. – Үз геройларымның җитешсез, йомшак якларын сурәтләгәндә, кешенең йөзенә пычрак атып түгел, киресенчә, адәм баласын рәнҗетмәслек итеп, ягымлырак әйтергә тырышам». Димәк, юмор тискәре күренешне, тискәре сыйфатны фаш итә алмый. Бу функцияне бары тик сатира гына башкара ала. Сатира – ачы, үткен көлү, тискәре якларга басым ясау, аларны фаш итүме? Әсәрнең жанрын билгеләүдәге каршылык нидән туа? Шуны ачыкларга тырышып карыйк.

“Әнә килә автомобиль”нең жанрын сатирик комедия дип билгеләү дөрес булмас. Чөнки автор аерым сыйфатларны җыеп, үстереп, геройны фаш итми, җиңелчә көлү белән генә чикләнә. Әлеге пьеса – көнкүреш комедиясе. Дөрес, биредә водевильга хас сыйфатлар да бар. Чөнки ул кискен борылышларга, адаштыруларга нигезләнгән. Шаяртудан, уенкөлкедән төзелгән. Пьесаның асылында исә, җәмгыятьтәге тайпылышларның норма булып калырга тырышуы ята. Мондый каршылык, норма белән тайпылышның бәрелеше, комедиячел ситуация тудыра. “Әнә килә автомобиль”дә генә түгел, Ф. Яруллинның без тикшергән башка комендияләрендә дә бу үзенчәлек күзәтелә. Автор мондый алымны киң файдаланса да, көлкеле хәлләр тудырганда, башка төрле чаралардан да актив куллана. Кызы-

клы чагыштырулар, предмет-күренешләрне янәшә куеп сурәтләү, гипербола, персонажларның сөйләм үзенчәлеге, җор теллелеге, шул чорга хас типик күренешләргә киная һ.б. “Әнә килә автомобиль” пьесасында юмор тудырырга ярдәм итүче шундый чараларның берничәсе.

## Фәнис Яруллинның ярдәмчеләре

Гарифуллина Азалия, 7 нче сыйныф
Казан шәһәренең “13 нче рус-татар мәктәбе”
Җитәкче: Губайдуллина Ф.Р.

Армия фаҗигасеннән соң ятакка береккән хәлдә, түшенкелеккә бирелмичә, сәнгатьлелекнең югары дәрәҗәсендә торган ялкынлы әдәби әсәрләрен иҗат итүче каһарман шагыйребез Фәнис Яруллин.

Фәнис Яруллинга әлеге бөеклекләр яуларга кемнәр ярдәм иткән соң? Алар шагыйрь турында нинди фикердә? Шушы сораулар миңа фәнни-тикшеренү эше белән шөгыльләнергә этәргеч ясадылар.

Фәнни-тикшеренү эшемнең максаты: Ф. Яруллинга таяныч булган кешеләрне табу һәм аларның әдип турында әйткән фикерләрен ачыклау.

Бурычлар:

1.Ф. Яруллинга язган хатлар белән танышу.

2.Автограф язып бирелгән китаплардагы теләкләргә күзәтү ясау.

3. Ф. Яруллинның М.Шабаев, Т.Миңнуллин, Г.Зәйнашевалар белән булган мөнәсәбәтләре турында мәгълүмат туплау.

Алга куелган максат һәм бурычларга төрле белешмәләрдән, җыентыклардан алган мәгълүматларны анализлау методы белән ирешелде. Фәнни эшне Ф.Яруллинга таяныч булган кешеләр белән бәйләүнең сәбәбе: шагыйрь турында тагын да күбрәк мәгълүмат туплау. Сайланган теманың актуальлелеге: Ф.Яруллинның иҗаты күпмедер дәрәҗәдә дәреслектә урын алган, ә аңа таяныч булган кешеләр турында мәгълүмат бирелмәгән. Фәнни эшнең яңалыгы: Ф.Яруллин иҗатын гына түгел, ә аның турында әйтелгән фикерләрне, аңа ярдәм кулы сузучыларны белү.

Әлеге максатка ирешү өчен мин Фәнис Яруллинның “Сөенечләр бүлешү”, “Хәтер төпләрендә утлы күмер” китаплары белән танышып чыктым. Шулай ук, Гөлчәчәк Галиеваның “Күңелемә якын затлар” китабы да ярдәм итте.

Мин яраткан шагыйребез, язучыбыз, драматургыбызга ярдәм кулы сузган, файдалы киңәшләрен биргән барлык шәхесләргә дә тукталып китмәдем. Алар бик күп. Минем тукталган шәхесләрем өчәү булды: Марс Шабаев, Туфан Миңнуллин, Гөлшат Зәйнашева.

Марс Шабаев Фәнис Яруллинга иң беренче ярдәм итүче, дөрес юл күрсәтүче булган. Коточкыч авыртуларны онытырырга, дәвалауны Казанда оештырырга, түшенкелеккә бирелмәскә ярдәм итә. Укучыларны, беренчеләрдән булып, булачак бөек шагыйрь белән таныштыра. Ә Туфан Миңнуллин Ф.Яруллинга драматург булып үсеп китәргә ярдәм итә, драма әсәрләрен язу серләренә төшендерә. Һәрвакыт аның күңелен үстерә. Гөлшат Зәйнашева, Фәнис абый авылда ятканда ук, хатлар язып, шигырь язу нечкәлекләренә өйрәтә. Аның хаталарын күрсәтә, булачак шагыйрь белән бик җылы мөнәсәбәттә була. Аның уңышларына чын күңелдән сөенә.

Шулай итеп, мин Ф.Яруллинның М.Шабаев, Т.Миңнуллин, Г.Зәйнашевалар белән булган мөнәсәбәтләрен ачыкладым.

## Әдип иҗатында юмор һәм сатира

Гатауллина Кәмилә, 7 нче сыйныф

Әлки районының “Иске Чаллы төп мәктәбе”
Җитәкче: Әхмәтшина Л.Т.

Фәнни-тикшеренү эше Татарстанның халык шагыйре, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, М. Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты, шагыйрь, язучы, драматург Фәнис Яруллин иҗатын тирәнтен өйрәнү һәм аның иҗатында сатира һәм юмор темасының чагылышын күзәтү максатыннан чыгып башкарылды. Сайлап алынган тема бүгенге көндә дә бик актуаль. Куелган максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычларны чишү сорала:

1. Фәнис Яруллин әсәрләре белән танышу.
2. Әдип иҗатында сатира һәм юмор темасының чагылышын күзәтү һәм ачыклау.

Тикшерү өчен Ф.Яруллинның “Керербез янган утка “ (1978), “Әби килде авылдан” (1978), “Докторда” (1989), “Мөнипнең дәфтәре” (1965) шигырьләре алынды.

Шагыйрь үзенең шигырьләре аша укучыларны тәрбияли. Аның шигырьләре юмор һәм сатирага корылган. Язучы тормышның матурлыгын күрә белергә, дөреслекне ялганнан аера белергә өйрәтә. Ә бүгенге көндә бу бик мөһим мәсьәлә булып тора. Ул үзенең шигырьләрендә өлкәннәр белән балалар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, сабыйлар дөньясындагы проблемаларны күрсәтә белә. Аның иҗатын үсмерләр дә, яшьләр дә, өлкән буын да бик яратып укый. Мин шуңа күрә сайлап алган теманы актуаль дип саныйм. Юморга корылган шигырьләр укучыларны тәрбияләргә ярдәм итә.

Максатка ирешү өчен, С.Г. Хәкимова хезмәтләре, газета-журнал материаллары, интернет ресурслар файдаланылды.

Фәнис Яруллин бөек шәхес иде. Ул башкаларга охшамаган. Фәнис Яруллин күпме еллар үзенең язмышы белән көрәшеп яшәде. Шуңа күрә аңарда башкаларга караганда ихтыяр көче, рух ныклыгы бик зур булды. Әдипнең балалар өчен язылган әсәрләрен балалар гына түгел, өлкәннәр дә яратып укый. Язучының иҗаты безне әдәпле булырга өйрәтә, чын мәгънәсендәге кеше булырга чакыра, җаныбызны сихәтләндерә.

Мин Фәнис абый Яруллин шигырьләрен бик яратып укыдым. Бөек шәхес – Фәнис абый белән чын күңелдән горурланам.

Фәнис Яруллин исеме, иҗаты һәм мирасы беркайчан да онытылырга тиеш түгел.

Мин үземә шундый нәтиҗәләр ясадым:

1.Фәнис Яруллинның иҗат мирасы гаять бай һәм күпкырлы.
2. Аның иҗаты бик югары бәяләнә.
3. Шагыйрьнең иҗатын әле тулысынча өйрәнәсе бар.
4. Фәнис Яруллин иҗаты мәктәп программасында күбрәк урын алсын иде.

## Татар әдәбиятын үстерүдә Фәнис Яруллин иҗатының роле

Гиматдинова Илүзә, 9 нче сыйныф
Яңа Чишмә районының “Тубылгытау төп мәктәбе”
Җитәкче: Халиуллина Г.Р,

Әдәбият халык тормышы белән тыгыз бәйләнештә яши, үзгәреш кичерә. Менә шушы бай мираслы әдәбиятка санлы өлеш кертү юнәлешендә зур көч куйган әдипләр арасында Фәнис абый Яруллин да бар.

Ф.Яруллин үзенең күптармаклы һәм үзенчәлекле иҗаты белән күпләрне җәлеп итә.

Беренчедән, ул төрле жанрда иҗат итә. Икенчедән, авторның геройлары арасындагы мөнәсәбәтләр һәм аларның чишелешләре үзенчәлекле булуы. Үз бәясен биреп барган туры сүзле, кыю фикерле публицист та әле ул.

Кечкенәрәк сыйныфларда мин аның шигырьләрен якын күреп укый башладым. Бүгенгедәй хәтеремдә “Гайни”дигән шигыре. Мәктәптән кайтканда, берәр бабай таеп егылсын иде, ә мин булышыр идем дип кайта идем. Аннан соң укытучылар көнендә “Сез иң

гүзәл кеше икәнсез" дигән җырны башкара идек. Бу җырны башкарганнан соң, бөтен укытучылар да миңа гүзәл булып тоела иде.

"Кояштагы тап"хикәясен дәрестә укыдык. Укытучым бер ак кәгазъ бите алган, шуңа кара тап буяган. Безгә күрсәтә. Бу нәрсә, ди. Без инде пычранган бу кәгазъ бите, таплы, дибез. Менә шушы сүзләр белән ул безне "Кояштагы тап "хикәясен укырга әзерләде. Шушы кечкенә генә хикәядән без дөньяда бер генә яманлык та, бер генә ялган да эзсез калмаганын, яманлыкны хәтта кояш та яндырып бетерә алмавын бик яхшы аңладык.

"Ак төнбоек"хикәясендә Шөһрәт күңелендә туган яхшылык, Гадиләгә булышырга омтылу – Кеше өчен иң кирәкле сыйфатлар, иң зур байлык. Ләкин иткән яхшылыгың белән мактанып, гел искә төшереп, гел битәрләп тору бөтен яхшылыгыңны җимерә дә ташлый. Үземә дус сайлаганда мин инде Фәнис абый Яруллин әсәрен искә төшердем.

Аның иҗатында үзенчәлекле шаянлык һәм шулар белән бергә халык авыз иҗатына хас тапкырлык, сагыну-сагышларны, милләтебезгә хас булган  башка асыл сыйфатларны күрергә була. Татар халкына хас кунакчыллык, уңган-булганлык, буыннан буынга тапшырылып килгән гүзәл гореф-гадәт, бәйрәмнәребез. Мәсәлән,Сабантуйга халыктан әйбер җыю күренешләре, кичке уеннарда егет-кызларның халык җырларын, биюләрен яратып башкарулары ("Җилкәннәр җилдә сынала"повестенда).

Фәнис абыйның әсәрләренә кергән туган як табигате халык өчен якын, кадерле. Авылына барып керсәң, Өемташ таулары уйчан гына тирбәлә сыман. Фәнис абый серләшкән таулар. Бүген алар әдипнең туган авылында аның уйларына уралган сыман. Ул, кечкенә вакытында, шул тауларга менеп үзенең исемен дә язган әле. Кызылъярлылар 2010 нчы елның 28 нче августында шушы авылда йорт-музей ачып җибәргәннәр. Авылның нәкъ уртасында. Анда 874 экспонат бар. Алар арасында Фәнис Яруллинның китаплары, документлары, шәхси әйберләре дә бар.(җитәкчесе Гүзәлия Газизуллина).

Чәчмә, сәхнә әсәрләре авторы, шагыйрь, халкыбызның каһарман улы Ф.Яруллин иҗаты безне дөнья ваклыкларыннан һәм вакытлы ыгы-зыгылардан өстен булырга өйрәтә. Чын мәгънәсендә Кеше булырга чакыра. Ул җаныбызны сихәтләндерә, аруландыра, чистарта алган тылсыымлы көч кебек. Күңелләребезне бозланып катудан саклый.

Әлеге тикшеренү эшендә, "Татар әдәбиятын үстерүдә Фәнис Яруллин иҗатының роле"н ачыклау бурычы куелган иде. Аның иҗаты күпкырлы. Ф.Яруллин  әсәрләре аның катлаулы тормыш юлы белән тыгыз бәйләнгән, шагыйрьнең бик күп иҗат җимешләре үз автобиографиясенең турыдан-туры чагылышы булып тора.  Иң саф хисләр,  хыяллар-өметләр белән тулы иҗат татар әдәбияты үстерүдә  искиткеч зур роль уйный. Аның әсәрләре-тормыш. Үзеңне борчыган сорауга җавап табасың. Димәк,әдәбиятыбыз онытылмый.

## Фәнис Яруллин иҗатында балалар дөньясы

Җәләева  Әминә, 8 нче сыйныф
Казан шәһәренең "Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиясе"
Җитәкче: Фәхретдинова Г.М.

Сәнгати көче, иҗади пафосы белән Фәнис Яруллин иҗаты дөнья әдәбияты казанышлары белән янәшә торырлык.

Шагыйрь, язучы, әдип, халкыбызның каһарман улы Фәнис Яруллинның иҗаты безне дөнья ваклыкларыннан, вакытлы ыгы-зыгыдан, өстен булырга, өлкәннәрне хөрмәт итәргә, нәниләргә юл куя белергә, җир йөзендәге иң изге кешебез – әнкәйләребезгә карата мәрхәмәтле, олы җанлы булырга, кыскасы, чын мәгънәсендә Кеше булырга чакыра. Әдипнең әсәрләре җаныбызны сихәтләндерә, чистарта алган куәтле бер тылсымлы көч кебек.

Фәнис Яруллин аңлаешлы, гади, халыкчан яза. Аның күп кенә шигырьләре халык җырларыннан үсеп чыккандыр кебек. Ул – чын мәгънәсендә сизгер шагыйрь. Аның шигырьләрендә гап-гади көндәлек күренешләр сурәтләнә.

Әдип Фәнис Яруллинның бәрәкәтле һәм игелекле иҗаты катлаулы һәм каршылыклы тормышыбызга кыю үтеп кергән сихәтле бер нур сыман, адәм балаларының күңелләрен, рухларын, җаннарын тәмам бозланып катудан саклый, намусыбызны саф килеш сакларга омтыла. Шуңа аның иҗаты, тереклек чишмәсе кебек, беркайчан да саекмый. Әдип боларның барысына да үзенең вөҗдан эше итеп карый, шуңа бөтен гомерен багышлый.

Әдипнең нәниләр өчен язган шигырь-поэмаларын укысаң, аны бөтен иҗатын балаларга гына багышлаган язучы итеп күз алдына китерәсең. Нәниләргә багышланган шигырьләрендә җорлык, шуклык, тапкырлык авторның табигатеннән киләдер.

Әдип баланың холкына хас кызыксынучанлыкны юмор аша бирә. Шуның белән әсәрен кызыклы итә. Баланың тапкыр җавабы укучыны көлдерү өчен генә бирелми. Тапкыр җавап – зирәклек билгесе. Ә зирәклек, якты зиһен, җор тел баланың күңеленә шифалы бальзам булып агып керә. Көлә белгән, үзенең кимчелекләренә юмор аша карый белгән кеше сәламәт була.

Талантлы язучы үзенең әкиятләре аша да бик мөһим әхлак мәсьәләләрен хәл итүгә ирешә. Баланың табигате шундый (бу сыйфат гомер буе саклана дисәк тә, хаклы булырбыз), ул “тегеләй эшлә дә, болай итмә” дигәнне яратмый. Ә менә балаларның яраткан жанры булган әкиятләр аша язучы тәрбия темасын чишүдә зур уңышка ирешкән. Фәнис Яруллин әкиятләрендә мәрхәмәт, шәфкать төшенчәләре зур урын алып тора, ә кансызлык, бәгырьсезлек, куркаклык, алдау юлы белән максатка ирешү катгый рәвештә тәнкыйтьләнә. “Юылмас хурлык”, “Кояштагы тап” кебек әкиятләре моның ачык мисалы.

Шулай ук табигатьтәге күренешләрне, табигатьтә барган үзгәрешләрне сурәтләгәндә дә шагыйрь ана образын төрле яссылыкта ача. Мәсәлән, карт өянкенең кыш көне бушап калган ояны саклавын, балалары таралгач, үз нигезен саклаучы карт ана белән чагыштыру (“Өянке” (1969)); төнлә коелган алмаларны кайгысын әйтми яшертен елаучы анага охшату (“Ник коела алмалар?”(1973)); ташландык, “кара көйгән” бакчаны рәнҗетелгән ана йөрәге белән янәшә кую (“Ташландык бакча” (1985)).

Теленең байлыгы, холыкларны ачудагы нечкәлеге, әсәрләрендә артык сүзләрнең булмавы, иң тирән кичерешләрне дә гади һәм аңлаешлы итеп ача белүе, әсәрләрендәге тема яңалыгы, тормыш проблемаларын күтәрүдәге новаторлыгы – болар барысы да аның олы язучы, бөек шәхес икәнен раслыйлар.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: Фәнис абыйның әкиятләрен бик яратып укыйбыз. Әмма аларны дөньяның күп телләренә тәрҗемә итәргә иде. Шул әкиятләргә нигезләнеп, туган телебездә мультфильмнар да эшләнсә, барыбыз өчен дә нинди сөенечле һәм күркәм күренеш булыр иде.

## Фәнис Яруллинның бәрәкәтле һәм игелекле иҗаты

Зәбиров Умар, Газизов Амир, 7 нче сыйныф
Казан шәһәренең “113 нче татар-рус мәктәбе”
Җитәкче: Фәйзетдинова Г.Г.

Фәнис Яруллин – шагыйрь дә, прозаик та, драматург та, әкиятләр остасы һәм ялкынлы публицист та. Иҗатының кайсы ягын гына алып карама, аның үзенә генә хас фәлсәфи карашын, тормышка мөнәсәбәтен күрәсең.

Фәнис Яруллин 1938 нче елның 9 февралендә республикабызның Баулы районы Кызылъяр авылында гади игенче крестьян гаиләсендә дөньга килә. Туган ягында урта белем ала. Бала чакта бергә уйнап, тау битләрендә җиләк җыеп, Ык елгасында су коенып үскән дуслары һәм сабакташлары аны җор сүзле, шат күңелле итеп искә алалар.

Матбугатьтә Фәнис Яруллинның беренче әдәби иҗат тәҗрибәләре 1960 нчы елда Баулы район газетасында, аннан соң республиканың үзәк газета-журналларында басылалар. Димәк, Фәнис Яруллин иҗатка күмелә.

Автор без яшәгән чынбарлыкны гамьле дөнья итеп карап, үз хикәяләрендә бу хәятнең төрле халәтләрен һәм мизгелләрен гәүдәләндерә. Әсәрләрендә сурәтләнгәннәрне авторның гадәти күз белән генә түгел, бәлки күңел күзе белән генә күрүе сизелеп тора.

Гамьле яшәү идеясын алга сөреп, Фәнис Яруллин, табигый, безнең көндәлек тормышыбыздагы гамьсезлек күренешләре өчен аеруча борчыла, укучы игътибарын да еш кына шуларга юнәлтә, алардан гыйбрәт һәм сабак алырга куша кебек. «Рәнҗү» дигән хикәядә, мәсәлән, шундый күренешләрнең берсе сурәтләнә.

«Кайту» повестендә яңа сюжет. Совет Армиясе дигән бөек көчнең эчтән җимерелүен автор аерым шәхес язмышы аша тасвирлап күрсәтә. Әсәрдә ике олы язмыш. Ата һәм Ул язмышы. Икесе дә хәрби кешеләр. Шагыйрь чын мәгънәсендәге Кеше булырга чакыра. Ул җаныбызны сихәтләндерә, аруландыра, чистарта алган куәтле бер тылсыми көч кебек. Әдип Фәнис Яруллинның бәрәкәтле һәм игелекле иҗаты катлаулы һәм каршылыклы тормышыбызда кыю үтеп кергән сихәтле бер нур сыман: адәм балаларының күңелләрен, рухларын, җаннарын тәмам бозланып катудан саклый.

Фәнис Яруллин безнең күңелләрдә мәңге онытылмас!

## Әкиятләрдән олы тормышка

Зәйнуллина Аделина, 4 нче сыйныф
“В.Ф.Ежков исемендәге Арча 1 нче урта мәктәбе”
Җитәкчеләр: Җәләева А.М., Сафиуллина Г.Н

Әкият – халык авыз иҗатының борынгы, шул ук вакытта киң таралган һәм мавыктыргыч жанрларыннан берсе. Татар халкы әкиятләргә бай халык. Күп гасырлар дәвамында әкиятләр телдән-телгә күчеп килгән. Шул ук вакытта күп кенә язучыларыбыз халык әкиятләре тәэсирендә үзләренең әкиятләрен дә иҗат итәләр. Бу язучылар арасында талантлы шагыйрь, хикәяләр остасы, тирән эчтәлекле әсәрләр иҗат итүче драматург һәм балалар язучысы Фәнис Яруллин да бар.

Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Республикабызның халык шагыйре Фәнис Яруллин тормышы һәм иҗаты белән дә беркемгә дә ошамаган язучыларның берсе.

Мин бу эшемдә Фәнис Яруллинның иҗатына тукталып китәсем килә. Фәнис Яруллинның әкиятләрендә бүгенге көн проблемалары күтәрелә. Мин укыган әкиятләрдә кешелеклелек, шәфкатьлелек, миһербанлылык, тугрылык, мәрхәмәтлелек темалары ачыла. Ә кансызлык, куркаклык, алдау юлы белән максатка ирешү катгый рәвештә тәнкыйтьләнә. Шулай ук табигатьне саклау, барча тереклек ияләренә карата мәхәббәт кебек сыйфатлар да чагылыш таба.

Язучыны әхлаксызлыкның үсүе, кешелеклелек, ата-ананы хөрмәт итү, үз гаебеңне тану кебек сыйфатларның югала баруы борчый.Шуңа күрә, аның әкиятләрен балалар гына түгел, өлкәнннәр дә яратып укый.

Фәнис Яруллин иҗаты аша яхшылыкның һәрвакытта да начарлыкны җиңүенә тагын бер тапкыр ышанабыз. Ф.Яруллин әкиятләрендә төп геройлар үз максатларына ирешкәндә генә зур канәгатьләнү алалар. Билгеле, максатка ирешү авыр. Моның өчен кыюлык, тәвәкәллек, киң күңеллелек,юмартлык сыйфатларына ия булу кирәк.Әгәр син үз-үзеңне генә яратасың, мохтаҗларга,көчсезләргә ярдәм итмисең икән-тормыш сине бик кыен хәлдә калдырырга мөмкинлеген аңладым.

Фәнис абый әкиятләре аша китап укучылар йөрәгенә үтеп керә алды һәм татар әдәбиятын үстерүдә үзеннән искиткеч зур өлеш кертте.

## Фәнис Яруллинның шигырьләре көлдерә дә, тәрбияли дә

Иванов Сергей, Гыйлметдинов Ислам, 4 нче сыйныф
Казан шәһәренең “103 нче мәктәбе”

Җитәкчеләр: Зәйнуллина Г.Х., Хәйретдинова А.Х.

Без Фәнис Яруллин иҗатын туган тел дәресләрендә һәм дәрестән тыш чараларда бик яратып өйрәнәбез. Әсәрләрен сәхнәләштереп, бәйгеләрдә югары уңышларга ирешәбез.

Күңелебезгә аеруча юмор һәм сатирик шигырьләре якын. Эзләнү эшебезнең максаты: Фәнис Яруллин иҗатын тулырак өйрәнү,әдипнең балалар өчен шигырьләрендә юмор һәм сатираның әһәмиятен билгеләү.

Куелган максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычлар куелды: Фәнис Яруллинның юмор һәм сатирик шигырьләре белән танышу; әдипнең юмор остасы икәнен исбатлау; шигырьләренә карата үз фикерләребезне белдерү.

Безнең уйлавыбызча, сайлаган темабыз бүгенге көндә дә бик актуаль. Фәнис Яруллинның шигырләре бик тиз хәтердә кала һәм барысы да әхлак тәрбиясе бирүгә юнәлтелгән. Ә бүгенге көндә бу бик мөһим мәсьәлә булып тора.

Фәнис Яруллинның бар өмете- яшьләрдә, балаларда, сабыйларда. Ул үзе дә – гомере буена сабый булып кала белгән бәхетле кеше. Безне язучының төрле рольләргә керә белүе гаҗәпләндерде.

Фәнис абый үзенең иҗтында юмор һәм сатира аша укучыларын әхлаклы, белемле булырга,олыларны хөрмәт итәргә өйрәтә. Шагыйрь укучыларны матурлыкка, яхшылыкка, тормышны сөяргә өнди.Йомгаклап шуны әйтәсебез килә. Фәнни эшебезне башкарганда,без түбәндәге нәтиҗәләргә ирештек: Фәнис Яруллин шигырьләре дөрестән дә,юмор һәм сатира белән сугарылган.Безнең кебек рус мәктәпләрендә укыган татар балаларына аның теле аңлаешлы,әсәрләрен уку кызыклы,өйрәнергә җиңел.

## Фәнис Яруллинның әдәп-әхлак мәсьәләсен күтәргән балалар прозасын инглиз теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләре

Кашапова Динә, 9 нчы сыйныф
Казан шәһәренең “13 нче гимназиясе”
Җитәкче: Садриева Г.Х.

Әдәби тәрҗемә – оригиналга ияреп тәрҗемә итү, шул ук вакытта тәрҗемә теле үзенчәлекләрен яраклаштырып эшләнә. Төп максат булып әсәрнең стилен мөмкин кадәр саклау, укучыга җиткерү тора.

Мәгълүм булганча, Ф. Ярулинның кайбер әсәрләре инглиз теленә тәрҗемә ителгән. Тәрҗемәләрнең кат-кат эшләнүе, андый җаваплы эшкә иң тәҗрибәле тәрҗемәчеләр җәлеп ителүе нәтиҗәсендә аларның сыйфаты да канәгатьләнерлек.

Билгеле, әдәп-әхлак мәсьәләсе Фәнис Яруллинның балалар прозасында төп темаларның берсе булып тора. Мисалга “Ак төнбоек” хикәясен алыйк. Әсәр профессиональ дәрәҗәдә инглиз теленә тәрҗемә ителгән. Бер өзекне карап китик. “...Дан иярле булмаса да, кайберәүләр аңа атланырга, шуның белән тормыш юлындагы барлык киртәләрне сикереп чыгарга телиләр. Шөһрәт исә бу атка үзе атланмады, ияргә аны башкалар утыртты. Тик аннан ни файда? Үзе дә аңламастан эшләп ташлаган батырлыгы аны башка балалардан аерды.” “...Using the fame they have achieved, some people want to overcome all the obstacles in life. Shukhrat did not want to admit his heroism, but others forced him to. But what's the use of it? His bravery, which he did unconsciously, set him apart from other children. Shukhrat grew up. The pages of the newspaper that once wrote about his feat turned yellow. If even the articles about his heroism in the Newspapers disappeared, they did not disappear in Shukhrat's soul.”

Күргәнебезчә, тәрҗемә әсәрдә эчтәлек тулырак, баерак итеп бирелә һәм тәрҗемәче образлылыкны тагын да арттыра.

Фәнис Яруллинның “Зәңгәр күлдә Ай коена”, “Биюче бака” китапларында бик күп әкиятләр тупланган. Мисалга “Рәссам кыз” әкияте. “Борын-борын заманда, бәп-бәләкәй авылда, ун терәүле бер өйдә яшәгән, ди, узенең нәни кызы белән бер карчык. Таң нурлары

офыкларга таралуга, урманнарда, болыннарда сандугачлар уянуга, карчык өйдән чыгып китә икән. Китмәс иде, карын икмәк таләп иткән..." Тәрҗемәдә әлеге өзек болай яңгырый: «In the old days, in a small village, in one of the houses, there lived an old woman with her little daughter. As soon as the rays of dawn spread to the horizon, the nightingales woke up in the woods and meadows, the old woman left the house. I wouldn't leave, but hunger forces me to...»

Күргәнебезчә, "ун терәүле, карын" сүзләрен инглиз теленә тәрҗемә итеп булмый. Оригинал әсәрдә автор шушы сүзләр белән геройларның ярлылыкларын күрсәтергә тели. Әлеге сүзләрнең тәрҗемәсе булмавы эчтәлекне гомумиләштерә, әсәрнең тәэсир көче югала.

Фәнис Яруллин әкият жанрын файдаланып, бик мөһим әхлак мәсьәләләрен хәл итә. "Биюче бака" әкиятенең тәрҗемәсенә тукталыйк. "In a certain country, in a small lake, there lived a frog that danced very well. Every morning she would get up on a water Lily and start dancing". Тик ана бака болай ди: "Daughter, you're the only one in the lake. There are no beautiful dancing frogs except you. Know that you are better than everyone else".

Күргәнебезчә, тезмә фигыльләр, фразеологизмнар инглиз теленә турыдан-туры тәрҗемә ителми, шуңа да мәгълүмат гомумиләштереп бирелә. Оригинал әсәрдә эчтәлек тулырак, баерак итеп бирелә.

Фәнис Яруллин әсәрләрен тәрҗемәдә уку, әлбәттә, кызыклы. Әмма оригинал белән чагыштырганда, тәрҗемәдә әсәр ачылып бетми, ләкин әсәрдә әдәп-әхлак мәсьәләсе күтәрелүе, халкыбызга хас кешелеклелек, ата-ананы зурлау, үз гаебеңне тану кебек сыйфатларны укучыга җиткереп була.

## Фәнис, син миннән әйбәтрәк

Менлишев Егор, 6 нчы сыйныф
Казан шәһәренең "85 нче урта мәктәбе"
Җитәкче: Краснова Е.А.

Фәнис Яруллинның замандашлары, аның белән бергә иҗат иткән каләмдәшләре бик күп. Аның авыр тормышында аңа ярдәм итүчеләр бик күп булган. Шулар арасыннан безгә Фәнис Яруллинның Туфан Миңнуллин белән мөнәсәбәте аеруча ошады. Туфан Миңнуллин шагыйрьнең замандашы да, каләмдәше дә, ярдәмчесе дә.

Әлеге теманың актуальлеге шунда: без Ф.Яруллинның иҗаты белән күпмедер дәрәҗәдә дәреслекләрдә танышабыз, ә аның Туфан Миңнуллин белән мөнәсәбәте турында белмибез. Шуны күздә тотып, без түбәндәге максатны куйдык: Ф.Яруллинның замандашы Туфан Миңнуллин аның турында нинди фикердә, аларның бәйләнешләре нәрсәдә?

Эшемнең максаты: Фәнис Яруллинның Т.Миңнуллин белән булган мөнәсәбәте турында мәгълүмат туплау. Әлеге максатка ирешү өчен мин Фәнис Яруллинның "Сөенечләр бүлешү", "Хәтер төпләрендә утлы күмер" китаплары белән танышып чыктым. Шулай ук, Гөлчәчәк Галиеваның "Күңелемә якын затлар" китабы, Туфан Миңнуллинның "Фәнис, син миннән әйбәтрәк" мәкаләсе дә ярдәм итте.

Без яраткан шагыйребез, язучыбыз, драматургыбызга ярдәм кулы сузган, файдалы киңәшләрен биргән барлык шәхесләргә дә тукталып китмәдек. Алар бик күп. Безнең тукталган шәхесебез берәү булды: ул - Туфан Миңнуллин

Туфан Миңнуллин Фәнис Яруллинга драматург булып үсеп китәргә ярдәм итә. Үзеннән дә югары булырлык дәрәҗәгә җиткерә. Һәрвакыт аның күңелен үстерә. Алар һәрвакыт аралашып яшиләр, иҗат планнары, эшләгән эшләре турында фикер алышалар. Туфан Фәнис Яруллинның зур таянычы, киңәшчесе була.

Димәк, Фәнис Яруллинның замандашы, каләмдәше, киңәшчесе булган Туфан Миңнуллин шагыйрь тормышында зур роль уйный.

# Фәнис Яруллин әкиятләренең үзенчәлекләре

Минһаҗева Айзилә, 6 нчы сыйныф
Казан шәһәренең “4 нче гимназия-интернаты”
Җитәкче: Садыкова Р.Г.

Мең еллык тарихы булган әдәбиятыбызда Габдулла Тукай традицияләрен дәвам итеп балалар өчен матур-матур әкиятләр язучы әдипләр шактый. Алар арасында Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай һәм М.Җәлил исемендәге дәүләт бүләкләре иясе, “Халыклар дуслыгы” ордены кавалеры Фәнис абый Яруллинның да какшамас урыны бар. Шушы фикерне әсәрләр ярдәмендә исбатлау һәм әкиятләрнең төп үзенчәлекләрен билгеләү – алынган темабызның максатын билгели.

Фәнис Яруллинның әкиятләре шигъри телелеге, образлы сөйләмгә бай булулары белән аерылып торалар. Әдип чәчмә формадагы әкиятләрен дә шигъри формада яза. Бу үзенчәлекне аның шагыйрь булуы белән аңлатырга мөмкин. Шушы эчке көй, шигъри моң әсәрнең буеннан буена кызыл юл булып сузыла. Татар әдипләре арасында мондый күренеш А.Алиш әкиятләрендә очрый, ләкин алар күп түгел. Мондый стиль үзенчәлеге бала психологиясен яхшы белүдән килә.

Ф.Яруллин әкиятләрендәге эчке рифмалар, вакыйгаларның үсә барып, герой белән укучының берләшүе әкиятләргә сихрилек бирә. Образлар ярдәмендә әдип геройларның тышкы кыяфәтләре белән бергә характерлы сыйфатларын да ача. Шушы паралель барган ике үзенчәлек әкият геройларын онытылмаслык итеп баланың хәтеренә сеңдереп калдырырга ярдәм итә.

Тел – һәр язучы өчен иң зур байлык. Алар тел ярдәмендә әллә нинди дөньяда булмаган Дию пәриләрен, Йорт ияләрен, албастыларны һәм тагын бик күп төрле әкият геройларының кыяфәтен, холык-фигылен, уй-гамәлләрен сурәтли. Әкияткә тирән фәлсәфә дә, сабыйларча беркатлылык та сыя. Ф.Яруллин үз әкиятләрендә тел белән ювелирларча эш итә. Бу сүзләрне раслау өчен аның әкият китапларының теләсә кайсы битен ачып карау җитә.

Ф.Яруллин иҗатында бертөрлелектән качарга тырышу бар. Аның әкиятләренең икенче үзенчәлеге шунда да инде. Аеруча әкиятләрнең башлам өлешенә зур игътибар бирә автор. Аның әкиятләре бер-берсеннән бик нык аерылып торалар. Әдип иҗатында бер үк төрле башланган әкиятләр бик сирәк. Билгеле, татар халык әкиятләрендә дә башлам өлеше бик кызыклы һәм мавыктыргыч була. Ләкин анда күпчелек әкиятләрдә бик күп мәртәбәләр сөйләнелеп, тәмам калыпланган форма, ягъни «Борын-борын заманда» дип башлап китү өстенлек итә.

Фәнис Яруллинның әкиятләрендәге өченче үзенчәлек – ул аларның тормышчанлыгы, ягъни аның әкиятләре, күпчелек очракта, хикәягә тартым. Аларны укыганда бала үзен әкияттә тасвирланган вакыйгалар эчендә итеп хис итә. Әкият герое белән бергә шатлана, кайгылы вакытта алар белән бергә борчу хисләре кичерә.

Фәнис Яруллин үз әкиятләрендә үз максатларына ирешкән геройларны гына: кыю, тәвәкәл, киң күңелле, юмартларны гына уңай герой итеп тасвирлый. Алар мисалында әдип бала күңелендә тирә-юньдәге кешеләргә, табигатькә карата сакчыл караш, игътибарлылык, кирәк чакта ярдәм итү кебек әхлакый сыйфатларны тәрбияли. Аның әкиятләрендә ялкаулар, алдакчылар, киребеткәннәр һичбер вакыт максатларына ирешә алмый.

Нәтиҗә итеп, Фәнис Яруллин балалар әдәбиятында үзенең ныклы урынын булдырды, дип әйтә алабыз. Әдипнең әкиятләр геройлары – ата-ана белән бала арасындагы әхлакый күперләрне ныгытырга, җәмгыятькә үз максатларына тугры булган шәхес тәрбияләргә ярдәм итүче ролен дә үти.

## Фәнис Яруллин юмор һәм сатира остасы

Мифтахова Адилә, 8 нче сыйныф
Казан шәһәренен “175 нче гимназиясе”
Җитәкчеләр: Габдулвалиева Р.Н., Гафарова Г.Г.

Бүгенге көндә шагыйрьләр арасында иң хөрмәт иткән шагыйрьләремнең берсе – Фәнис Яруллин. Шуңа күрә мин Фәнис Яруллинның иҗатын тирәнрәк өйрәнергә булдым.

Максатым – Фәнис Яруллинның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнү. Максаттан чыгып, мин үз алдыма түбәндәге бурычларны куйдым:

- Фәнис Яруллинның  юмор һәм сатира остасы икәнен исбатларга; шигырьләренә карата үз фикеремне белдерергә.

Фәнни-тикшеренү эшенең төп объекты – Ф. Яруллинның тормыш юлы һәм  иҗаты; предметы – балалар өчен язган шигырьләре.

Шагыйрь укучыларны матурлыкка, яхшылыкка, тормышны сөяргә өйрәтә. Һәм ул аны бик оста эшли, чөнки аның шигырьләре юмор һәм сатирага корылган. Ә андый шигырьләрне уку җиңел дә, рәхәт тә. Аның шигырләре бик тиз хәтердә кала һәм барысы да әхлак тәрбиясе бирүгә юнәлтелгән. Ә бүгенге көндә бу  бик мөһим мәсьәлә булып  тора.  Ул үзенең шигырьләрендә өлкәннәр белән балалар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, сабыйлар дөньясындагы проблемаларны күрсәтә беләә. Аның иҗатын үсмерләр дә, яшьләр дә, өлкән буын да бик яратып укый. Шуңа күрә  сайлап алган теманы актуаль дип саныйм. Юморга корылган шигырьләр укучыларны тәрбияләргә ярдәм итә.

Фәнис абый Яруллин – шагыйрь дә, прозаик та, драматург та, әкиятләр остасы һәм ялкынлы публицист та. Иҗатының кайсы ягын гына алып карама, аның үзенә генә хас фәлсәфи карашын, тормышка мөнәсәбәтен күрәсең.

Өлкәннәр өчен язылган повесть, хикәя, пьеса һәм поэмалары бу олы, тирән иҗат елгасының бер тармагын тәшкил итсә, икенче тармагы исә – балалар әдәбияты. Әкиятләр яки балалар өчен язылган поэмалар дисеңме, шуклыкка – җорлыкка корылган шигырьләр дисеңме – боларның һәркайсында олы фикер, саф әхлак һәм матурлыкка омтылу ята.

“Укыр идем бишкә генә” дигән шигырен алып карыйк. Бала психологиясенә хас хыялны автор юмор аша бирә. Әйе, бөтен бала да бишле белгесенә генә укырга хыяллана. Ләкин төрле сәбәпләр аркасында бу хыял күп баланың төшенә генә керә. Көлә белгән, үзенең кимчелекләренә юмор аша карый белгән кеше сәламәт була. Табиблар тәнне дәваласа, язучылар җанны дәвалый.

“География дәресендә” дигән шигырендә Фәнис абый юмор аша укучының тапкыр җавабын бирә. Баланың тапкыр җавабы укучыны көлдерер өчен генә бирелми. Тапкыр җавап ул – зирәклек билгесе. Ә зирәклек, якты зиһен, җор тел баланың күңеленә шифалы бальзам булып агып керә.

Шәхес булып формалашу кечкенәдән башлана. Балачактан ук һәр эшне үз ирке белән эшләргә тырышу – ялкаулыкны җиңү дигән сүз. Ихтыяр көчен үстерү, тырышу, кайсыдыр яктан үзеңне күрсәтергә омтылу һәр бала күңелендә дә бар. Нәниләр психологиясен яхшы белгән язучы гына балалар өчен үтемле әсәрләр яза ала. “Узар идем” шигырендә шуклык белән бирелгән “теләк” баланың үз – үзенә булган критикасын күрсәтә, ялкаулыгын таный бала. Үз гаебеңне тану – төзәлүгә беренче адым.

## Фәнис Яруллин – драматург

Муллахметова Лилия, 10 нчы сыйныф,
Казан шәһәренең “47 нче мәктәбе”
Җитәкче: Баһавиева С.С.

Фәнни эшемнең максаты: халык шагыйре Фәнис Яруллинның иҗатын тулырак ачу, татар әдәбияты үсешендә аның ролен һәм тоткан урынын төгәлрәк билгеләү.

Бурычлар: Ф.Яруллинның драматург буларак эшчәнлеген ачыклау; әсәрләренең тәрбияви әһәмияте;Ф.Яруллин иҗатында кеше тормышының мәгънәсе, кыйммәте, яшәешнең катлаулы, каршылыклы якларын күрә белү.

Бу тикшеренү эшенә әзерләнгәндә, бик күп китаплар, газета-журнал материалларына мөрәҗәгать иттем. «Идел», «Казан утлары», «Мәйдан» журналларыннан материаллар алдым. Мин сайлаган тема бик актуаль дип саныйм.

Эшнең структурасы. Фәнни эшем кереш, төп өлештән, йомгаклаудан, әдәбият исемлегеннән тора.

Ф.Яруллин иҗади эшчәнлегенең бер тармагы драматургия белән бәйләнгән. Аның ике дистәгә якын пьесасы бар. Профессиональ режиссерлар тарафыннан 13 әсәре сәхнәләштерелгән. Сәхнә әсәрләре арасында комедия, драма, трагедия дә бар.

Аның беренче пьесасы «Әнә килә автомобиль», М.Сәлимҗанов тарафыннан сәхнәләштерелеп, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куела һәм озак еллар сәхнәдән төшми. Ул шушы беренче пьесасы белән үк үзенең драматургия өлкәсендә талантлы каләм иясе икәнен таныта.

Ф.Яруллин драма жанрының комедия төренә ешрак мөрәҗәгать итә. Әйтик, «Бай эти», «Койрыксыз сандугач», «Сөембикә егет сайлый», «Бер күрешү - үзе бер гомер», «Кызларның кызганнары» – шундыйлардан. Комедияләрендә автор тормышның авырлыгын, җәмгыятьтәге гаделсезлек очракларын, аның кешеләр психологиясенә тәэсир итүен, шуның нәтиҗәсендә туган белән туган, дус белән дусның конфликтка керүен төрле ситуацияләргә куеп сурәтли.

Ф.Яруллинның «Кызлар күңеле-тирән сер» пьесасы жанры буенча лирик драма. 1997 елда бу пьесасының икенче кисәген – «Җимерелгән хыяллар» драмасын яза. Драмада күтәрелгән проблемаларга нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: хәзерге дөньяда үзеңнең хыялыңа ирешү өчен вөҗдан һәм намусның нык, ихтыяр көченең көчле булуы, кешеләр турында кайгыртучанлык күрсәтү сорала.

Сугыш темасы, сугышның кешеләргә китергән кайгылары, ятим балаларның түгелгән күз яшьләре Ф.Яруллинның «Язмышларны язып булмый яңадан» дип исемләнгән шигъри трагедиясендә тирәнрәк чагыла. Әдип әлеге әсәрен «Нәсел агачы» һәм «Коткарыгыз» поэмаларына нигезләнеп иҗат итә. Сугыш беткәннән соң да халыкның тормыш дәрәҗәсе түбән булу, илне дошманнан саклап калу өчен үзенең гомерен кызганмаган солдатларның балалары һәм якыннарының кичергән газаплары, кеше дигән олы затның кадерен белмәү, әсәрнең буеннан-буена сурәтләнеп бирелә.

Ф.Яруллинның әкият-пьесалары да шактый. «Әмәк белән Шәмәк», «Шүрәлеләр каргышы», «Каракның бүреге яна», «Бәхет ачкычы», «Ак яфрак», «Хәзинә» исемле пьесалары балаларга тәрбия бирү ягыннан зур мәгънәгә ия. Һәр пьесада яхшылык белән яманлыкның бәрелеше, ялкаулык һәм алдау нәтиҗәсендә килеп чыккан күңелсезлекләр ышандырырлык итеп сурәтләнгән.

Фәнис Яруллин үзенең сәхнә әсәрләрендә геройларының йомшак якларын сурәтләгәндә юмористка, төзәлмәслек кимчелекләрен ачканда сатирикка әверелә. Аның пьесалары музыкаль, җырларга бай. Пьесаларының озын гомерле булуы – аның халыкчанлыгында, авторның гади генә нәрсәләрне дә матур итеп күрә белүендә.

## Фәнис Яруллин – халкыбызның йөз аклыгы

Мухетдинов Марсель, 6 нчы сыйныф
Казан шәһәренең “175 нче гимназиясе”
Җитәкче: Хакимова М.С.

Фәнни эшем иҗат гомере батырлык, фидакарьлек үрнәгенә әверелгән М.Җәлил исемендәге премия лауреаты, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре,

“Халыклар дуслыгы” ордены иясе, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе, Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллин иҗатына багышлана.

Эзләнү эшемнең темасы: “Фәнис Яруллин – халкыбызның йөз аклыгы”.

Эзләнү предметы: Фәнис Яруллин шигырьләренең әһәмияте, тәрбияви роле.

Эзләнү объекты: Фәнис Яруллин шигырьләре, аның турында язылган китаплар, мәкаләләр, истәлекләр.

Максат: танылган каләм остасы Фәнис Яруллин иҗатында темаларның бирелешен, укучы күңеленә тәэсир итү, кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләү алымнарын ачыклау.

Бурычлар: Фәнис Яруллин шигырьләрен уку; теманы яктырткан фәнни-методик әдәбиятны өйрәнү; Ф. Яруллин шигырьләренең тематикасын билгеләү; Ф. Яруллин шигырьләренең тәрбияви көчен ачыклау.

Эзләнү актуальлеге: шагыйрьнең шигырьләре бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган. Минемчә, Фәнис Яруллин иҗаты – мәңгелек әдәби мирас. Аның шигырьләрендә күтәрелгән темалар беркемне дә битараф калдырмас. Туган җир, аның табигате һәркемгә якын, кадерле. Һәр кеше анда үзенә рухи азык табар. Аның әсәрләре – Тормыш мәктәбе. Мин аның шигырьләрендә барлык сорауларга да җавап таба алам. Фәнис Яруллин китаплары – минем киңәшчем, сердәшчем.

Эзләнү методлары: әдәби әсәрләрне уку, анализлау, эзләнү.

Мин Фәнис Яруллинның бик күп шигырьләрен укыдым, анализладым, аның турында язылган мәкаләләр, истәлекләр белән таныштым һәм шундый нәтиҗәгә килдем:

1.Фәнис Яруллин иҗаты бүгенге көндә үзенең актуальлеген югалтмаган, чөнки аның шигырьләрендә чагылган темалар – мәңгелек.

2.Фәнис Яруллин шигырьләре безне тәрбияли, матурлыкка, яхшылыкка, туган телебезне, туган җиребезне яратырга, аның белән горурланырга өйрәтә.

3.Фәнис Яруллин шигырьләрен балалар да, өлкәннәр дә яратып укый, чөнки алар шаян, кызыклы сюжетка корылган, һәркемгә дә аңлаешлы тел белән язылган.

4. Һәр укучы бу шигырьләрдә үзен кызыксындырган сорауларга җавап таба ала, чөнки әсәрләренең нигезендә яшәү фәлсәфәсе ята.

Аның иҗаты белән тагын да күбрәк танышкан саен, минем дөньяга, якыннарыма, дусларыма, тирә-якка карашым үзгәрде, мин дөньяга яңа күзлектән карадым. Матурлыкны күрергә өйрәндем. Кешеләргә, барлык җан иясенә яхшылык эшлисем килә. Фәнис абыйның көчле рухы, тормышны яратуы шигырьләре аша миңа да күчте.

Шигырьдә – кырык елдан артык гомер! Бу гомер – илаһи, якты, матур бер юл. Һәм ул, гомернең үзе кебек үк, күргәнебезчә, гел гөлләр, чәчәкләр белән генә бизәлмәгән. Анда сикәлтәле юллар да, җиңеп үтәсе чытырманлыклар, упкыннар да күп булган. Әмма аксакал шайгырь Фәнис Ярулинның үткәннәргә борылып, горур караш ташларга тулы хакы бар. Үткәннәр алдында да, халык алдында да йөзе ак шагыйрьнең. Киләчәктә дә аның иҗаты татар әдәбиятының онытылмас җәүһәрләре булып сакланыр.

## Фәнис Яруллин иҗатында балалар психологиясенең чагылышы

Нажарова Айзилә, 8 нче сыйныф
Казан шәһәренең “89 нчы мәктәбе”
Җитәкчеләр: Хабибуллина Д.М., Хусниева А.С.

Татар әдәбияты талантлы, бөек шәхесләргә бик бай. Шулар арасында Фәнис Яруллин үзенең күптармаклы һәм үзенчәлекле иҗаты белән игътибарны җәлеп итә. Тикшеренү объекты итеп Фәнис Яруллинның “Тавышым калсын билгегә”, “Алсу чәчәк”, “Солдат пәкесе”, Сандугач оясы”, “Бүректәге бүрек баласы”, “Аксак тимер” хикәяләрендәге геройларның күңел дөньясын сурәтләү үзенчәлекләре сайланды.

Кешенең күңел дөньясы – бик киң сыйдырышлы, нәфис, төрле-төрле хисләрнең гаҗәеп күп нюансларын үзенә сыйдырырга сәләтле дөнья. Шунысы да мөһим: күңел дөньясы боларны сыйдырып кына калмый, аларның үсеш-үзгәрешен дә эченә ала.

Фәнис Яруллинның хикәяләре үзләренең оригинальлекләре, мәгънәви тирәнлекләре һәм тасвири осталыклары белән күңелләрне яулый, уйланырга мәҗбүр итә. Язучының без укыган хикәяләрендәге геройларның күбесен берләштерүче сыйфат – аларның иманлы, эчкерсез, ярдәмчел булулары, авыл табигатенә гашыйк булып, аның киләчәге өчен кайгыртулары, бай күңел дөньясына ия булулары.

“Алсу чәчәк” хикәясендәге Сиринә исә, бала гына булуына карамастан, авыру күрше абыйсына ничек тә ярдәм итәсе килү теләге белән яна. Авылга кайткач, Рәшит абыйсы сөйләгән әкияттәге бар авыруларны да җиңә торган алсу чәчәкләрне эзли. Ахырдан тау башыннан җыйган шайтан таягы чәчәкләрен җыеп Рәшит абыйсына җибәрә. Сиринә ышана: шайтан таяклары һичшиксез әкияттәге алсу чәчәкләргә әвереләчәк һәм күрше абыйны аякка бастырачак.

Фәнис Яруллин хикәяләрендәге балалар да изге эшне онытмыйлар, яхшылыкны яхшылык белән кайтара беләләр. Мәсәлән, “Солдат пәкесе” хикәясен алыйк. Гыйлаҗи абыйлары яхшы пәкесе белән авыл малайларының чәчләрен ала, бөтен малайлар да бик теләп аңа йөриләр. Чөнки, Гыйлаҗи абыйлары авырттырмыйча, канатмыйча, пөхтә һәм матур итеп эшли. Авыл малайларының бу абыйга шулай ук изгелек эшлиселәре килә. Өлкәнрәк малайларның Гыйлаҗи абыйларның яшелчә бакчасын басарга теләүләрен белгәч, алар хәйлә уйлап табалар, теге малайларны куркыталар, яшелчә бакчасын угрылардан саклап калалар.

Фәнис Яруллин аларның эчке дөньяларын, рухын ачып бирү өчен, хикәяләрдә өзек-өзек хатирәләр, әкиятләр дә куллана. Мәгълүм булганча, геройларның эчке дөньясын бирүдә әдип пейзаж тасвирларын да файдалана. Фәнис Яруллин балаларның күңел дөньясын сурәтләгәндә, аның олылар, бигрәк тә ата-ана йогынтысында формалашуына басым ясый.

Фәнис Яруллин олыларга хөрмәт белән карый белгән, кечкенәдән аларга булышып үскән, шаян, зирәк геройларын аерым бер ярату белән сурәтли. Сугыштан соң ярлылыкта үскән малайлар – эш сөючән, җитез, шук, гаделсезлеккә каршы көрәшергә әзер булган тулы канлы шәхесләр буларак тасвирланалар. Әсәрләрне тирәнрәк өйрәнү шуны күрсәтә: әдипнең уңай геройлары табигать белән берлектә яшиләр, тискәре персонажлары шәфкатьсезлек сыйфатлары белән аерылып торалар.

## Фәнис Яруллин әсәрләренең тәрбияви көче

Насырова Алина, 9 нчы сыйныф
Казан шәһәренең “110 нчы лицее”
Җитәкче:Зарипова Г.Г.

Фәнис Яруллин - көчле рухлы язучы. Үз тормышы мисалында башкаларны тәрбияли, шуңа да мин аның иҗатына мөрәҗәгать иттем. Яшь буынга тәрбия бирү, яшәү мәгънәсенә төшендерү – бүгенге көндә иң актуаль проблемаларның берсе булып тора. Эшемнең максаты: Фәнис Яруллин әсәрләренең тәрбияви көчен ачыклау. Максатка ирешү өчен бурычлар да билгеләнде.

Фәнис Яруллин үзенең әсәрләрендә күп проблемаларга кагыла. Авыл халкы тормышын сурәтләү аша кешелеклелек, ата-ананы зурлау, олыны – олы, кечене – кече итеп карау, бер-береңә ярдәмләшү, үз гаебеңне тану кебек матур сыйфатларны югалтмаска дигән фикерне этәрә. Һәр әсәрендә әхлаки якны күтәрү, эчке матурлыкны тою, ямьсез әйберләрне булдырмауны ассызыклау күренә. Безнең халкыбызны милләт итүдә зур роль уйнаган сыйфатларны сакларга, күркәм гадәтләребезне онытмаска кирәклеген билгели. Иҗатында авыл телне, әхлакны, халыкның милли чараларын саклаучы итеп күрсәтелә.

Әдип әсәрдәге геройлар аша тырыш һәм булдыклы булырга өнди. Мактасалар да, масаймау, үзең булып кала белү үрнәген күрсәтә. Тирә-якны игътибар белән күзәтү, табигатьнең матурлыгын күрә белү, файдасын табу һәм сак карашлы булу кебек сыйфатлар тәрбияли. Моны без “Моңлы курай” әсәрендә күрдек.

Туган тел, бердәмлек төшенчәләрен бала күңеленә кече яшьтән сала. “Анам теле”, “Бияләй” шигырьләре моңа мисал булып тора. Мондый әсәрләре аша Фәнис Яруллин кечкенәләрне олы тормышка әзерли: бердәм булырга өнди, бердәмлекнең көчен күрсәтә, үз телеңне белергә кирәклеге турында искәртә.

Ф. Яруллин әсәрләрендә мәрхәмәт, шәфкать, ярдәм, батырлык төшенчәләре зур урын алып тора, ә куркаклыкның аяныч хәлгә китерүе ачыла. Мәсәлән, “Юылмас хурлык” экиятендә баланың игътибарын батырлыкны сүз белән түгел, эш белән күрсәтергә кирәклегенә юнәлтә, чын батырлыкның асылын ачып бирә: “Батыр булу өчен җанда шәфкать кирәк, мәрхәмәтле йөрәк кенә батыр була ала”,– ди ул.

Әдипнең тормышчан әсәрләрендә явызлыкка яхшылыкны каршы куеп күрсәтүе дә, зур тәрбияви көчкә ия. “Биюче бака” әкиятендә туганлыкның, дуслыкның кадерен белү ассызыклана.

“Әйбәт тә минем әби” шигырендә кешенең җитешмәгән ягын ачып күрсәтә, уйланырга, хатаны танырга һәм төзәтергә этәрә. Ә “Гайни” шигырендә мәрхәмәтле бала образы аша кешеләргә яхшылык эшләргә, өлкәннәргә игътибарлы булырга, аларны хөрмәт итәргә, игелекле эшләр башкарырга, гамәлләр кылырга өйрәтә.

Әсәрләре аша Фәнис Яруллин балаларны сиздерми генә тәрбияли, алар күңеленә әхлаклылык, битараф булмау, шәфкатьлелек орлыклары сала. Үзенең иҗаты белән безне дөнья ваклыкларыннан, вакытлыча булган ыгы-зыгылардан өстен булырга өйрәтә, чын мәгънәсендә Кеше булырга чакыра.

Нәтиҗә ясап, шуны да әйтергә кирәк: Фәнис Яруллин иҗатында төрле алымнар куллана, психологик моментлар аша кичерешләрне ача. Мондый табышлары белән ул, гомумән, татар әдәбияты үсешенә дә зур өлеш кертә.

Ә минем бүгенге яшьләргә әйтер сүзем шул: тәртиплелек, тыйнаклык кануннарын саклап, үзеңне башкаларга үрнәк булырдай тотып, илебезнең әхлаки тотнагы нигезен ныгытуга үзеңнән өлеш кертергә кирәк. Мин дә, көчемнән килгәнчә, моңа омтылачакмын.

## Фәнис Яруллин шигырьләренә язылган җырлар

Рафиков Алмаз, 5 сыйныф укучысы
Казан шәһәренең “65 нче мәктәбе”
Җитәкче: Төхватуллина Г.Г.

Шагыйрь Фәнис Яруллин үзенең бер анкетасында җыр текстлары турындагы сорауга аларның төп таләбе итеп сюжетлыкны, образларның гади булырга тиешлеген әйтә. Аның фикеренчә, җырның төп вазыйфасы җанны тетрәндерү, кешене тирән уйларга салу, битарфлыктан чыгару. Дөрес, дәртне кузгатучы, борчу-мәшәкатьләрне күпмедер вакытка оныттырып торучы шаян җырлар да бар, ди ул. Миңа калса, Ф. Яруллинның шигырьләре үзе куйган таләпләрне үти: сюжетлык бар, образлары гади. Фәнис Яруллин шигырьләренә иҗат ителгән җырлар тирән фикерле, матур, көйләнеп тора. Тиз отып алырдай, тиз хәтергә керердәй булуы да җырның төп үзенчәлекләренә карый.

Фәнис Яруллинның байтак шигырьләренә төрле композиторлар көй яздылар, безнеңчә, аның шигырьләре болай да җырлап тора кебек. Җырның исә бик өлгер, җитез жанрлардан берсе икәнлеген белгәнгә, аның халык арасында күпкә тизрәк популяләшуында да бернинди шик юк. Белүебезчә, җыр шигырьдән башлана. Композитор аңа музыкаль аһәң, канат бирә. Шулар арасыннан аеруча Рөстәм Сәрвәров, Ганс Сәйфуллин, Фәрит Хатыйпов, Резидә Ахиярова, Риф Гатауллин, Оскар Усманов, Айдар Тимербаевларны атап узарга кирәктер.

Минем хәзер бөтен татар халкына таныш булган “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” җырына тукталып узасым килә. Шагыйрь үзенең беренче укытучысын, татар теле һәм әдәбияты укытучыларын зур соклану, ярату, хөрмәт белән искә алып, әлеге шигырен аларга багышлап иҗат итә. Әхмәт Хәйретдинов аңа көй яза. Әлеге җыр ел саен белем бәйрәмнәрендә меңләгән мәктәпләрдә яңгырый. Шулай ук балалар өчен иҗат ителгән “Рәхмәт Сезгә” җыры тәрбиячеләргә, укытучыларга багышлап язылган. Әлеге шигъри юлларда безгә тәрбия, белем бирүчеләргә рәхмәт сүзләре яңгырый.

Фәнис Яруллинның шигырьләренә иҗат ителгән җырлар арасында аеруча мәхәббәт темасы өстенлек алып тора. Мәхәббәт бирелгә илаһи көч, кешенең күңел канаты буларак тасвирлана. Мәхәббәт – ул сабырлык, ул – җаваплылык, яраткан кешең турында кайгырту, олы җанлылык. Мәхәббәт ул – тормыш. Бу тема шагыйрь иҗатының яртысын алып тора, дисәм тә ялгыш булмас. Аеруча сөю турында җырларны Гөлнара Тимерҗанова яратып башкара. Гөлнара Тимерҗанова эстрадага нәкъ менә Ф. Яруллин иҗат иткән шигырьләр белән килеп керә. Аның репертуарында без Фәнис Яруллин шигырьләренә язылган 11 җырны санап, тыңлап чыктык. Менә алар: “ Мин синеке, бары синеке” (“Син минем өчен”), “Йолдызлар яңгыры” һ.б. “Язмышларны берләштерик” җырын гына Айрат Ильясов белән дуэт итеп башкаралар, ә калган барлык җырларны да Г. Тимерҗанова үзе җырлый.

Ф. Яруллин иҗатын музыкасыз күз алдына китерүе дә авыр, шигырьләренең барысы диярлек үзеннән-үзе көй сорап тора кебек. Шуңадырмы, бик күпләр репертуарында аның шигырьләренә иҗат ителгән җырлар күп.

## Фәнис Яруллин иҗатында юмор һәм сатира

Саттарова Әминә, 4нче сыйныф
Казан шәһәренең “Ф.Г.Аитова исемендәге 12 нче татар гимназиясе”
Җитәкче: Самитова А.М.

Хезмәтемнең максаты – Фәнис Яруллинның иҗатында юмор һәм сатираны өйрәнү.

Әлеге максаттан чыгып, мин түбәндәге бурычларны билгеләдем: Ф.Яруллинның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышып китү; Ф.Яруллинның шигырьләрен анализлап, аның юмор һәм сатира остасы икәнен исбатлау; шигырьләрьгә карата үз фикеремне белдерү.

Фәнни-тикшеренү эшенең төп объекты булып Ф. Яруллинның шигъри иҗаты; предметы – балалар өчен язган шигырьләре булды.

Фәнни эшнең структурасы керештән, төп өлештән, йомгаклау өлешләреннән һәм кулланылган әдәбият исемлегеннән тора.

Фәнни-тикшеренү эшен башкарганда төп чыганак итеп Фәнис Яруллинның “Сайланма әсәрләр” хезмәте файдаланылды.

Сайлап алган теманы актуаль дип саныйм. Юморга корылган шигырьләр укучыларны позитив яктан тәрбияләргә ярдәм итә. Шагыйрь без – яшь укучыларны матурлыкка, яхшылыкка, тормышны яратырга өйрәтә. Фәнис абый аны бик оста эшли, чөнки аның шигырьләре юмор һәм сатирага корылган. Ә андый шигырьләрне укуы күңелле һәм рәхәт. Аның шигырләре җиңел ятлана һәм барысы да күркәм әдәп-әхлакка юнәлтелгән. Ә бүгенге көндә бу бик тә мөһим мәсьәлә булып тора. Ул үзенең шигырьләрендә өлкәннәр белән балалар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, сабыйлар дөньясындагы проблемаларны, хискичерешләрне күрсәтә белә. Аның иҗатын яшьләр дә, үсмерләр дә, олылар да, өлкән буын да бик яратып укыйлар.

# Фәнис Яруллин иҗатында юмор һәм сатира

Файзрахманова Камилә, 8 нче сыйныф
Саба районының “Түбән Шытсу төп мәктәбе”
Җитәкче: Мусина Җ.Х.

Минем фәнни эшемнең темасы – “Фәнис Яруллин иҗатында юмор һәм сатира”.

Максаты: Фәнис Яруллинның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнү. Максаттан чыгып, мин үз алдыма түбәндәге бурычларны куйдым:

- Фәнис Яруллинның юмор һәм сатира остасы икәнен исбатларга; шигырьләренә карата үз фикеремне белдерергә.

Теманың актуальлеге. Шагыйрь укучыларны матурлыкка, яхшылыкка, тормышны сөяргә өйрәтә. Һәм ул аны бик оста эшли, чөнки аның шигырьләре юмор һәм сатирага корылган. Ул үзенең шигырьләрендә өлкәннәр белән балалар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, сабыйлар дөньясындагы проблемаларны күрсәтә белә. Аның иҗатын үсмерләр дә, яшьләр дә, өлкән буын да бик яратып укый. Шуңа күрә сайлап алган теманы актуаль дип саныйм. Юморга корылган шигырьләр укучыларны тәрбияләргә ярдәм итә.

Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Республикабызның халык шагыйре Фәнис Гатаулла улы Яруллин иҗаты диюгә, күз алдына иксез-чиксез дәрья килеп баса. Бу дәрьяның дулкыннары көчле ярсу белән үз эченә бөтереп алыр кебек

Фәнис абый Яруллин – шагыйрь дә, прозаик та, драматург та, әкиятләр остасы һәм ялкынлы публицист та. Иҗатының кайсы ягын гына алып карама, аның үзенә генә хас фәлсәфи карашын, тормышка мөнәсәбәтен күрәсең.

Балачак кешене гомере буе озата бара. Шагыйрь һәм әдипләр кечкенә чакта ничек күрүләрен: хыял-уйларын, шатлык-сагышларын, югалту-табышларын үзләренең әсәрләрендә чагылдырмый калмыйлар. Хәтер сукмакларына басып балачакка кайту кеше күңелен нечкәртеп, сафландырып җибәрә. Кешенең балачагы нинди генә авырлыкларга туры килмәсен – ул барыбер күңелдә кайтарып булмаслык югалту буларак хәтерне яңартып тора. Ф. Яруллинның балалар өчен язган шигырьләре, хикәя- повестьлары, әкиятләре укучыларны балачагына кайтара, уйландыра; сагыш рәшәләренә алып кереп китә; күктәге салават күперләре буйлап йөгертә. Аның әкиәтләре моңарчы таныш булмаган серле-тылсымлы дӥньяга алып керә, шаян шигырьләре рәхәтләнеп көлдерә; тирән эчтәлекле хикәяләре дөньяның гыйбрәтле хәлләрен йөрәк аша уздырырга ярдәм итә. Балалар өчен язган әсәрләрендә дә ул җитди проблемалар күтәрә. Өлкәннәрдә була торган барлык сыйфатлар балаларда да бар. Автор тормышта килеп чыккан яки мөмкин булачак проблеманы балалар җаны аша уздырып үз әсәрләрендә чагылдыра.

Шәхес булып формалашу кечкенәдән башлана. Балачактан ук һәр эшне үз ирке белән эшләргә тырышу – ялкаулыкны җиңү дигән сүз. Ихтыяр көчен үстерү, тырышу, кайсыдыр яктан үзеңне күрсәтергә омтылу һәр бала күңелендә дә бар. Нәниләр психологиясен яхшы белгән язучы гына балалар өчен үтемле әсәрләр яза ала.

Бу эшемне башкарганда, мин түбәндәге нәтиҗәләргә килдем: Ф. Яруллинның әсәрләре, дөрестән дә, юмор һәм сатира белән сугарылган. Бәхет беркемгә дә җиңел бирелми. Бигрәк тә, тимер бөҗра белән кыскандай кымшана алмый яткан Фәнис абыйга сәламәт кешеләр белән ярышып эшләр, өметсезлеккә бирелмәс өчен ай-һай нык тырышлык кирәк булган.

Безнең халкыбыз Фәнис абый кебек көчле рухлы кешеләре булганда, беркайчан да йөзен югалтмас!

Ходаның һәр бирмеш көнендә
Бер матур як белән ачылыйк:
Һәркемнең гомере бер генә,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк!

## Әдип иҗатында юмор һәм сатира

Фахриева Алинә, 8 нче сыйныф
Казан шәһәренең “91 нче мәктәбе”
Җитәкче: Тукманова М.Х.

“Халыкның кадерлесе” диләр Фәнис Яруллин турында. Ни өчен кадерле икәнлеге барыбызга да аңлашыла. Ул бөтен гомерен, җанын әдәбиятка багышлый. Язмыш аны гел сынап торса да, Фәнис абый өмет белән алга карап яшәде, тормышка гашыйк, башкаларны да дөньяны яратырга чакырды. Аның иҗаты мәңгелек ут булып яна. Ф.Яруллин шагыйрь дә, прозаик та, драматург та, әкиятләр остасы һәм ялкынлы публицист та. Иҗатының кайсы ягын гына алып карама, аның үзенә генә хас фәлсәфи карашын, тормышка мөнәсәбәтен күрәсең.

Аның шигырьләрен, хикәяләрен бик яратып укыйм. Шуңа күрә дә инде бу эшемне Ф.Яруллинның балалар өчен язган шигырьләрен алып, алдагы юмор һәм сатираны күрсәтәсем килә.

Нәрсә соң ул сатира һәм юмор? Юмор белән сатира арасында байтак уртак яклар бар. Һәр икесе тормыштагы иҗтимагый мөһим кимчелекләрне, кешеләрдәге начар сыйфатларны ачып салалар, ягъни икесе дә тәңкыйть итә.

Шулай да сатира белән юмор икесе бер нәрсә түгел. Аерма нәрсәдә соң? Аерма көлү рәвешендә. Сатирада күбрәк шәфкатьсез көлү өстенлек итсә, юморда дусларча елмаю балкый. Сатира кимчелекләрне яндыра, көйдерә. Юморист каләме исә иптәшләрчә тәнкыйтьли, җитешсезлекләрдән арынырга булыша. Тормыш җибәргән авырлыкларны да артта калдырып, бөтен көчен җыеп, Ф.Яруллин үзенең иҗатында юмор һәм сатираны бик оста файдалана. Ул үзенең иҗатында юмор һәм сатира аша укучыларын әхлакка, белемле булырга, олыларын хөрмәт итәргә өйрәтә.

Шагыйрь укучыларны матурлыкка, яхшылыкка, тормышны сөяргә өйрәтә һәм ул аны бик оста эшли, чөнки шигырьләре юмор һәм сатирага корылган. Ә андый шигырьләрне уку җиңел дә, рәхәт тә. Аның шигырьләре бик тиз хәтердә кала һәм барысы да әхлак тәрбиясе бирүгә юнәлтелгән. Ә бүгенге көндә бу бик мөһим мәсьәлә булып тора. Ул үзенең шигырьләрендә өлкәннәр белән балалар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, сабыйлар дөньясындагы проблемаларны күрсәтә белә. Аның иҗатын усмерләр дә, яшьләр дә, өлкән буын да бик яратып укый. Шуңа күрә сайлап алган теманы актуаль дип саныйм. Юморга корылган шигырьләр укучыларны тәрбияләргә ярдәм итә.

Фәнис Яруллин аеруча хикәя җанрында уңышлы эшли. Аның үзенчзлекле юмор белән сугарылган, тормышчан, заманча, оптимисттик хикәяләре “Һәркемнең үз сукмагы” дигән чираттагы җыентыгына тупланган. Әдипнең поэтик иҗатыннан аерым үрнәкләр рус теленә тәрҗемә ителеп, “Современник”, “Аврора”, “Волга” кебек журналларда һәм Комсомольская правда, Литературная Россия кебек үзәк газеталарында да урын ала килә.

## Фәнис Яруллин һәм аның гаилә дуслары

Хабибуллина Альбина, 8 нче сыйныф
Казан шәһәренең “103 нче мәктәбе”
Җитәкче: Карамова Э.Ю.

Шәхес һәм язучы ... Чын кеше, иҗат кешесе әлеге төшенчәләрне үзендә берләштерә аламы икән? Бәлки, болар бер кешедә параллель рәвештә дә яши аладыр. Чөнки телебездә ул иҗатта бер, ә тормышта бөтенләй икенче кеше дигән гыйбарәләр дә яши.

Фәнис Яруллин үзен беркайчан да бөек шәхес итеп санамаган. Аның фикеренчә бөек затлар ул – Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Хәсән Туфан. Язучы шәхес булыр өчен аның иҗаты һәм шәхесе бербөтен булырга тиеш дип саный: “Язучының иҗаты белән шәхесе кушылып бербөтен төшенчә тудырырга тиеш... Иҗатыннан аны аерып карап булмый”. Әдип

фикеренчә, үзенең укытучылары Г.Тукай, М.Җәлил, Х.Туфан әнә шундый фигуралар булып торалар.

Әлеге ике төшенчә Фәнис Яруллинның үзендә бербөтенме? Күңелне борчыган сорауга җавап табу өчен язучының замандашларының төрле елларда әйтелгән фикерләренә тукталып үттем.

Элеккеге президентыбыз М.Шәймиев аны ышаныч чыганагы дип атый, аны күренекле классик язучыларыбыз белән бер баскычка куя, олы хөрмәтен күрсәтә.

Классик язучыбыз Гомәр ага Бәширов аның тырышлыгына, үҗәтлегенә соклана, батыр, фидакарь иҗатына куана.

Үз заманында күренекле шагыйребез Ш.Галиев перспективалы иҗатына, ихлас холкына, чиста күңеленә сөенә.

Равил Фәйзуллин да аны нык каләмле, киң колачлы язучы дип атый. “Фәнис Яруллин – төрле жанрларда уңышлы иҗат итә торган нык каләмле, киң колачлы язучы... Бөтен язганнарын җентекләп беләм дип әйтә алмыйм, әмма шигъри әсәрләрен эзлекле күзәтеп барам. Зур шагыйрь ул! Тормышчан шагыйрь, кешеләр өчен кирәк шагыйрь”. Равил Фәйзуллин. Татарстанның халык шагыйре. 1999.

Рәдиф Гаташ исә аны пәйгамбәрләргә тиңли, татар көченең дәвамы итеп күрә, газаплар аша әдәбиятка килүен чистарыну, күңел матурлыгына ирешү дип атый.

Кайсы гына шәхеснең фикерләрен алма: элеккеге президентмы, күренекле язучымы, галимме, тәнкыйтьчеме, мәртәбәле кешеме – барысы да Фәнис абый Яруллинга сокланып, зур ихтирам белән карыйлар. Тормышта да, әдәбиятта да аны үрнәк итеп куялар. Аның тормыш батырлыгын иҗатыннан аерып карау һич мөмкин түгел. Аның әсәрләрен халкым яратып укый, Ф.Яруллин шәхесен үзенә өлге итеп ала.

## Фәнис, син – сүнмәс йолдыз

Хайбуллова Әдилә, 8 нче сыйныф
Чүпрәле районының “Кече Чынлы мәктәбе”
Җитәкче: Низамова Э.А.

Татар әдәбияты меңьеллык әдәби мирасы, бай язу культурасы, стиль үзенчәлекләре, жанрлар төрлелеге белән бөтен дөнья мәдәниятенә зур өлеш керткән әдәбият. Менә шушы бай мираслы әдәбиятка өлеш кертү юнәлешендә зур көч куйган әдипләр арасында Фәнис Яруллин да бар.

Фәнис Яруллинга әлеге бөеклекләр яуларга кемнәр ярдәм иткән соң? Алар шагыйрь турында нинди фикердә? Шушы сораулар безгә фәнни-тикшеренү эше белән шөгыльләнергә этәргеч ясадылар.

Безнең сайлаган темабыз: “Фәнис, син – сүнмәс йолдыз”. Фәнис Яруллинның замандашлары, аның белән бергә иҗат иткән каләмдәшләре бик күп. Аның авыр тормышында аңа ярдәм итүчеләр бик күп булган. Шулар арасыннан безгә Фәнис Яруллинның Туфан Миңнуллин белән мөнәсәбәте аеруча ошады. Туфан Миңнуллин шагыйрьнең замандашы да, каләмдәше дә, ярдәмчесе дә.

Әлеге теманың актуальлеге шунда: без Ф.Яруллинның иҗаты белән күпмедер дәрәҗәдә дәреслекләрдә танышабыз, ә аның Туфан Миңнуллин, авылдашлары, туганнары белән мөнәсәбәте турында белмибез. Шуны күздә тотып, без түбәндәге максатны куйдык:

- Ф.Яруллинның замандашы Туфан Миңнуллин аның турында нинди фикердә булуын билгеләү;
- авылдашларының, туганнарының Фәнискә карата мөнәсәбәтләрен ачыклау.

Максатка ирешү өчен, бурычлар билгеләдек:

1.Ф. Яруллинга язган хатлар белән танышу.

2.Автограф язып бирелгән китаплардагы теләкләргә күзәтү ясау.

3.Ф. Яруллинның Т.Миңнуллин белән булган мөнәсәбәте турында мәгълүмат туплау.

Әлеге максатка ирешү өчен мин Фәнис Яруллинның “Сөенечләр бүлешү”, “Хәтер төпләрендә утлы күмер” китаплары белән танышып чыктым. Шулай ук, Гөлчәчәк Галиеваның “Күңелемә якын затлар” китабы, Туфан Миңнуллинның “Фәнис, син миннән әйбәтрәк” мәкаләсе дә ярдәм итте.

Без яраткан шагыйребез, язучыбыз, драматургыбызга ярдәм кулы сузган, файдалы киңәшләрен биргән барлык шәхесләргә дә тукталып китмәдек. Алар бик күп. Безнең тукталган шәхесебез берәү булды: ул – Туфан Миңнуллин.

Туфан Миңнуллин Фәнис Яруллинга драматург булып үсеп китәргә ярдәм итә, драма әсәрләрен язу буенча төпле киңәшләрен бирә. Үзеннән дә югары булырлык дәрәҗәгә җиткерә. Һәрвакыт аның күңелен үстерә. Алар һәрвакыт аралашып яшиләр, иҗат планнары, эшләгән эшләре турында фикер алышалар. Туфан Фәнис Яруллинның зур таянычы, киңәшчесе була.

## Җыр калдырыйк

Хасбиева Амелия, 7 нче сыйныф
Казан шәһәренең “103 нче мәктәбе”
Җитәкче: Зиатдинова Н.В.

Язучы һәм шагыйрь, прозаик Фәнис Яруллин иҗаты һәм тормыш юлы белән мин узып киткән 2019 нчы елда таныша башладым. Интернетта минем күземә бер шигырь чалынды. Бу искиткеч юлларның авторы Фәнис Яруллин иде! Мин шуннан соң бу шагыйрьнең иҗаты, тормыш юлы белән кызыксына башладым. Аның сүзләренә язылган җырлар бар икәненә игътибар иттем. Ф.Яруллинның тормыш юлы да бик аянычлы булып чыкты, ләкин ул үзендә Николай Островскийга хас ихтыяр көче табып, бәхетле, нәтиҗәле гомер юлы узган.

Ф.Яруллин сүзләренә язылган җырларны тупладым. Барлыгы 41 җыр таптым. Бу җырларга башкаручылар, популярлык һәм тематикасы буенча нәтиҗәләр ясарга тырыштым.

Татар халкы элек-электән җыр-моңга бик хирыс булган. Иң каты бәгырьлеләрне дә елатырга, нечкәртергә сәләтле ул җыр. Ф.Яруллин “Матур җыр ул, көчле дару кебек, йөрәкләргә үтә туп-туры...” – ди.

Кайсы җырчылар аның җырларын башкаралар, кемнең репертуарында Ф.Яруллин җырлары күбрәк булуын ачыкларга тырыштым. Гөлнара Тимерҗанова репертуарында Ф.Яруллин сүзләренә язылган 9 җыр бар. **“**Бөек шәхес, арабыздан киткән шагыйрь Фәнис Яруллин белән элемтәдә идем... Ул «Мәхәббәт ялкыны» җырын иҗат итеп бирде. Бу җыр белән мин сәхнәдә беренче олы адымнарымны ясадым. Фәнис абый язып калдырган күп җырларны башкарам, алар аның рухына дога булып барып ирешсен иде”,– дип сөйли Гөлнара Тимерҗанова Әлмәт район газетасына биргән әңгәмәсендә.

Классик җырчылар башкаруында җырлар тапмадым, ә Татарстанның халык артисты Асаф Вәлиев аның ике җырын, Рәсим Низамов бер җырын башкара. Лилия Хәйруллина, ИлГәрәй кебек яшь җырчыларның да җырлары популяр.

Шулай итеп, Ф.Яруллин иҗаты белән яшь җырчыларыбыз да кызыксынып тора дигән нәтиҗә ясап була.

Җырларда нинди тематика өстенлек алганын ачыкларга тырыштым. Әлбәттә, мәхәббәт, ярату – төп тема. Җавапсыз мәхәббәт, сөйгән кешесен сагыну, яраткан кешесенең янында булуына шатлану, яраткан кешесенең күңелен ничек яулап алырга теләү һ.б. шундый хисләрне ачыкларга була.

Безгә әле киләчәктә дә яңа җырлар ишетергә насыйп булыр. Аның шигъри тәлгәшләренә иҗат ителгән җырлар бөтен татар дөньясына йолдыз булып сибелгән һәм сибеләчәк тә.

## Татар балалар әдәбиятын үстерүдә Фәнис Яруллин иҗатының роле

Шайдуллина Зилә, 7 нче сыйныф
Арча районының "Лесхоз урта мәктәбе"
Җитәкче: Фахриева Р.Т.

Хезмәтемнең максаты: Фәнис Яруллинның балалар өчен иҗатын өйрәнү. Ф.Яруллинның әсәрләрен өлкәне, кечесе үзе өчен язылган дип укый. "Җилкәннәр җилдә сынала", "Яралы язмышлар" повестьларын һәм бихисап шигырь һәм хикәяләр әйтергә мөмкин.

Ф.Яруллинның балалар өчен язылган шигырьләре, хикәя-повестьлары, әкиятләре укучыны балачагына кайтара, уйландыра; сагыш рәшәләренә алып кереп китә; күктәге салават күперләре буйлап йөгертә. Аның әкиятләре моңарчы таныш булмаган серле-тылсымлы дөньяга алып керә, шаян шигырьләре рәхәтләнеп көлдерә; тирән әчтәлекле хикәяләре дөньяның гыйбрәтле хәлләрен йөрәк аша уздырырга ярдәм итә. Балалар өчен язган әсәрләрендә дә ул җитди проблемалар күтәрә. Өлкәннәрдә була торган сыйфатлар балаларда да бар. Автор тормышта килеп чыккан яки мөмкин булачак проблеманы, балалар җаны аша уздырып, үз әсәрләрендә чагылдыра.

Бала өчен ана – иң кадерле газиз зат. Шушы олы хисне, ата-анага булган мәхәббәтне бала күңеленә гомергә сеңдереп калдырырга теләгән әдип шигъриятендә тәрбияче ролен дә оста файдалана. Гадәттә, балалар шаян телдә, кызыклы сюжетка корылган әсәрләрне ныграк ярата һәм аларны күңеленә тизрәк сеңдерә. Ф.Яруллинның шаян шигырьләре бар. Шаянлык, баланы көлдерү аның өчен үзмаксат түгел: әдип көлү аша берәр кимчелекне ача (физик кимчелекне түгел), начар гадәтнең аяныч хәлдә калдырырга мөмкин икәнен искәртә. Нәни герой һәр очракта диярлек ачышны үзе ясый. Авторның тел очында шаян сүз булса, әсәрнең нигезендә яшәү фәлсәфәсе ята.

Ф.Яруллинның балалар әдәбиятына караган "Язмышлар язылганда" һәм "Яшел утрау хуҗалары" исемле ике повесте бар. Аларның икесендә дә геройларның тормышка мөстәкыйль булырга, үзләренең сорауларына үзләре җавап табарга, ягъни яшәү серләренә үз акыллары белән төшенәсе килүләре сурәтләнә.

Язучының балалар өчен иҗатының тагы бер тармагын әкиятләр хасил итә. "Зәңгәр күлдә ай коена", "Өе балчык – иясе карчык", Биюче бака" һәм "Серле дөнья" китапларында әкиятләр тупланган. Автор үз әкиятләрендә иң мөһим нәрсә итеп физик көчне түгел, әхлакый сафлыкны, намусны һәм вөҗданлылыкны куя.

"Яралы язмышлар" – мин бу повестька тукталмый китә алмыйм. Алда әйткәнемчә, әсәрне өлкәннәр дә, балалар да үзләре өчен язылган дип кабул итә ала. Мин эшемә материал туплаганда шушы шәхес белән бәйле кызыклы мәгълүматка тап булдым. Бу әсәрдәге төп герой – Миңлегөл Рәфыйкова, минем якташым булып чыкты. Ул ихтирамга лаеклы, мәрхәмәтле, олы йөрәкле шәхес. Мин шундый якташым белән чиксез горурланам. Ул районыбызның Курса-Почмак авылында туган, аны "Арча Терезасы" дип йөрткәннәр. Ф.Яруллинның үзенчәлеге тирәнтен фикер йөртә, гап-гади тоелган тормышыбызда бик күп матурлыклар, тирән фәлсәфәләр, катлаулы вакыйгалар яшеренеп ятуын чын рәссам каләме белән сурәтләп бирә белүдә. Талантлы әдип әсәрләрендә бик мөһим әхлак мәсьәләләрен хәл итә, киләчәк буын хакында борчылу, аларны әхлаклы, кешелекле итеп тәрбияләү, милләтебезнең киләчәген бәхетле итеп күрергә теләү ята. Ул гади кешеләрнең күңелләрендә йөреп тә, аларны тышка чыгара алмаган гыйбрәтле вакыйгаларны, тетрәндергеч язмышларны, беренче карашка сәер күренгән кешеләрне әсәрләренә герой итеп алып, аларның күңел төпләрендә яшеренеп яткан энҗеләрен күрсәтте. Аның иҗаты балалар әдәбиятында үз урынын, һәрбер әсәре үз укучысын тапты.

## Җыр калдырыйк җирдә, нур калдырыйк

Шакирова Диләрә, 5 нче сыйныф
Казан шәһәренең “103 нче мәктәбе”
Җитәкче: Рамазанова Г.Ф.

Җыр дип әйтүгә, күңелгә билгеле сүзләр һәм көй килә. Фәнис Яруллин махсус җырлар язучы шагыйрь түгел. Композиторлар көйләрне әдипнең китапларында урын алган шигырьләренә яза. Шагыйрь, шигырь китапларына җырларын керткәндә, еш кына җәя эченә “җыр” дип тә билгели. Мәсәлән, “Бер генә”(җыр), “Умырзая” (җыр). Мин Фәнис Яруллин сүзләренә, спектакльләренә язылган 70 кә якын җыр таптым. Поэзиядә Фәнис Яруллинның төп жанры лирика булса, аның җырларын лирик җырлар тәшкил итә. Аларда сурәтләнгән темалар да күп төрле. Җырлар дуслыкка, мәхәббәткә, яшьлеккә, тормышка, туган җиргә багышланган.

Төрле композиторлар белән иҗади эшләү нәтиҗәсендә бер-берләрен кабатламый торган яңа җырлар дөньяга килгән. Шагыйрь Фасил Әхмәтов, Фәрит Хатыйпов, Илгиз Закиров, Оскар Усманов, Риф Гатауллин, Марат Мухин, Гөлнара Тимерҗанова һәм башка композиторлар белән хезмәттәшлек итә. Ф. Яруллин спектакльләренә язылган көй авторлары белән танышып үтик. “Әнә килә автомобиль” спектакленә композитор Хөснул Вәлиуллин, “Сөембикә егет сайлый” спектакленә композитор Фуат Әбубәкеров, “Бер күрешү-үзе бер гомер”, “Кызлар күңеле-тирән сер” спектаклләренә композитор Мәсгүт Имашев көй язган. Шулай ук төрек, үзбәк, һинд, казах халык көйләренә язылган җырлар халык арасында популярлык казана. Фасил Әхмәтов Фәнис Яруллин шигырьләрен башта ятлый, кабатлап йөри, аннан соң җыр туа. “Кем елый анда?”, “Ташлама мине”, “Мин синеке бары синеке”, “Бирмә мине беркемгә дә” җырлары шундый иҗади дуслыкта языла. Укытучылар мине әдәбиятка алып керде”,– дип яза Фәнис Яруллин. Сабыр һәм акыллы укытучыларга багышланган “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” дигән шиырен яза, композитор Әхмәт Хәйретдинов аны көйгә сала. Шагыйрь Фәнис Яруллин татар җыры, татар моңы аша телгә карата мәхәббәт уята.

Фәнни эш барышында, куелган максатыма ирештем дип уйлыйм. Татар халкының горурлыгы булган Фәнис Яруллин турында бик күп материал тупланылды. Без, шул әсәрләрне укып, үзебезгә рухи көч алабыз, алар белән сокланабыз.

## II. Укучылар иҗаты

### Туган як

Абдрахимова Азалия, 6 нчы сыйныф
Буа районының “Аксу мәктәбе”
Җитәкче: Хайруллина Р.Ф.

Туган як, син, әй, гүзәл як!
Синдә генә йомшак җил исә,
Синдә генә ләйсән яңгыр ява,
Синдә генә матур гөл үсә.
Туган якта гына дөнья матур,
Шундый матур булып тоела.
Сандугачлы урманнары шаулый,
Дус-туганнар шунда җыела.
Туган якта әти-әни яши,
Нигезләрен шунда корганнар.
Нәсел дәвамымны калдырам дип,
Шәһәрләргә китми калганнар.

### Республикам – Татарстан

Акчурина Найлә, 10 нчы сыйныф
Казан шәһәренең “А.С Умеркин исемендәге 116 нчы лицее”
Җитәкче: Ахмадуллина Э.Т.

Шәһри Казан – башкала.
Илкәемнең һәр иртәсе
Якты таңнан башлана.
Тукай эзе Казанымда,
Туган телем – көзгесе.
Чал тарихта сихри дөнья –
Узганы, бүгенгесе.
Татарстан – горурлыгым!
Киләчәккә ышанам.
Үз телемнән, үз илемнән
Илһам алам, көч алам.
Туган телем – татар теле,
Телләрнең иң гүзәле.
Туган телем – иркә гөлем
Милләтнең син бизәге.
Туган телем – газиз телем
Син – минем бердәнберем.
Горурланып кабатлыйм мин.
Чөнки син – газиз телем.

## Әнием

Ахметзянова Зилия, 8 нче сыйныф
Зәй районының “Чыбыклы мәктәбе”
Җитәкче: Мурзина Г.М.

Әнием, күз нурым,
Син бердәнберем, нурым.
Күңел назым сиңа биреп,
Сине котлый  кече кызың.
Якты кояш нурлары,
Күтәрсен күңелеңне.
Бүген бәйрәм, матур бәйрәм,
Бүген – әниләр көне.
Бәхет килсен күңелеңә,
Котлый сине барсы да.
Бәйрәм сәламнәрем сиңа
Гөлләр булып барсын ла.
Көн дә мине уята,
Сыйпап назлы куллары,
«Бәхетле бул балам,»– ди,
Якты аның уйлары...

## Митрәй гармуны

Ахметзянова Ясминә, 10 нчы сыйныф
Казан шәһәре “179 нчы гимназия-белем үзәге”
Җитәкче: Ахметзянова А.Ф.

Безнең өйнең түрендә ике гармун бар. Берсе – татар тальян гармуны, икенчесе – Митрәй гармуны. Иртәнге кояш үзенен алтын юлын шул гармуннарга сузган. Әйтерсен: “Вакыт уза, сөйләт бабаңнан ике гармун язмышын!”– ди кебек. Ни өчен Митрәй гармуны? Менә хәзер дә бабам шул Митрәй гармунында тын гына “Катюша” көен суза. Күзләре дымлы, иреннәре нидер пышылдап ала. Гармун күрекләре белән бабаем кулындагы сырлар бер яшьтә сыман. Һәр сыр, һәр күрек авыр сугыш чорын моңнарга төреп, безгә сөйли кебек...

Бабам, күзләрен йомып, бераз уйланып утырды да, гармунын чиккән мендәр өстенә куеп, мине кочагына алды.

– Тыңла, кызчыгым, шаян йолдызым,– дип, үзе белән мине авыр сугыш елларына алып кереп китте.

Кечкенәдән табиб булырга хыялландым...

## Дуссызлык

Ахметшин Гаяз, 9 нчы сыйныф
Казан шәһәренең “7 нче интернат-лицее”
Җитәкче: Мансуров А.И.

Инде күпме еллар үтте,
Аерылды безнең юллар,
Суга башын игән таллар,
Безне жәйләр буе уйлар.

Икәү бергә йоргән идек,

Өстен китереп аска.
Исебездә һәрчак тоттык,
Начарын башкармаска.

Уйларымнан һаман китми,
Кулым каты кысуың.
Киң юлларда аңладым мин,
Дуссыз чакның моңсуын.

## 41 нең ябык балалары

Валиев Хәлил, 8 нче сыйныф
Арча районының "Утар-Аты мәктәбе"
Җитәкче: Касимова З.Г.

Сугыш салкыны искән авыр еллар,
44 нең матур бер көзе...
Чал тарихның тормыш битләрендә
Уелып ята яшь малайлар эзе.

Кай төшләрдә эре-эре атлап,
Ә кайвакыт туктап, таптанып,
41 нең ябык малайлары
Белем алган тырышып-тырмашып...

## Татарстан

Вафина Таңсылу, 8 нче сыйныф
Яңа Чишмә районының "Зирекле лицее»
Җитәкче: Газимова Р.М.

Туган ягым – Татарстан
Иң матур җир дөньяда.
Табигате дә искиткеч,
Елга,тугай, дәрьлар.
Сугыш кебек явыз эшләр
Булмасын илебездә.
Гел-гел кояш көлеп торсын
Зәп-зәңгәр күгебездә
Язлар саен кошлар килсен,
Сандугачлар сайрасын.
Безнең газиз илебездә
Тынычлык хөкем сөрсен.

## Сак булыгыз юлларда!

Габделбаров Ислам,7 нче сыйныф
Саба районының "Рост Шемордан лицее»
Җитәкче: Валиуллина Г.Р.

Җәйге матур бер көндә,
Саф һавалы иртәдә

Ике куян баласы
Юл тоттылар шәһәргә.
Бара торгач ардылар,
Аяклары талдылар.
Әниләрен сагынып,
Бераз елап алдылар.
Берсе әйтә: “Кайтыйк,” – ди,
Икенчесе: “Барыйк!” – ди.
“Ярты юлдан борылу -
Егет эше түгел,” – ди...

## Яңгыр

Габдрахманов Инсаф, 6 нчы сыйныф
Арча районының “Д.Г.Хакимов исемендәге Түбән Мәтәскә мәктәбе”
Җитәкче: Габдрахманова Н.Ш.

Яңгыр ява, яңгыр ява
Көне-төне туктамый.
Без аңардан туйдык инде,
Ул туктарга уйламый.
Урамга да чыгып булмый,
Өйдә генә торабыз.
Иртәгә туктар әле дип,
Көн дә план корабыз.

Бүген иртән торган идек,
Урамда яңгыр беткән.
Бик күп эшләп арыгандыр,
Яңгыр йокларга киткән.

## Кечкенәдән шигырь язам…

Гатауллина Кәмилә, 7 нче сыйныф
Казан шәһәренең “40 нчы гимназиясе”
Җитәкче: Хикматуллина Р.Ф.

Автор хыял диңгезләрендә йөзәргә, уйланырга ярата. Шигырьләр укырга, язарга ярата, бигрәк тә татар халкы әдипләренең әсәрләрен:

Балачактан - Тукай, Җәлил,
Кутуй, Алиш, Яруллин...

Ул аларның иҗаты белән соклана. Татар халкының әдипләре күп булуы белән горурлана:

Бөек татар халкыбызның
Йолдызлары бик тә күп!
Аларны үзе өчен үрнәк итеп куя:
Һәрберсе барыр юлымда
Торалар үрнәк булып.

Кечкенәдән шигырь язам,
Багышлыйм әдипләргә

Алдан әсәрләрен укыйм,
Сөйлим өйдәгеләргә.

Әйтә алмам сорасагыз
Кем күбрәк ошый диеп,
Бар шагыйрь, язучыларны
Укыйм куңелемне биреп...

## Хыял

Давлетшина Алия, 10 нчы сыйныф
Әлки районының “Алпар мәктәбе»
Җитәкче: Сафиуллина Г.А.

Шигырь язу өлкәсендә үземне сынап карау максаты белән Татарстанның халык шагыйре Фәнис абый Яруллин шигырьләрен укыганнан соң туган хисләремне белдерәм.

Фәнис абыйның иҗаты укучыларны шәфкатьлелеккә, мәрхәмәтлелеккә, кешелеклелеккә өйрәтә. Аларны укыган саен укыйсы килә. Аның шигырьләрен өйрәнгән укучылар үзләрендә бары тик яхшы сыйфатларны гына булдырырга тырышалар. Шигырьдә ул күтәргән проблемалар бүген бик актуаль.Фәнис абыйның иҗатын барлык кешеләр дә яратып өйрәнсен иде.

Хыялланам: җырлыйм, көләм,
Әллә ниләр башкарам.
Бакчада гөлләр үстерәм,
Комнан шәһәрләр салам.

Биеклеккә омтылучы
Канатлы кошчык кебек.
Әллә ниләр башкаргандай,
Уйлый, талпына күнел.

Хыял мине җилкендерә,
Каядыр әйди һәрчак.
Хыял бит ул – үзе бер җыр,
Йөрәкләрдә калачак.

## Шагыйрь бәхете

Зайдуллина Ләйлә, 10 нчы сыйныф
Казан шәһәренең “145 нче лицее”
Җитәкче: Шайхутдинова Р.С.

Кеше җиргә бәхет өчен туа,
Кайда икән шагыйрь бәхете?
Кулдан-кулга, өйдән-өйгә йөреп,
Ятимлектә үткән гомере.

Сынаса да язмыш төрле яклап,
Сыгылмаган Тукай, сынмаган.
“Халкым өчен”– диеп ул тырышкан,
Мәктәп-мәдрәсәләрне ачышкан.

Бала күңелендә шигырьләре,
Әкиятләрен укый сабыйлар,
Күрәсезме, халкым ничек зурлый,
Киләчәктә әле олылар...

## Эзләр

Закирова Илвина, 10 нчы сыйныф
“Әгерҗе шәһәренең 1 нче гимназиясе”
Җитәкче: Закирова Г.И.

Яшьләр арасында татарча матур, дөрес сөйләмгә игътибар кимегән чорда, күңелдә булган соклану, ярату, шатлану, борчылу кебек хисләрне шигырьләр аша башкаларга да күрсәтү актуаль. Һәр кеше үзенчә сәләтле. Җиргә беренче ак кар төшкән көн. Ясый белсәм, бәлки, рәсемгә төшерер идем. Ә минем күңелгә шушы юллар килде. Кечкенәдән үк шигырьләр укып, үзең дә каләм тибрәткәндә, сүз тәмен аңларга өйрәнәсеңдер инде ул. Шигъри дөньям – сихри дөньям ул минем.

Җирдә ап-ак кар, карда эзләр бар.
Әти эзе бар, әни эзе бар.
Бабакай эзе, әбекәй эзе,
Сынап карый күк аларның күзе.
Абыйның эзе, апаның эзе,
Мин дә калдырам үземнең эзне.
Туган илемдә салам эзләрне.
Туган телемдә әйтәм сүзләрне!

## Мин тормышка гашыйк

Зиганшина Әминә, 6 нчы сыйныф
Казан шәһәренең “30 нчы мәктәбе”
Җитәкче: Ахмаева Э.З.

Шагыйрь укучыларны матурлыкка, яхшылыкка, тормышны сөяргә өйрәтә. Һәм ул аны бик оста эшли, чөнки аның шигырьләре юмор һәм сатирага корылган. Ә андый шигырьләрне уку җиңел дә, рәхәт тә. Аның шигырләре бик тиз хәтердә кала һәм барысы да әхлак тәрбиясе бирүгә юнәлтелгән. Үземнең иҗат ителгән шигырьдә дә Ф.Яруллиның тормышка мөнәсәбәтен, тормыш сынауларына бирешмәвен сурәтләргә тырыштым.

Фәнис Яруллин кеше буларак та, шагыйрь буларак та бәхетле кеше. Чөнки ул үз девизына тугры. «…Нинди генә очракта да җиңәргә өйрән. Көчле рухлылар гына максатларына ирешәләр. Түземлеләр генә бәхеткә лаек».

Бу тормышта безгә һәрчак,
Кыю булырга кирәк.
Ничек кыю булыйм диеп,
Уйлап торырга кирәк.
Бу нисбәттән Фәнис абый,
Безгә һәрчак үрнәк ул.
Ихлас сөйде бу дөньяны,
Гомер безгә бүләк ул.

## Авылыма

Ибрагимова Фирүзә, 7 нче сыйныф
Яңа Чишмә районының“Чаллы-Башы мәктәбе”
Җитәкчеләр: Замалетдинова Л.И.,Мингачева Л.Ф.

Бер җирдә юк синдәй гүзәл авыл,
Нинди бәхет синдә тууым.
Син җиремнең йөзек кашы сыман
Чаллы Башы – туган авылым.
Җиде буын бабам кабере шунда,
Тәпи атлап киткән сукмагым.
Йөрәгемә якын булган җир бу
Башка беркайда да булмастыр.
Туган нигез чишмә кебек изге,
Яшел чирәм – тоташ бер келәм.
Киләчәге аның якты булыр,
Матур булыр – шуны мин беләм.

## Туган телем минем!

Каримов Гайсә, 8 нче сыйныф
Теләче районының “Олы Нырсы мәктәбе”
Җитәкче: Фадеева Г.Х.

Туган тел! Бу сүз һәркем өчен кадерле, газиз! Тел – ананың балага зур бүләге. Кешегә нәселнең, халкының асыл сыйфатларын иң әувәл тел тәме, тел кодрәте ярдәмендә ана бирә. Туган телне белү кирәк, чөнки туган телдә синең әби-бабаларың, әти-әниләрең, халкың сөйләшкән һәм сөйләшә. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен дә туган телен кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү – һәр кешенең изге бурычы.

Минем туган телем – татар теле. Минем өчен татар теле кадерле һәм газиз, чөнки без – татар балалары. Татарча минем телем ачылган, татача бишек көйләре, әкиятләр тыңлап үстем.

Туган телем минем – җырлы бишек!
Сабый чактан мине үстергән.
Хыял дөньяларыма ачык ишек,
Яшәү өчен миңа көч биргән.
Туган телем минем – тәрбиячем!
Бай тәҗрибәсе булган чын остаз.
Тормыш китапларын язган хикәячем,
Синең китабыңа бүген мин мохтаҗ…

## Туган ягым

Максимов Евгений, 9 нчы сыйныф
“Сәламәтлеге чикләнгән балалар өчен 9 нчы Зәй мәктәбе”
Җитәкче: Хайретдинова Р.Җ.

Туган якның матурлыгын Г. Тукай сурәтләгәнчә тасвирлап шигырь язуны максат итеп алдым. Урманга җәй көне сәяхәткә чыгып, авыл табигатен күреп, шигъри юлларга салуны бурычларым итеп алдым.

Мин шигыремне “Туган ягым” дип атадым. Шигырьнең структурасы шигырьнең атамасыннан һәм уналты юллыктан тора. Беренче дүртьюллык Тукай бабай туган ягын үземнең туган авылым белән чагыштырдым. Безнең якларда чишмәләр күп. Мин тәмле чишмә суын эчеп үстем. Чыннан да безнең яклар Габдулла Тукайның Кырлае белән охшаш.

Безнең якка нинди охшаш икән,
Тукай бабай туган ул яклар.
Чишмәсе дә, урман-кырлары да,
Авылы да нинди охшашлар!

Икенче дүртьюллыкта урманнарга игътибарны юнәлттем. Мин үзем яз җитү белән табигать нигъмәтләрен авыз итәм, урман һавасын сулыйм, сәламәтлеккә сихәт алам.

Юкә, каеннары шул ук аның,
Бездәгедәй үсә төз нарат.
Киек-җанвар, бөрлегәннәр шул ук,
Бездә дә күп җиләк, кузгалак.

Өченче дүртьюллыкта Кырлай авылы табигате белән чагыштыруны дәвам итеп, халык герое Шүрәлене искә алдым. Тукай бабай Шүрәлене ачкан. Минем дә Шүрәле кебек үз героемны ачасым килүен сурәтләдем, бу чыннан да шулай, мин моның турында күптән хыялланам.

Тик шунысы гына үзгә бераз,
Безнең якта юк бит Шүрәле?!
Бәлки бардыр безнең якларның да,
Ачыласы ягы күп әле.

Туган якны ярату хисе эти-әни, сөекле шагыйрем Тукай бабай белән күчкән. Ни өчен “Тукай бабай” дидем, аңа карата хөрмәтем бик зур, чөнки телем Г.Тукай шигырьләре белән ачылды. Мин туган телем татар телен бик яратам.

Туган якны сөю серен,
Тукай бабай салган күңелгә.
Ачылмаган серле почмакларны
Мин ачармын, бәлки, кем белә?!

Мин кузгаткан туган як темасы һәрвакыт бик актуаль, чөнки туган ягы гына кешегә илһам бирә. Әгәр туган як эзләнер өчен һәрдаим мөмкинлекләр бирә икән, бу бик яхшы. Ә мин һәрвакыт эзләнүдә. Г. Тукайдан әле миңа бик күп нәрсәгә өйрәнәсе бар.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсем килә, мин шигырь юлларын яза башлаганда, бик дулкынландым. Эшем бик эчтәлекле булдым. Шигырьне язып бетергәч, мин бу эшемнән канәгатьлек кичердем.

## Горурлыгым минем - Кукмарам!

Мустафина Йолдыз, 11 нче сыйныф
Кукмара районының “А.М.Булатов исемендәге күппрофильле лицее”
Җитәкче: Гарипова Л.Г.

Бүгенге көндә кешеләрнең, аеруча яшүсмерләрнең зур шәһәрләргә китергә омтылуы, байлык, акча артыннан куып чит җирләргә китеп баруы бик актуаль мәсьәләгә әйләнеп бара. Бу шигырь аша мин туган җирнең табигый матурлыгын, үзенчәлеген тасвирлап күрсәтергә тырыштым.

...Ялан тәпи йөргән болыннардан,
Җиләкләрнең җыям кызылын,
Шушы җирдә туган, суын эчкән,

Шушы төбәкнең гади кызы мин.
Зурлыйм сине бүген, туган төбәк,
Күңелемә якын, газиз җирем,
Кошлар да багышлыйдыр бүләк итеп,
Иң матур, иң моңлы назлы җырын.
Мәңге гөрлә, дан казанып, и, районым,
Горурланып яшик без монда,
Сиңа хезмәт итәрбез дип, ышандырып кала,
Синдә туып үскән кыз һәм уллар...

## Иң куркыныч сүз

Набиуллина Гөлназ, 7 нче сыйныф
Арча муниципаль районының "Сизин мәктәбе"
Җитәкче: Набиуллина Г.Р.

Җәйге иртә. Кояш чыгып килә,
Уяндылар чебен-черкиләр.
Үзләренә урын таба алмый
Әрле- бирле очып йөриләр.
Урман ягыннанмы, болыннанмы –
Өзеп-өзеп сайрый бер чыпчык.
Сайраулары бигрәк үзәк өзгеч,
Никтер үзгә сайрый ул кошчык.

## Әбиләргә – кунакка

Нугуманов Булат, 4 нче сыйныф
Казан шәһәренең "103 нче мәктәбе"
Җитәкче: Хафизова А.В.

Менә көтеп алынган яңа ел каникуллары җитте.

Без, әниләр белән, әбиләргә авылга кайтырга җыенабыз. Без әби янына ике атнага китәчәкбез.

Менә юлга чыктык. Юл әле озак булачак. Мин инде әбинең авылы турында уйлый башладым. Уйлап карасаң, мин бит, балачагымның яртысын анда үткәрдем. Мин үзем Казан кызы булсам да, авылны бик яратам, һәр каникулымны авылда уздырырга тырышам. Безнең авылның табигате бик матур, кешеләре яхшы күңелле. Анда минем яраткан әбием белән бабам яши.

Бер заман, шуларны уйлап ятканда, мин кинәт кенә йокыга талганмын... Бераздан мине әниемнең тавышы уятты:

– Тор кызым, килеп життек! Мин шундый шатландым! Минем инде күптән әби-бабай белән күрешкәнем юк. Биш минут үткәч, без килеп җиттек.

Урамда кыш, һава шундый чиста, саф, сулап туеп булмый! Агачлар ап-ак бәскә төренгән, урамга кар көртләре өелгән, өй түбәләрен кар сарып алган! Каршыдагы тау битендә балалар чаңгы-чана шуалар! Без шушы матурлыкка сокланып торган арада, капка ачылып китте һәм аннан иң беренче булып, Акбай йөгереп чыкты, аның артыннан ашыга-ашыга чыгып килуче әби белән бабай күренделәр. Без алар белән шатланышып күрештек. Безне күргә Акбай да бик шат иде. Ул койрыгын болгый-болгый безнең белән күреште. Менә өйгә кердек. Мин тиз генә әбиемнең чәен эчәргә һәм иптәш кызларым янына тау шуарга барырга ашыктым.

Эх, яратам мин кышкы авылны!

## Әнкәем

Нуризянова Азалия, 7 нче сыйныф
“Адымнар-Казан полилингвиаль комплексы”
Җитәкче: Габдрахманова Р.А.

Өебезне гүя нурга күмеп
Әнкәем син шаян көләсең.
Нинди матур толымнарың, диеп
Чәчләремнән сыйпап сөясең.

Ерак юлга безне озатканда
Изге теләк теләп каласың.
Олы юлдан күзең алалмыйча
Һаман безне карап таласы...

## Әниемә булышам

Окунева Аделина, 10 нчы сыйныф
Алабуга районының “10 нчы урта мәктәбе”
Җитәкче: Әхмәтова Р.З.

Эшләргә йорт эшләрен
Күптән инде тырышам.
Үз эшләрем булса да,
Әниемә булышам.
Ашарга пешергәндә
Кишер,суган турашам.
Бәрәңгене тиз әрчим,
Савыт-сабаны юам.

Бераз суы саркыгач,
Урыннарына куям.
Гөлләргә сулар сибәм,
Тизрәк үссеннәр, диям.
Тузаннарны да сөртәм
Идәнне юып үтәм.
Өебез ямьле булсын,
Тормышлар имин торсын!

## Аякларым кадакланган минем...

(Фәнис Яруллинга багышланган шигырь)

Сагитова Нурзилә, 9 нчы сыйныф
“В.Г.Тимирясов исемендәге 1 нче Аксубай мәктәбе”
Җитәкче: Галиева А.А.

Аякларым кадакланган минем,
Кулларым да каләм тотмыйлар.
Күпме генә килсә дә елыйсым
Никтер күздән яшьләр чыкмыйлар.

Аякларым кадакланган минем,
Сыңар адым атлый алмыйлар.
Йөрәк ертыкларын ямап булмый
Йөрәккә бит ямау салмыйлар.

Аякларым кадакланган минем,
Йөрәк, сөбханалла, йөгерә.
Телем белән әйтеп өлгерәлмим
Йөрәк каһәр әйтеп өлгерә.

Аякларым кадакланган минем,
Күңел образ эзли чаршаудан.
Җилкәннәрем җилдә сыналыр, дип,
Калдым инде, энем, ашаудан.

Аякларым кадакланган минем,
Әле дә бар янда Нурсөя.
Шигырьләрем арлы-бирле чыкса,
Тукмак белән башымны төя.

Аякларым кадакланган минем,
Сабантуйда көрәшмим чыгып.
Егалмады язмыш йөрәгемне,
Таптаса да гәүдәмне егып.

## Әлкәемнән илһам алам...

Салахова Лилия, 8 нче сыйныф
Азнакай районының “Мәлбагыш урта мәктәбе”
Җитәкчеләр: Загитова З.И., Закирова Ф.М.

Мин сезнең игътибарга 2021 нче ел – Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы уңаеннан язылган шигырьләремне тәкъдим итәсем килә. Иҗади эшемнең темасы: “Әлкәемнән (туган авылымнан) илһам алам ” дип аталды.

Теманың актуальлелеге шунда: мин – авыл баласы булганлыктан, үземне кадерле кешеләрем-әти-әниемнән башка, яраткан укытучыларым, туган авылым, газиз җиремнән башка күз алдына китерә алмыйм . Шул хисләрем минем иҗатымда чагылды

Максат: дуслык җепләрен киләчәк буыннар өчен саклап калу, патриотизм, туган якны ярату хисе тәрбияләү.

Иҗади эшнең яңалыгы шунда: истәлекле бүгенге язмаларым киләчәк өчен яңа өйрәнелмәгән тарихи чыганак булып тора.

Иҗади эшне язу барышында түбәндәге тарихи чыганакларга таяндым: мәктәп музеенда саклanучы архив язмалары, авыл тарихы китабы.

Шушы олы максатны күздә тотып,бу шигырьләр язылды.

Хәтеремдә минем бүген дә,
Мәктәп бусагасын атлауга
Якты йөзең һәм карашың белән,
Килеп чыктың минем каршыма.
Мәктәбем – икенче йортым булса,
Син – булдың икенче әнием.
Йөрәктән чыккан рәхмәт сүземне,
Шушы шигырем аша сөйлимен...

## Фәнис абый Яруллин ул...

Сафина Алисә, 4 нче сыйныф
Баулы районының “4 нче гимназиясе”
Җитәкче: Разетдинова Ф.Н.

Фәнис абый Яруллин ул
Ахры булган тылсымчы.
Шигырьләре шундый матур,
Гел килә бит укыйсы.

Вәт язып та караган ул,
Шундый кызык һәм гади.
Гарип булса да, тормышны
Яраткан Фәнис абый.

Нинди көчле кеше булган,
Зарланып тик ятмаган.
Күңел хисләрен, уйларын
Ак биткә тезеп салган.

Моңсу чакта да язган ул,
Язган ул шатланганда.
Шигырьләре бик күп аның

Туган ягы турында.

Туган авылы Кызылъяр,
Ык буенда урнашкан.
Фәнис Яруллин музее
Балкып тора ерактан.

## Туган телем – татар теле

Сафуанова Альбина, 7 нче сыйныф
Азнакай районының “Азнакай шәһәре 7 нче урта мәктәбе”
Җитәкче: Кашапова Ф.Ф.

Туган телем – татар теле
Бала чактан җанга иңгән.
Газиз телем – татар телен
Әнкәм мирас итеп биргән.

Моңлы бишек җырлары да
Туган телем аша кергән.
Тылсымлы әкиятләр дә
Татар телем аша сеңгән.

Әткәй-әнкәй өйрәткән бит
Яратыйк без туган телне!
Ансыз безнең киләчәк юк,
Саклыйк татар телебезне!

## Батыр шагыйрь

Фарукшина Илзира, 7 нче сыйныф
Азнакай районының “Азнакай шәһәре 7 нче урта мәктәбе”
Җитәкче: Кашапова Ф.Ф.

Муса Җәлил – бөек шагыйрь
Үрнәк аның тормышы.
Әсирлектә үлем белән
Тәмамланган язмышы.
Сугыш барган вакытта да
Шигырьләр иҗат иткән.
Ватаны өчен көрәшеп
Сугышчан юллар үткән.
Дошманнар газапласа да,
Һич тә башын имәгән.
Һәрчак горур булып калган
Бер дә курку белмәгән.
Шигырьләрен укыганда,
Без дә горурланыбыз.
Татарның зур шагыйре, дип,
Һәркемгә мактанабыз.
Шагыйрьдән үрнәк алабыз,
Без дә шигырь язабыз.

Киләчәктә Җәлил кебек
Кыю, үрнәк булырбыз.

## Кыш. Туган ягым кышы

Хадиуллина Дилә, 8 нче сыйныф
Казан шәһәренең “43 нче мәктәбе”
Җитәкче: Гиниятуллина Р.Х.

Бүген иртән көн томанлы иде,
Ә көндезен ишеп кар яуды.
Кешеләргә йокларга да бирми,
Төне буе буран дулады.

Буран,  дулый-дулый, юлны күмгән,
Тракторлар юлны чистарта.
Капка төбендәге яуган  карны
Көрәк алып мин дә чистартам...

## Хәтер сагында

Хайруллина Эльвина, 7 нче сыйныф
Азнакай районының “Азнакай шәһәре 7 нче урта мәктәбе”
Җитәкче: Кашапова Ф.Ф.

45 нең мае. Илгә Җиңү килде...
Атышлар да инде тынды.
Совет солдатының батыр каны
Туган җирен саклап тамды.
Күпме гомерләр өзелде,
Күпме кан- яшь түгелде.
Бу аяусыз көрәштә
Миллионнар һәлак булды.
Фашист тоткынлыгында
Күпме әсир интекте.
Җәзалау-җәфалануны
Безнең халык күп күрде.
Җитмеш биш ел үтсә дә,
Ул еллар күңелләрдә.
Солдатларның исеме
Мәрмәр һәйкәлгә язылган
һәм төренгән гөлләргә.
Мәңгелек ут янында
Сезне искә алабыз.
Һәр яз саен – бәйрәмдә
Һәйкәлгә җыелабыз.

## Әнием

Хакимова Әминә, 4 нче сыйныф
Азнакай районының “4 нче лицее”
Җитәкчеләр: Ибатова С.Р.,Сахбиева Р.Р.

Әни, әни! Мин бит сине
Бик, бик, бик нык яратам!
Матур да син, тырыш та син,
Кояштай җылы да син!
Ничек итеп яратмыйсың
Иң яхшы дустым бит син!

## Туган авылым

Хасанова Чулпан, 9 нчы сыйныф
Буа районының “Аксу мәктәбе”
Җитәкче: Хайруллина Р.Ф.

Безнең авыл бигрәк ямьле,
Агачларга күмелгән.
Җәелеп киткән киң кырлары
Ямь-яшелгә төренгән.

Туган-үскән өем нур чәчә,
Мин йөгергән сукмак елмая,
Күршеләрем ачык күңелле,
Чит җирләргә китмим беркая.

Авылдашлар бигрәк уңган
Булдыралар бар эшне.
Кайда гына эшләсә дә,
Тырышып эшли һәр кеше...

## Ана һәм мәңгелек солдат

Хисамиева Ландыш, 9 нчы сыйныф
“Г.Тукай исемендәге Ашытбаш мәктәбе”
Җитәкче: Хисамиева Р.Р.

Күп еллар үтсә дә, яшь буын, киләчәк буын бәхетле тормышның нинди югалтулар нәтиҗәсендә килүен онытмаска тиеш. Балаларын югалткан аналар, тол хатын-кызлар, “әти” сүзен әйтергә тилмереп үскән балалар. Бу сугыш китергән афәтләр. Тыныч тормышта мондый хәсрәтләр булмасын өчен үткәнеңне белергә, булган матур тормышны сакларга кирәк.

Һәйкәл яны, һәр яз саен ана
Чәчәк сала солдат каршына.
- Җиңәрмен дә, кайтырмын мин ,– дидең
Кайтмадың бит, балам, яныма.

Җыерчыклы куллар назлый сынны

– Салкын түгелме соң, бәбкәем?
Танадыңмы мине, әби булдым
Агарды бит көтеп чәчкәем.

Җиңү таңы атты, балакаем,
Бик тә матур гомер итәбез.
Һәр яз саен җырчы кошлар кайта,
Сез дә кайтыр диеп көтәбез...

## Әбием

Шакирова Ләйлә, 11 нче сыйныф
Казан шәһәре “182 нче политехник лицее”
Җитәкчеләр: Хайрутдинова Л.Н., Гатауллина А.С.

Әбием, әйтче, ник олылар
Бертуктаусыз уфтана?
Нигә алар авыр диеп
Тормышка нык зарлана?
Алар, балам, авырлыкның
Ни икәнен белмиләр.
Тыныч тормышның кадерен
Сакламыйлар, күрмиләр...
Әбием, әбием, чынлап торып
Син сугышта булдыңмы?
Мылтык тотып фашистлардан,
Илне саклап тордыңмы?
Юк, үскәнем, мылтыкны мин
Кулымда һич тотмадым...
Без күрдек чын авырлыкны
Ачлыкны да кичердек.
Киләчәк өчен корбанга
Үзебезне китердек.
Күпме балалар сугышта
Ятим булып калдылар,
Күпме солдатның гомерен
Гаепсезгә алдылар.
Тик сыгылмадык беркайчан,
Уфтанмый алга бардык.
Яшьлекне дә, гомерне дә
Бары җиңүгә салдык...
Сугыш бик куркыныч, балам.
Бүтән була күрмәсен.
Бер кеше дә без үткәнне
Беркайчан кичермәсен.
Уфтанмыйча, зарланмыйча
Шөкер итеп торыгыз.
Якты киләчәк өчен дип
Сез дә тормыш корыгыз!

## Күрәчәкне күрми

Шамкина Диана, 10 нчы сыйныф
Казан шәһәренең “179 нчы гимназия-белем үзәге”
Җитәкче: Ахметзянова А.Ф.

Бик тә сагынып кайтты авылын Заһир. Көмештәй ялтырап агып ята торган елгасы, иге-чиге күренмәгән ямь-яшел болыннары, шаулап үсеп утырган урманнары, искиткеч матур табигатьле җирдә урнашкан авылны ничек сагынмыйсың ди инде!? Чит җирләрдә генә йөргәннәр сагына торгандыр шулай. Шахталарда эшләп, азрак акча юнәтеп, өс-башларын яңартып кайтты Заһир. Киткән җирдә калырга да була иде. Тик ул авылына ашыкты.

Сөйгән яры, күз атып йөргән кызы янына бик кайтасы килде аның. Шулай хыялланып кайтып, үзләренең читән киртәле иске генә өйләре янына да килеп җиткәнен сизми дә калды. Бер сәгать тә узмады туганнары, күршеләре җыелдылар. Сөйләштеләр, сораштылар. Кайларда булдың? Ниләр күрдең? Ничек анда чит җирләрдә тормышлар? Кайларда эшләдең? Сүзләр дә, сораулар да бик күп булды.

Егет нәрсәләр генә сөйләмәде. Килгән кешеләр аны йотлыгып тыңлыйлар, кара әле син дип, тел дә шартлатып алалар. Тик йөрәген генә ишетмиләр иде алар. Йөрәге: “Эх, тизрәк кич җитсен иде дә, су буена төшәсе иде!”– диеп үрсәләнә. Заһир кайтуын авыл яшьләре минуты белән ишеттеләр. Бүген барысы да су буена җыелачак, уен-көлке, шау-гөр киләчәк су буе! Алар арасында аның сөйгәне – Зөләйха да булачак. Эх, тизрәк күрәсе иде. Иртәгәсен Заһир үзенең әтисенең абыйсы һәм тагын бер туганы белән Зөләйхаларга таба юнәлделәр. Нәрсә буласын белмәде шул ул. Юкка өметләнде егет. Аны бер авыздан: «Сиңа, син хәерчегә бирә торган кызлар бездә юк, зимагур! Зөләйханы бирерләр дип уйлама да!»– дип куып чыгардылар аларны. Заһирның бөтен хыяллары чәлпәрмә килде. Бик каты хурланды, җир упса, шунда керергә дә риза иде ул шул вакытта...

## Әни йөрәге аша

Шангараев Йосыф, 11 нче сыйныф
Казан шәһәренең “ 7нче лицей-интернаты”
Җитәкче: Мансуров А.И.

Бу дөньяга карап булса,
Әни йөрәге аша.
Күз яшьләрең бәреп чыгар,
Бик тә моңсу тамаша.

Күрер идең, никадәрле,
Була көчле яратып.
Хисен бирә йөрәккәен,
Телеп, кисеп, таратып.

Барысы да синең өчен,
Көне-төне борчуда,
Юк кына әйбергә дә,
Бик тирәнтен борчыла!...

# III. Укытучылар иҗаты

## Кыр казлары

(истәлекләрдә минем борчуларым, уйларым)

Ахмадуллина Рәмзилә Фирдинат кызы,
туган тел һәм әдәбияты укытучысы
“Арча районының “41 нче гимназиясе”

Язлар саен кыр казлары туган якларына кайталар. Талгын гына канат кагып, авыл өстеннән каңгылдашып очалар. Мин бу чорда һәр иртән урамга чыгып, җылы яктан кайтучы кошларны күзәтергә яратам. Һавага карап, әлеге җан ияләренә сокланам, ничә чакрымнарны, авырлыкларны җиңеп, туган төбәкләренә нәселләрен дәвам итәр өчен кайталар бит алар! Кыр казларын санарга ярамый диләр, таралалар. Шуңа күрә эчтән генә энәдән җепкә, энәдән җепкә дип пышылдыйм. Имеш, шулай эшләгәч, алар бер сафка тезеләләр икән.

**...** Тик арабызда шундый матурлыкны тоя белмәүчеләр дә бар.

Якты хыялларыма бирелеп, тезелешеп очкан кыр казларына карап торганда, шарт иткән мылтык тавышы мине сискәнергә мәҗбүр итте. Мескен кыр казлары куркышып таралыштылар. Алдыма яралы кош килеп төште. Бичара соңгы тапкыр яшәр өчен талпынды да, мәңгегә күзләрен йомды. Күршегә кунакка кайткан абый: “Нинди яхшысы эләккән!”– дип, алтын тешләрен күрсәтеп көләргә тотынды. Озакламый ул кыр казын машинасына салып китеп тә барды...

## Мең дә бер сорау. Иртәнге моң

(хикәя)

Ахметова Гөлнара Ахкам кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “М.И.Махмутов исемендәге 184 нче урта мәктәбе”

Якшәмбе иртәсе. Аш бүлмәсендәге радиоалгычны кабызам.

“Фәнис Яруллин сүзләре, Әхмәт Хәйретдинов көе “Сез иң гүзәл кеше икәнсез”. Җырлый Миңгол Галиев”. Миңгол абыйның моңы илаһи нур булып, күңел түренә агыла.

Мең кат тыңланган, һәр сүзе, һәр иҗеге таныш, юкса, ә шулай да мин әсәрләнеп, тәүге кат ишеткәндәй җыр тыңлыйм:

Сиздермичә ярдәм иткәнсез,
Сез иң күркәм кеше икәнсез.

Чыннан да, 25 ел мөгаллимлек юлында күпме укучыларыма җылылык өләштем, аларга ышанычлы терәк булырга, үз балаларымдай якын күреп, һәрчак ярдәм итәргә тырыштым. Күркәм кеше була алдыммы?

Барысына да җавап биргәнсез,
Сез иң гүзәл кеше икәнсез.

Чирек гасыр үтелгән ул чорда, укучыларымның бик күп сорауларына җавап бирелде.

Ә менә күптән түгел генә, икенче сыйныф укучысының җавап көтеп торган мөлдерәмә карашы күз алдымнан китми...

# Розалар иле

Әхмәтҗанова Әлфия Фарух кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “179 нчы гимназия- белем үзәге”

Борын-борын заманда яшәгән ди, булган ди бер ир белән хатын. Аларның булган ди бер кечкенә генә кызлары. Бу кыз күз явын алырлык чибәр булган. Аның гүзәллеген күреп сандугачлар да таң кала торган, табигать телгә килеп, гаҗәеп могҗизалар китереп чыгара торган булган. Бу кечкенә кыз ел үсәсен ай үсеп, ай үсәсен көн үсеп буйга җиткән. Тик әти-әнисе кызларын бер дә читкә чыгарырга яратмаганнар, чөнки аңа ят кеше күзе ярамаган, бер сокланып карасалар кыз шундук авырый торган булган. Ләкин кыз гел өйдә генә дә утыра алмаган, алар яшәгән йорт гаҗәеп матур җирдә урнашкан булган, анда кеше аяк басмаган җирләр, табигатьнең сихри урыннары бик күп булган.

Күк йөзе караңгыланган һәм көтмәгән җирдән Кәрлә малае килеп чыккан, Айсылу шунда ук йөзен яшергән. Ләкин Кәрлә малае аны, күреп алырга һәм аңа гашыйк булырга җитешкән. Бу Кәрлә малае бик ямьсез булган, Айсылуның дус кызлары аның белән сөйләшеп торырга да теләмәгәннәр.

Икенче көнне Айсылу бик каты авырый башлаган, ул тәмам өзлеккән, бу юлы аның аяклары авырткан. Көн артыннан төн үткән, Айсылуны нинди генә табибка күрсәтеп карасалар да, аякка бастыра алмаганнар. Әти-әнисе дә табибларга кул гына селтәгәннәр. Шулай итеп, Кәрлә малае әйткән җиденче көн дә килеп җиткән. Әти-әнисе Кәрлә малаеның теләген ишетергә теләгәннәр. Кәрлә малае Айсылуны үзенә кияүгә бирүләрен сораган. Ул көн дә кич белән Айсылуның өенә килеп нәрсә булганын белеп торган, Айсылу аякларына баса алмаса да Кәрлә малае аңа өйләнергә теләгән. Әти-әнисе аңа нәрсә дип җавап бирергә дә белмәгәннәр. Кәрлә малае аларга шул дәрәҗәдә ямьсез булып күренгән ки, үзләренең кызларын, күз нурларын, аңа кияүгә бирү куркыныч төш кебек тоелган. Алар гомерләре буе кызларын Сары розалар илендә яшәүче падишаһ улына бирергә хыялланганнар, чөнки ул иң матур һәм иң бай егет булып саналган. Уйлый торгач, Кәрлә малаеннан җиде көн вакыт бирүләрен сораганнар. Җиде көн эчендә, Кәрлә малае Айсылуны аякка бастырырмын дип сүз биргән.

Көн димәгән, төн димәгән Кәрлә малае җиде көн буена Айсылуга дөньяның җиде могҗизасын күрсәткән. Җиденче могҗиза Чишмәләр иленә сәяхәт булган. Бу илдә берсеннән-берсе биек, горур таулар булган, алар араларына алып, җәннәт бакчасына алып кергән.

Кич белән Кәрлә малае Айсылу артыннан килеп җиткән, Айсылуның әти-әнисе аның урынына, аның дус кызын киендереп, йөзен яшергән һәм Кәрлә малаена биреп җибәргәннәр. Кәрлә малае бер нәрсә дә сизмәгән. Ул аны урман эчендәге түгәрәк өйгә түгел, ә Кызыл розалар илендәге патшалыгына алып кайткан һәм җиде тапкыр эченнән нидер кабатлап күз явын алырлык чибәр егеткә әйләнгән. Айсылуның дус кызы – Карасылу, бу егетне күреп хушыннан язган, ә егет Карасылуны күреп телсез калган.

Ул арада Айсылу Сары розалар патшалыгына барып кергән, падишаһ егетенең күз карашыннан Айсылу тәмам сулган. Ул кулындагы сары розалар төсле саргайган, сагышланган. Падишаһ улының күз карашы аны тәмам саргайткан.

## Укытучыма

Әхмәтҗанова Дамира Рәхимҗан кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “15 нче татар гимназиясе”

Әлеге шигырь һәркемгә беренче хәрефләрне таныткан, нәни кулларыннан тотып тәүге сүзләрне язарга, санарга өйрәткән, күңеленә яхшылык орлыклары салучы изге һөнәр ияләре – укытучыларга багышлана.

Укытучым! Безнең тик йөрәкләр
Рәхмәт хисе белән тибәдер,
Сезгә тезгән чәчкә бәйләмендә
Яратуым, бәлки, сизеләдер?!

Өйрәттегез безне армый-талмый
Яхшылыкны аерып яманнан.
Дуслык кадерен белү кирәк, дисез,
Дөреслекне аеру ялганнан.

Рәхмәтлебез шуңа барысы өчен,
Өйрәндек без Сездән барысын!
Башлангычта очкын булган уйдан
Киләчәктә учак кабынсын!

Балаларым, диеп уйландыгыз,
Истән чыкмадык без – кич-иртән.
Мин дә шуңа олы рәхмәтемне
Йөрәгемнең түрендә йөртәм!

## Үги кыз
(хикәя)

Әхмәтова Рәмилә Зөфәр кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Алабуга районының “10 нчы урта мәктәбе”

Катнашалар: Бабай, әби, үги кыз, үз кызы, егет -1, егет-2, бәйрәмне алып баручы.

Мультфильмнан өзек күрсәтелә. ( Башы)

Әби белән бабай ( милли киемдә, өстәлдә милли ризыклар) самовар артында чәй эчеп утыралар.

Бабай:

– Кар көрисе бар әле, тагын ява...

Әби:

– Сөйләмә әле шул карыңны. Әнә, корновальный вирусның яңа төрле, Һиндстан ыштанлысы килә икән...

– Шулай, ди җаным... Шулай, ди... Син гел дөрес әйтәсең.

Ишектән ике кыз – Гөлназбикә белән Рәмзиябикә керә. Гөлназбикә ( Сагыз чәйни, кабарта, шартлата). Рәмзиябикә :

– Әтием, әнием! Барлык эшләрне дә эшләп бетердем. Рөхсәт итсәгез, бүген мин Яңа ел бәйрәменә – дискәтүккә барыр идем... Анда...

Гөлназбикә аны этеп җибәрә.

– Кит әле моннан, үзем сөйлим. Корроче... әни... Мин бәйрәмгә нинди күлмәгемне кияргә дә белмим. Асылы – бик асыл, бәрхете – бик бәрхет., озыны – бик озын, кыскасы – бик кыска....

Әби:

– Иииии.... Алтынкаем минем, кичә алган, яңа күлмәгеңне кимисеңме, әллә тиз генә кибеткә барып тагын берәр күлмәк сатып алыйкмы? Алтын-көмешләреңне, энҗе-мәрҗәннәреңне ки! Кем, дигәндә – Гөлназбикә! дисеннәр! ...

Әкиятне бүгенге көнгә яраклаштырып язу, яшь тамашачының аңына барып җитсен өчен кирәк.

Әкиятне бүгенге көнгә яраклаштырып язу, яшьләрдә хезмәткә уңай караш, хезмәт тәрбиясе бирү өчен кирәк.

Әкиятне бүгенге көнгә яраклаштырып язу, әти-әниләрнең балаларына дөрес тәрбия бирергә этәргеч булдыру өчен кирәк.

Әкиятне бүгенге көнгә яраклаштырып язу, бүгенге көндә дә “намус, итәгатьлелек, тәүфыйк, әти-әнине санлау, хөрмәт итү ” төшенчәләренең бик актуаль икәнлеген күрсәтү, аңлату өчен кирәк.

Әкиятне бүгенге көнгә яраклаштырып язу, миллилекне саклау өчен кирәк.

## Фәнис Яруллинга

Әхмәтшина Люция Таһир кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Әлки районының “Иске Чаллы гомуми белем мәктәбе”

Авырлыкка бирешмәдең,
Сынмадың, сыгылмадың.
Төшенкелеккә бирелми
Һәрчак алга атладың.
Шигырьләрең белән кердең
Балалар күңеленә.
Шаян сүзләр урын алды
Язган шигырьләреңдә.
Шигырләрең безне һәрчак
Чакыралар әдәпкә.
Дөреслекне ялганнан
Аерырга өйрәтә.
Шаян сүз белән аңлаттың
Уйларыңның һәммәсен.
Өйрәттең син яшь буынга
Яшәүнең чын мәгънәсен.

## Күңел халәтем шигырьләремдә...

Борисова Римма Владимир кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “69 нчы мәктәбе”

Һәр кеше күңелендәге уй-кичерешләрен, кайгы-сагышларын, сөенеч-шатлыкларын үзенчә кичерә. Аларның кайберләре эш-гамәлләрдә,сөйләмдә чагылыш таба. Мин күңелемдә туган уй-фикерләрне, сагыш-борчуларны, шатлык-куанычларны шигырь юлларына салам.

“Әбием хатирәләре” шигыре әбиемнең балачак турындагы истәлекләренә нигезләнеп язылды. Кышкы озын кичләрдә әбием, без – оныкларын янына утыртып, сугыш чорына туры килгән авыр балачагы, ачлы-туклы килеш колхоз эшенә йөрүләре турында мавыктыргыч итеп сөйли иде. Бу истәлекләр минем күңелгә сеңеп,еллар үткәч, шигырь юлларына салынды. Бу шигырем әбием истәлеге буларак саклана.

“Туган як” шигыре бүгенге көндә дә актуаль, авылларда мәктәпләр ябыла, яшьләр шәһәргә күченә, күп йортлар иясез, ятим кала, бары тик Сабантуйларда гына күп авылдашларны очратырга мөмкин. Югалтмаска иде туган авылларны, саклап калырга иде төп нигезләрне, онытмаска иде аунап үскән туган туфракны.

Тарта туган туфрак, үскән нигез,
Аунап үскән яшел чирәм дә....
Кайтыгыз ла туган җирегезгә,
Саргаймагыз чит-ят җирләрдә.

Бу юллар туган якларын сагынып яшәүче авылдашларга багышланган.

“Парлы тормыш насыйп булсын сезгә...” шигыре яшьтән парын югалтып, тормыш йөген ялгыз тартырга мәҗбүр булганнарга багышлана. Толлар язмышы аяныч, алар язмышка буйсынырга мәҗбүр. Ләкин юк кына сәбәп белән, бер-берсенең гаебен табып таркалган гаиләләр дә шактый. Балалар ятим үсә, ялгыз анага тормыш алып бару, балаларга дөрес тәрбия бирү кыенлаша. Бу шигырем белән мин сабыр булырга, балалар, аларның киләчәге хакына, бер-берсенә юл куеп, уртак фикергә килергә өндим.

Гафу сорап килгән ярыгызны
Кичерегез,читкә бормагыз.
Балаларга һәр икегез кирәк,
Алар киләчәген уйлагыз.

Бәхет төшенчәсен һәркем үзенчә аңлый. Кем өчендер бәхет – янында яраткан яры булу, кемдер байлыкны зур бәхет дип саный, кемгәдер бәхетле булу өчен сәламәт булу да җитә, кемнәрдер якыннарының сау-сәламәт булуын тели. “Бәхет” шигырендә мин үзем өчен бәхетнең нинди булуын, бәхетле булу өчен миңа ниләр кирәген күрсәтергә теләдем. Минем өчен бәхет – яратып башкарган эшем, янымдагы тиң ярым, балаларым, якыннарымның сау-сәламәт булуы.

“Сөйгәнемә” шигыренең язылу тарихы шактый кызыклы. Бу шигырь ирем еракка озак вакытлы командировкага киткәч язылды. Бер-береңә кирәклекне тою, тиң парлар булуны аңлау өчен шундый аерылып торулар да кирәк икән тормышта.

Син – минем өчен терәкме,
Әллә мин – синең терәк?
Бу дөньяда син миңа да,
Мин сиңа да бик кирәк.

Шигырьләр – күңелдәге уй-фикерләрне, борчу-сагышларны башкаларга җиткерүнең бер юлы. Шигырь юлларына салырлык куанычлар күбрәк, күңел сандыгыбыз шатлыкларга бай булсын иде.

## Йөрәк кушуы

Габдрахманова Наилә Шайнур кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Арча районының “Түбән Мәтәскә урта мәктәбе”

Авылга әби-бабасына кунакка кайткан Алмаз исемле малай белән булган хәлләр сурәтләнә. Әби белән бабай оныклары кайтуга бик шат. Алмаз күбрәк бабасы янында булырга тели. Бабасы, үзенең эшләре аркылы, малайга намус төшенчәсен аңлатырга тырыша.

– Дәү әти, бу синең агачыңмы?

– Юк, улым, кем утырткандыр, белмим.

– Алайса, нигә аны син карап торсың? Сиңа карарга куштылармы?

– И, улым, нишләп кушсыннар ди, миңа йөрәгем куша, йөрәгемә рәхәт була,– ди бабасы.

Әсәр ахырында Алмаз оядан егылып төшкән сыерчык баласын коткара. “Шуны гына көткән сыерчык анасы ояга килеп кунды, тишектән башын тыгып карады да сайрап җибәрде. Алмазга шундый рәхәт булып китте, ул, яшел чирәмгә утырып, сыерчык җырын тыңларга кереште”. Дәү әтисе оныгы эшләгән яхшылыкны күрә һәм аның өчен чын күңеленнән шатлана. “Әдһәм абый елмаеп җибәрде.“Аңлаган!” – диде ул үз-үзенә. Ул, оныгының башыннан сыйпап, аңа күз кысып куйды. Алмаз дәү әтисенең нәрсә әйтергә теләгәнен аңлады”...

## Әниемә

Габдрахманова Резедә Әнәс кызы,
татар теле һәм әдәбият укытучысы
“Адымнар-Казан полилингвиаль комплексы”

Әнкәем, кадерлем,
Сиңа дип җырладым
Җырларның моңлысын.
Ишетеп кичләрен,
Сагыну хисләрен
Барысы тыңласын.

Тыңласаң, әнкәем,
Алсу таң атканда
Сандугач сайравын.
Исәр таң җилләре
Тапшырып балаңның
Сагыну сәламен.

Ишетсәң, әнкәем,
Чылтырап тын гына
Чишмәләр агышын.
Аңларсың балаңның
Талпынган йөрәген,
Сагыну сагышын.

Әнкәем, кадерлем,
Кояшым син минем –
Җылы нур сибүче.
Йөрәгең түреннән
Салават күперен
Күңелгә сузучы.

## Шигырьләрем белән...

(Фәнис Яруллинга багышлана)

Галиева Әлфирә Әмирҗан кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
“В.Г.Тимирясов исемендәге Аксубай 1 нче
урта гомуми белем бирү мәктәбе”

Шигырьләрем белән
Аяксызга аяк бирдем.
Миңа карап көч ал, туган,
Дүрт саның да тигез дидем...

Шигырьләрем белән
Йөрәксезгә йөрәк бирдем.
Йөрәгемне минем ярып кара,
Ничек эшли икән дидем...

## Аккош язмышы

Гарипова Ландыш Габделфарт кызы,
тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы
Кукмара районының “А.М. Булатов исемендәге күппрофильле лицее”

Бүгенге көн кысаларында, глобализация шартларында, чит ил яшәү рәвешен пропагандалаган чорда гади генә кешеләрнең үзенчәлекле тормышын, кайвакыт ачы язмышын да тасвирлауны бик актуаль дип саныйм. Күп кенә әсәрләрем бу теманы яктыртып төрле гәҗит-журналларда басыла, бәйгеләрдә катнашып, рус теленә дә тәрҗемә ителә. Эшнең максаты: укучыларда “мәхәббәт “дип исемләнгән кешеләргә генә хас булган сихри хисләрнең көчен, рухын күрсәтү.

Бурычлары: хикәя геройларына карата хөрмәт хисе тәрбияләү; укучыларда хикәя геройларының тормышына, кичергән хисләренә карата кызыксыну уяту; укучыларга әхлакый тәрбия нигезләрен бирү

“Аккош язмышы” хикәясе тормыштан алынган вакыйгага нигезләнеп язылды. Хикәя геройлары бүгенге көндә дә Кукмара районының бер авылында үрнәк гаилә булып, тату гына яшәп яталар. Бу хикәя аша мин укучыларга чын ярату хисләренең нык, какшамас булуын күрсәтергә омтылдым. Кешеләргә генә хас булган мәхәббәт хисенең гомер буе да яшәргә мөмкин икәнлеген күрсәтүне максат итеп куйдым.

Нәтиҗә: “Аккош язмышы” хикәясе куелган максатларына иреште дип саныйм.

“Аккош язмышы” хикәясеннән өзек.

...Жыйнак кына авыл йорты. Өй эченә тәмле ризыклардан хуш ис бөркелгән. Өстәлнең бер башында милли бизәкле түбәтәйдән Шамил, икенче башында ап-ак яулыктан Сания утыра. Анын мөлаем йөзендәге җирән сипкелләренә кояш иренеп кенә узененең нурларын чәчеп тора. Нәкъ менә балачактагыча…Шамильнең күзләреннән бер- бер артлы мөлдерәмә яшьләре тама:

– И, Саниям, бәгърем, мин бит сине ярты гасыр буе көттем! Ярты гасыр...

Бу мизгелдә бар җиһанда алардан да бәхетле кеше юк иде. Ике җан, гомерләренең сагышлы көзендә, бер сукмакка басып, җитәкләшеп, бәхеткә төренеп салмак кына кереп китәләр.

## Бер игелек турында

Гәрәева Ленизa Әзһәр кызы,
рус теле һәм әдәбияты укытучысы
Баулы районының “1 нче санлы төп гомуми белем мәктәбе”

Шигырь язу – кешенең чынбарлыкка, үткәнгә, киләчәккә булган хисләрен, тойгыларын аңлатып бирү ул. Минем “Бер игелек турында” һәм “Кайтып киләм Бәйрәкәмә” шигырьләрем бер-беребезгә яхшы мөнәсәбәттә булу, игелек эшләү һәм туган якка мәхәббәт турында булулары белән актуаль дип саныйм. Максатым – ярдәмләшү кебек күркәм сыйфатның тормышта мөһимлеген аңлату һәм тарихи статусы булган Ютазы районында ураншкан Бәйрәкә авылым турында бәян итү. Бурычларым – шигырьләремне укыган кешеләрнең әхлак нормаларын тормыш кагыйдәсенә алуларына һәм тарихыбызга карата горурлык хисе тәрбияләүгә, туган авылым турында мәгълүмат бирүгә ирешү.

Эш барышында эзләнү (тарихи истәлекләр, әдәбият белән танышу), эвристик әңгәмә (кешеләр белән сөйләшү), күзәтү, нәтиҗә чыгару кебек алымнардан файдаландым.

“Бер игелек турында” шигырен шаян, заманча, гади формада, кеше күңеленә җиңел үтәрлек итеп яздым. Галимә әби һәм бер Казан егете образы аша тормышта яхшы мөгамәлә, игелек, ярдәмлек сыйфатларын күтәрдем. Галимә әби үзе олы яшьтә булуына карамастан, ялгыз яши торган дустына булышып яши. Кылган гамәлләренә җавап буларак, кыен хәлгә калгач, үзе дә бер яшь егеттән ярдәм кулы тоя:

Чит егет әбине шулай

Олылады, зурлады.
Тиеш җиргә илтеп куйды,
Акчасын да алмады.

“Кайтып киләм Бәйрәкәмә” исемле шигыремдә туган авылымның тарихы турында кыскача сөйләп бирәм. Тугыз строфа эченә авыл турындагы мөһим вакыйгаларны, мәгълүматларны салдым. Мәсәлән,

Әнә Ыкны барып коча торган
Бәйрәкә елгасы яңарта хәтер.
Заманында бер мең хуҗалыкка
Суын җиткергән ул, бердәнбер.

Шулай ук туган авылымның тирә-якка танылган рухи һәм гыйлем үзәге булганлыгын билгеләп үтәсем килде:

Биш йөз шәкерт өчен ишек ачкан
“Гобәйдия” мәдрәсәсендә
Мөҗәй, Сирин кебек даһи уллар
Канат тоеп чыккан иңендә.

Сүз уңаеннан, әлеге “Гобәйдия” мәдрәсәсе тарихы бөек композитор София Гобәйдуллинаның бабасы Мәсгуд Гобәйдуллинга барып тоташа. Бу мәдрәсә “Мөхәммәдия”дән кала икенче урында торган. Мәктәпнең бер өлеше булып хезмәт иткән элеккеге мәдрәсә бинасын музей итеп торгызып ачуга Бәйрәкәгә София Гобәйдуллина үзе дә чакырылды.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә, заманны, кеше күңелен тоеп язылган шигырьләрдә авторның әйтергә теләгән фикере укучыларда кайтаваз тапмыйча калмый, ә тарихи эчтәлеклеләре – үткәнебез белән киләчәгебез турында уйланырга да мәҗбүр итә.

## “Һәр ел саен яз җитүен көтәм...”,

Гилфанова Венера Җәүдәт кызы,
Татар теле һәм здзбияты укытучысы
Казан шәһәренең “25 нче мәктәбе”

Лирик герой гашыйк. Ләкин үз хисләре турында белгертергә ояла. Ул кайчан да булса хисләре җавапсыз калмас дип өметләнә, көтә. Мәхәббәт саф, назлы хис, аны сакларга кирәк, өзелгән җеп кире ялганмаган кебек, югалган хисләр дә кире яңармаска мөмкин.

Һәр ел саен яз җитүен көтәм
Мин язларны шундый яратам.
Язлар белән син кайтырсың төсле
Өметләрне ялгап яңадан.
Өзелгән җеп кире ялганмый шул
Өметләр дә, уй-хыяллар да.
Алар инде күптән күккә очкан
Адашканнар кар-бураннарда.
Иртә язлар очраштырган иде
Кара күзләр безне аерды.
Саф мәхәббәт озак яшәмәде
Пар канатларыбыз каерылды.
Йөрәк кенә һаман тынычланмый,
Синең исемең кат-кат кабатлый.
Ул бит һаман өметләнә, көтә,
Юкка икәнлеген аңламый.

## Очрашу

(хикәя)

Гыйниятуллина Раилә Хәбибулла кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “43 нче мәктәбе”

Зәйнәп машинадан төшеп калганда, төн үзенең кара пәрдәсен күк йөзенә капларга өлгергән иде инде. Кайсы якка барырга? Кемгә барып сыенырга?

Машина күздән югалуга, коеп-коеп, яңгыр яварга тотынды. Авыр чемоданын күтәреп авылга килеп кергәндә, тәрәзәләрдә утлар сүнә башлаган иде инде. Зәйнәп авыл читендәге бер тәрәзәсендә генә уты янып торган йортның ишеген шакыды. Галия апа ишекне ачты һәм һәр җиреннән су агып торган бу кызны күргәч: “Балам, тизрәк үт тә өсләреңне алыштыр. Салкын үзәгеңә үтә бит хәзер”,– дип, өйгә алып керде.

– Кызым, бу караңгы төндә башыңа ни эш төште соң?

– Сезнең авылга укытучы итеп җибәрделәр мине, апа. Татар теле укытучысы. Соңга калуымның сәбәбе…– кыз туктап калды. Күз алдына бүгенге хәлләр килде һәм чак кына елап җибәрмәде ул. Уйлары еракка – Рәшит белән беренче тапкыр очрашкан көнгә барып тоташты. “Тормыш юлын бергә үтик”,– дип йөргән егет көннәрдән бер көнне суга төшкән күк юк булды. Зәйнәп ни уйларга да белмәде. Бүген исә, үзе студент чагында яшәгән тулай торакның әйберләрен тапшырып бетергәннән соң, зур өметләр баглап, кабаттан Рәшитләр тулай торагына юл тотты. Тик анда бүлмә ябык, Рәшитне күрүче кеше дә юк иде.

– Иртәгә үзем сине мәктәп директоры белән таныштырырмын. Ул минем бертуган энем. Калырга уйласаң, миндә торырга калырсың.

– Сез риза булсагыз, мин бик теләп калыр идем.

Икенче көнне Галия апа аны иртән мәктәп директоры белән таныштырырга алып китте. Хәбир абый аны бик теләп эшкә алды.

Зәйнәп мәктәптә эшли башлады. Укытучылар аны якты чырай белән каршы алдылар.

Яраткан эше, аны яратып кабул иткән хезмәттәшләре, мөлаем хуҗабикәле торыр урыны булса да, күңеленең бер җире һаман китек булып тора, чөнки аның Рәшит турында бер төрле хәбәре дә юк. Кайда соң син, серле егет? Ни булды сиңа?

Шундый уйлар эчендә беренче сентябрь дә җитте. Курыкып та, зарыгып та көткән беренче дәрес... Ул дәрескә бик ныклап әзерләнде. Укучылары аны шулкадәр бирелеп тыңладылар, кыңгырау шалтырагач та, төрле сораулар биреп дәресне тагын аз гына булса да озайтырга тырыштылар.

## Шигырьләрем йөрәк түренннән

Закиров Айдар Миңлекашыйп улы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәрең ”7 нче лицей-интернаты”

Шигырь язып карамаган татар кешесе юктыр ул? Аны язмаса да, эчтән генә булса да көйләп йөридер. Казан пединститутына укырга кергәч, яңа сәләт ачылды. Ярыша-ярыша каләм тибрәтә башладык. Ләкин минем шигырьләрем тик торганда гына тумадылар. Алар күңелнең нинди дә булса бер сәбәбен көттеләр. Беренче мәхәббәт хисләре. Аларның җавапсызлыкка дучар булуы көеп янган йөрәктән шигырь булып чыкты.

“Шигырьләрем йөрәк түренннән” дигән җыентыгымны да шул вакытта язганнарым истәлек булып калсын әле дип тупладым. Анда тематика бер төрле генә түгел, берәр вакыйга булса, шигырь туган. Бу инде минем нечкә күңелле иҗат кешесе икәнемне ассызыклап тора да. Җыентыкта мәхәббәтләрем дә, колхозда эшләгәндә йортта торган әбиебез дә, сагынып үзәкләрне өзгән туган авылым да, татар телем дә, республикам да, институт диварлары да

искә алына. Минем шигырьләрем нинди дә булса вакыйга уңаеннан туалар. Аларны кирәк бит әле дип язып утырасы юк.

Бүген сезгә үземнең “Җыр көче” дигән шигыремне тәкъдим итәм. Ни өчен бу шигырь күңелемә якын соң? Мирхәйдәр Фәйзинең “Галиябану” әсәре – беренче музыкаль драма булып тарихка кереп калган. Аңа Салих Сәйдәшев музыка язган. Әсәр увертюра белән башланып китә, аннары геройларның җырлары белән үрелеп бара. Шушы әсәр буенча ачык дәрес үткәргәндә, мин иң соңыннан үземнең шигыремне укып киттем. Сез инде әсәрне хәтерлисез, әсәрдә җыр бик көчле урын алып тора. Шуңа минем шигырем дә җырның көчен күрсәтеп китте. Дустым шагыйрь Алмаз Мансуров Фатих Кәримнең “Кыңгыраулы яшел гармун”ы кебек булган бу”,– ди.

Сандугачны матур җырлый диләр,
Матур җырлый диләр аларны.
Ә яшь егет күпме җырласа да,
Сөйгән ярын бик тиз табармы?!

Җырлый егет күңеле тулган чакта,
Шатлыклары тулып акканда.
Кайгыларын җырга салып көйли,
Тормыш мәрхәмәтсез какса да.

Җырларында аның тормыш яме.
Эшче көче ачык күренә.
Көр күңелле егет җырлаганда
Бөтен дөнья моңга күмелә.

Нәтиҗә ясап, “Күңелемнән чыккан җылы хисләр бары сиңа гына агыла,”– дип әйтәсе килә. Шигырьләрем җыентыкларда да дөнья күрделәр. Мин аларны дәресләрдә, сценарияләр язганда кулланам.

## Туган нигез

Закирова Гөлназ Илдус кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
“Әгерҗе шәһәренең 1нче гимназиясе”

Җан да тарта, кан да тарта икән,
Төшләремдә көн дә туган нигез.
Гөлгә күмелеп утырган яшел бакча
Әткәй-әнкәй – парлап сез икегез.

Әнә шулай төн дә кайтып киләм
Гәрәбәдәй болдыр төпләренә.
Ишек ачам, бусагадан үтәм
Җан сафлыгы бөркелә битләремә.

## Төзәлдеме күңел ярасы?

Зарипова Гүзәлия Габделнур кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “110 нчы лицее”

Кулларыма шундый тасма алам,
Ә бу тасма – җиңү билгесе.
«Җиңү» сүзе рәхәт ишетелә,
Ә күпме соң аның бәясе?!
Ә күпме соң аның бәясе…

Биек күңелле «Җиңү» сүзен әйтү,
Аңлыйбызмы аның бәясен?!
Мөмкинме соң күз алдына китерү
Күпме кеше гомере өзелүен?!
Күпме кеше гомере өзелүен…

Ил эчендә нинди кайгы булды,
Күпме күз яшьләре түгелде,
Күпмеләрнең җаны сыкранды,
Күпмеләрнең күңеле елады?!
Күпмеләрнең күңеле елады…

## Кайтыгыз

Зарипова Дания Фирдәүс кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “85 нче мәктәбе”

Кайтыгыз сез, дуслар, туган якка
Ата-ана исән чагында,
Алар гомер буе безне уйлый ,
Һәр көн көтә, һәр көн сагына.
Ата-ана вафат булган булса,
Зыяраттә дога кылыгыз,
Әби-бабай, туган, күршеләрнең,
Барысын  да искә алыгыз!
Кайтыгыз сез, дуслар, туган якка
Алмагачлар чәчәк атканда,
Сәяхәт итегез кырларында
Сызылып алсу таңнар атканда.
Эчегез сез туган җирегезнең
Челтерәп аккан чишмә суларын,
Искә төшерегез яшь  чакларда
Гөрләп үткән сабан туйларын.
Кайта алмасагыз туган якка
Хыялларыгызда кайтыгыз,
Туып-үскән нигез туфрагына
Яланаяк чыгып басыгыз!

## “Өметем бар...”

Заһитова Зинфера Ильяс кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Азнакай районының “Мәлбагыш урта мәктәбе”

Ә мин көтәм, һаман көтәм...
Сугыш бетте. Җиңү килде.
Язлар белән кошлар кайттылар.
Кошлар кайтты туган якларына
Син кайтмадың, калдың, югалдың.
Җилләр иссә, җилдән сорыйм:
Күрдегезме диеп бабамны?
Җилдә белми, берни белми
Исәнлеген хәтта кабереңне.
Ә мин көтәм, һаман көтәм...
Менә бит син исән дигәнсең.
Тиздән кайтам, көт сабыр бул!
Исәнлегемне телә дигәнсең.
Хатлар , хатлар,
Өчпочмаклы хатлар.
Ник соң алар хәбәр бирмиләр.
Мин бер генә түгел, миллионнар
Һәйкәл булып катты күңелләр.
Ә мин көтәм һаман көтәм,
Саргайса да синең хатларың.

## Вөждан газабы
(хикәя)

Зиатдинова Ләйсән Һади кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “4 нче гимназия-интернаты”

“Вөждан газабы” хикәясендә яшүсмерләр арасындагы мөнәсәбәтләр, әхлак нормалары, материаль байлыкларга караш, үч алу, кеше әйберенә кызыгу, нахак сүз, көнләшү кебек проблемалар яктыртытра тырыштым. Шуннан чыгып, эшемнең максаты: яшүсмерләр арасындагы мөнәсәбәтләрне яктыртып, әхлак, дуслык, вөждан турында уйланырга этәрү.

Хикәядә вакыйга авыл мәктәбендә бара. Төп геройлар 12-13 яшьлек малайлар. Яшүсмерлек чорына кергән, үз-үзләрен танытырга теләгән катлаулы чор кичерә алар. Шушы чорда ике малай – Айрат һәм Таһир арасында киеренкелек туа. Таһир бу елны гына аларның авылына шәһәрдән килгән малай, уку аңа бик җиңел бирелә, барысы да аны ярата. Ә Айрат аңа кызыгып, уңышларына көнләшеп карый. Физкультурадан да Таһир беренчелекне алып, Айратны кеше көлкесенә калдыргач, малайда үч алу теләге туа. Үч алу максаты белән, Айрат бай гаиләдән булган сыйныфташы Маратның текә телефонын сиздермичә генә алып, Таһирның рюкзагына сала, аны урлашуда гаепле итәсе килә. Аның уйлаган эше килеп чыга, барысы да урлашуда Таһирны гаеплиләр. Әмма Айрат, үзе уйлаганча, бер дә канәгатьлек кичерми. “Ул төнне Айрат йоклый алмады. Күңелен әллә нәрсә тырнады, аз гына вакытка булса да онытылып китсә, шыбыр тиргә батып, йөрәге кысылып уянды. Күз алдыннан Таһирның сыйныфташлары уртасында куырылып басып торуы китмәде”. Айрат вөждан газабына түзә алмыйча, барысын да сөйләп бирергә мәҗбүр була. Дөреслекне сөйләгәч, үз

гаебен таныгач, Айратка җиңел булып китә, вөҗдан уты күңелен яндырудан туктый. Таһир белән дә аңлаша ала: “Ярый барысын да сөйләп бирә алдың. Көчле кеше икәнсең. Мин булдыра алмас идем,”– диде Таһир. Айрат та туры карамыйча гына гафу үтенде. Шушы сүзләрдән соң малайлыктан егетлеккә аяк атлаган, вөҗдан газабы һәм нахак сүз авырлыгын татып караган ике яшь кеше тын гына ак чәчәккә күмелгән шомырт агачы астындагы эскәмиядә бик озак утырдылар”.

Хикәямдә яшүсмерләр арасындагы мөнәсәбәтләргә тукталдым, чөнки һәр көн укучылар, яшүсмерләр белән эшлибез, аларның күңелен яндырган проблемаларын, үзара мөнәсәбәтләрен күрәбез, үз-үзләрен ничек тә күрсәтәсе килү теләгенә шаһит булабыз. Бәлки бу хикәя дә яшүсмерләр күңелен яхшырак аңларга, үзебезнең шушы чорыбызны искә төшереп, укучыларыбызга кирәк чакта ярдәм кулын сузарга этәрер.

## Әнием, кояшкаем!

Исрафилова Әлфия Рафаел кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Актаныш районының “Чалманарат төп белем бирү мәктәбе”

Әҗәкүл, Теләкәй, Чалманарат яклары – минем тормышым, хезмәтем белән бәйле авыллар. Ямьле Агыйдел елгасы янында урнашкан туган авылымның матурлыгы гаиләмдәге тыныч, тату тормышлар белән үрелеп бара. Минем әти-әнием дә матур, тату, үрнәк итеп яшәделәр. Кадерле кешеләремне, тормыш иптәшемне сагынып гомер үтеп бара. Мин бирешмим, сагышлы хисләр белән, хезмәт юлымны, тормышымны матур итеп, горур итеп дәвам итәм. Туып-үскән җирдә эшчәнлек алып бару – тагы да җаваплы хезмәт. Һәр адымны лаеклы итеп, тап төшермичә атлыйсы килә. Мәктәп – минем эш урыным гына түгел, ул яшәвемнең мәгънәсе дә. Мәктәптә белем алып чыгып киткән һәр бала безгә бик кадерле. Алар, безнең ышанычыбызны аклап, тагы да яңа үрләргә менәләр. Һәр укучы бала − минем горурлыгым, алар минем эшемнең нәтиҗәсе, мин аларны яратам.

Татар егетләре, татар кызларының уңган-булганлыгы – бик матур күренеш. Яшьли дөрес тәрбия алып үскән татар егетләре, кызлары чын татар гаиләләре кору осталыгына ия булалар, балаларын да матур, әхлаклы итеп тәрбияләп үстерәләр. Тәрбияле балалар гына безнең киләчәгебезнең ышанычы була ала.

Чын тормыш дусларсыз бара алмый. Дуслар белән генә чишә торган мәсьәләләр һәм аларга гына сөйли торган серләр була. Ышанычыны аклый торган дуслар булганда тормышның матурлыгы тагы да ачыграк күренә.

Тормыш матур, аны күрә белергә һәм яши белергә генә кирәк!

Әнием, кояшкаем,
Якты нурыбыз безнең.
Шаян һәм тапкыр сүзле
Таянычыбыз идең.

Җиде айлык булып,
Син дөньяга килгәнсең.
Әллә авырлыкларны
Күрми калмыйм дигәнсең.

Галәм киңлекләрендә
Йолдыз булып балкыйсың.
Йөрәгемнең иң түрендә
Кояш булып балкыйсың...

## Тормыш чыганагы

Калимуллина Роза Әгъдәс кызы,
башлангыч сыйныф укытучысы
Баулы муниципаль районының “4 нче гимназиясе”

Балалар тәрбияләүдә иң изге хәзинә – туган тел. Туган телгә, туган якка мәхәббәт, әти-әнигә, туганнарга булган якты хисләр, хөрмәт һәм иһтирамлык тәрбияләүдә милли горурлыгыбыз булган бөек шагыйрь – якташыбыз Фәнис ага Яруллинның иҗатын, тормыш юлын үрнәк итеп алабыз.

Бик күп тырышлык, үҗәтлек, хезмәт куеп, бәхеткә ирешү теләге белән яшәгән язучы, зур өметләр баглап гел алга омтылып яшәүче, күркәм сыйфатлы, искиткеч сәләтле әдип ул.

Укучылар белән Фәнис Яруллинның батыр, сыгылмас, авырлыкларга бирешмәс, үтә дә кешелекле шәхес булуы турында тәрбия алымнары үткәрәбез. Аның шигырьләрен, әкият-язмаларын яратып укыйбыз, ятлыйбыз, театрлар куябыз, һәйкәлендә, музеенда булабыз.

“Тырыш бәхетне эшендә күрер”, дигән әйтем бар. Якташыбызның бай әдәби сандыгы киләчәк буыннарга мирас булып калды. Без аңа чиксез рәхмәтлебез. Минем шигырем дә тырышлык турында.

Илең, халкың, табигатьне сөйсәң,
Чынлап гашыйк булсаң тормышка –
Күңлең белән иренмәскә кирәк,
Зарланмаска һич тә язмышка.

Белем ачкычлары – тырышлыкта,
Дәрәҗәле булыр белемле.
Каты булып, ныклы белем алып,
Киләчәккә яктырт көнеңне...

## Үз җиремдә
(хикәя)

Касыймова Зөһрә Габбас кызы,
туган тел һәм әдәбияты укытучысы
Арча районының “Утар-Аты төп мәктәбе”

Йомшак балаларына борынын төртеп йокымсырап яткан Керпебикәниндидер выжылдаган тавышка уянып китте. Ачу китереп, бертуктаусыз выжлый иде ул. Бераз тыңлап яткач, Керпебикә бу тавышның көчәюен сизде. Нәрсә булыр бу? “Чыгып, карап керми булмас,”– дигән фикергә килде Керпебикә. Бик пөхтәләп, тырышып ясаган оясыннан шыпырт кына чыгып, тирә-якка каранды.

Нинди җылы, матур, җәйге көн! Күк йөзе чалт аяз, күзләр чагыла хәтта! Үлән арасында йөзләгән бөҗәк, һәрберсенең үз мәшәкате. Төрле төстәге күбәләкләрне чәчәкләрдән аерып та булмый. Армас-талмас кырмыскалар гел хәрәкәттә. Үтә дә эшлекле выжылдап, төклетура очып үтте. Ә теге тавыш, бакчаның аргы башында, күңелгә шом салып, выжлый да выжлый.

Ярата шул Керпебикә бу бакчаны. Хуҗалары уңганнар, тырышлар. Бакчаларын бик карап торалар. Шуңа күрә һәрбер агач, куагы мул уңыш бирә. Гөлбакчалары да карап туймаслык була. Гаилә белән бергәләшеп, бакчада хезмәт куялар. Тик менә 2 ел рәттән печән кишәрлеген чапмый калдырдылар. Ә быел анда үлән куе булып, ишелеп үсте. Керпебикәгә дә оя ясарга бик уңай булды. Кипкән үлән күп, хуш ис аңкып тора, җир көпшәк,

бераз гына казыды да, җиләк яфраклары ташып төшәде, өстән чыбыкның ныграгын куйды, яңгыр үтмәслек итте. Инде менә 5 баласы тәгәрәп үсеп килә.

Үлән арасыннан бөтенләй дә күренмәгән оясына тагын бер борылып караганнан соң, Керпебикә болынның аргы башына тәпиләде. Юлында очраган тычкан балаларына да, тәмле һәм сусыл җиләкләргә дә игътибар итеп тормады бу юлы. Өзлексез выжлаган бу тавыш җүнлегә булмас.

Үзе өчен артык борчылмый ул. Ләкин яңа гына күзләре ачылып, шушы матур җәй белән таныша башлаган нәни балалары өчен курка. Керпебикә адымын тизләтте. Инде ят тавыш тагын да куркынычрак булып ишетелә башлады. Куе печән бетүгә, Керпебикә кулына печән чапкыч тоткан бакча хуҗасын күреп алды. Янында малае да булышып йөри. Алар гел шулай, эшне бергәләп башкаралар. Малайны еш күрә Керпебикә. Исемен дә белә. Иптәшләре белән болынга уйнарга еш килә Рәмис. Бик кызыксынып кырмыскалар күзәтә, күбәләк тә куып йөрми, башкаларны да: “Тотмагыз, болай да гомерләре бер генә көн!”– дип кисәтә.

Керпе чабылган үләнгә шыпырт кына күзәтү ясап килде. Бар үләнне төбеннән үк кыркып, егып бара. Болай булса, аның балалары харап була бит, тере көе тураклап ташлар бу чапкыч. Нишләргә? Керпе чарасызлыктан башын энәләре астына яшерде. Балаларыннан башка ничек яшәр ул!?

“Ни булса да булыр, бу чалгыдан коткарса, шушы малай гына коткарыр,”– дип уйлады Керпебикә. Әкрен генә Рәмис янына килде. Аның тирәсендә ярты түгәрәк тә ясап өлгермәде, Рәмис Керпене күреп тә алды.

– Әти, монда керпе бар! – дип кычкырды ул.

– Читкә алып кит, чалгыга керә күрмәсен, -диде әтисе.

Рәмис керпене ипләп тотып, печәне чабылган болын башына чыгарып куйды...

## Яңаралар иске яралар...

Комиссарова Фәнҗия Гавис кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Алабуга районының “4нче гимназиясе”

Кеше кайчан халык күңеленә мәңгегә кереп урнаша? Зур батырлыклар эшләсә, аның өчен яшәсә, хезмәт итсә. Нәкъ менә шул турыда языла “Яңаралар иске яралар”шигырендә. Бу шигырь Актаныш районы Актаныш авылы Бөек Ватан сугышы ветераны Хәмит Махмутовка багышлана.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк бөтен совет халкы Ватанның азатлыгын саклап калу өчен изге көрәшкә күтәрелә. Сугыш елларында татар халкы да явыз дошманга каршы батырларча көрәшә. Алар арасында безнең туганыбыз Хәмит Махмутов та бар. Яшь-ир-егет сугышның беренче көннәреннән алып соңгы көненә кадәр яу кырында дошманга каршы аяусыз көрәшә, Берлинга барып җитә. Сугышның барлык авырлыкларын үз җилкәсендә татып, ул туган якларына исән-имин әйләнеп кайта. Тыныч тормышта да үзен сынатмый. Авылдашлары алдында гомере буена олы тормыш юлы үткән, хөрмәтле кешеләрдән санала.

Менә тагын Бөек Җиңү җитә
Ешрак тибә безнең йөрәкләр.
Бәйрәм якынлашкан саен
Яңаралар кабат яралар...

Китскән чакта җизнәй яу кырына,
Егерме биш тулган, барысы
Озатып калган аны яшь хатыны
Тәпи киткән нәни баласы.

Утны-суны кичеп, Ватан өчен,
Тыныч тормыш, зәңгәр күк өчен
Яу кырында җизнәй дошман куган,
Хәтта Берлинга барып җиткән.

Ул елларда күп авыллар
Су кытлыгы кичерә.
Анда монда иске кое,
Чират бетми көн буе.

Тау астында суның бәргәнен
Күреп ала берчак ул,
Чистартып,тирәнәйтеп,
Чишмә ясап куя ул.

Менә ничә еллар бирле
Ага Хәмит чишмәсе,
Авылдашларына бу
Батыр солдат бүләге...

## Хаталар өстендә эш

Мансуров Мансур Илдар улы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “ 7 нче лицей-интернаты”

Вакытыбыз бераз бардыр әле,
Исән чакта була төзәтергә.
Уйламыйча куйган һәр ноктаны,
Тизрәк әйләндерик без өтергә.

Рәнҗетелгән кайбер кешеләрнең,
Исемнәрен зур хәрефтән башлыйк.
Кызу баштан куйган өндәүләрне,
Җөмлә ахырыннан алып ташлыйк.

Һәр иртәне кызыл юллар ачсын,
Җитсен безгә дәфтәр аклыгы.
Көн дә соңгы итеп язылсыннар,
Изгелекләр, кеше шатлыгы.

Вакытыбыз бераз бардыр әле,
Ашыгырга кирәк беткәнче.
Тулган дәфтәрләрне фәрештәләр,
Соңгы тикшерүгә илткәнче.

## Фатиха варислары

Миннехузина Рәсимә Мидхәт кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “Ф.Г.Аитова исемендәге 12 нче татар гимназиясе”

Гыйбрәт алыйк милләт язмышыннан,
Үрнәк булсын затлы шәхесләр.
Онытмыйк без үткәннәрне бер дә,
Үткәннәрсез юк бит киләчәк.

Күзәтәбез, ерак еллар аша,
Милләтемнең гүзәл баласын.
Белдеме икән, үз эшенең шулай,
Тарихларда мәңге каласын...

## Фәнис абыйга сокланам

Мөбәракшина Зөһрә Мәкъсүт кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “54 нче мәктәбе”

Гадел Кутуй әйткәнчә: “Шагыйрь сүзе укка тиң”. Бу тирән мәгънәле сүзләр, минемчә, Фәнис Яруллинга хастыр. Аның җыентыкларында олы шигъриятне тудыруда катнашкан, иҗат тәлгәшләре бирелгән. Әсәрләрен укып миндә шагыйрьнең иҗатына мәхәббәт һәм кызыксыну уятты. Аның шигырьрләрен, язмаларын кат-кат укыдым. Укыган саен, шигырьләрдә яңа мәгънә ачтым, шагыйрь турында күбрәк белдем.

Бүгенге көндә Фәнис абый безнең горурлыгыбыз, кешелек дәрәҗәбез. Бай мираслы әдәбиятка санлы өлеш кертү юнәлешендә зур көч куйган әдип. Аның иҗатында үзенчәлекле шаянлык һәм шулар белән бергә халык авыз иҗатына хас тапкырлык, сагыну-сагышларны, милләтебезгә хас булган башка асыл сыйфатларын күрергә мөмкин.

Миңа калса Фәнис Яруллин тарафыннан тудырылган, хәзерге заманада бик күпләргә җитми торган – әхлакый сафлыкка, матурлыкка хыянәт итмичә, эчке көрәш аша үзеңдә булган матурлык, тырышлык, сабырлык, олы җанлылык кебек сыйфатларны җуймасак идек.

Шагыйрь иҗаты мәңге. Бу шулай булырга тиеш тә.

Бөркет булып канатланып
Мин татар дия алам.
Туган телне бик яратам
Шигырьләр сөйли алам.

Кем яратмый, кайсыгыз соң
Туган телен, уз телен?
Әнкәй сөте белән сеңгән
Кадерле татар телем.

## Әгәр ул кайткан булса...

(хикәя)

Мөхәммәтова Айсылу Марат кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “146 нчы Ресурс лицее”

Укытучы! Нинди бөек исем! Әлеге һөнәр ияләренең бәяләп бетергесез хезмәтен, асылын үзем укытучы булып эшли башлагач кына аңлый башладым. Баксаң, әлеге исем артында күпме тырышлык, күпме маңгай тире, күпме рәхмәт сүзләре, күпме хөрмәт ята. Хикәямне нәкъ менә әлеге һөнәрне сайлавымда хәлиткеч рольне уйнаган кешегә багышлыйсым килә.

1941 нче ел. 22 нче июнь. Сәгать иртәнге 4... Әйе, инде сугыш тәмамланып, ярты гасырдан артык вакыт үтсә дә, бу шомлы дата, кайгылы минутлар, кешелек аңыннан һич кенә дә югала алмыйлар. Киресенчә, бу чор турында уйлануларым еллар үткән саен тагын да күбәя.

Сугыш... Нинди шомлы, авыр, ямьсез сүз. XXI гасырның бәхетле баласы булуыма карамастан, бу сүзне ишетүгә күңелемдә әйтеп бетерә алмаслык авыр хисләр дулкыны барлыкка килә, тәнем буенча ниндидер бер кайнарлык йөгерә. Күпме яшь гомерләрне өзгән, тату, гөрләп торган, матур гаиләләрне аерган, күпме мәхәббәтле йөрәкләрне яралаган, бер гөнахсыз балаларны ятим калдырган, якты, аяз күк йөзенә кара төтен җибәргән бу дәһшәтле, авыр еллар кайсы гына адәм баласының хәтереннән китәр икән?!

Бабаемның әтисе, ягъни минем карт бабаем, Салихов Мөхәммәт Салих улы 1902 нче елда Олы Шыңар авылында дөньяга килә. Авылның иң тырыш егете, булдыклы ире була ул. Җирен дә эшкәртә, итеген дә баса, кулыннан килмәгән эше булмый аның. Башкорт якларына кадәр барып (тегүчелек итеп) акча да юнәтә белә. Озак та үтми, авылның иң булдыклы, тырыш, чибәр кызы Сафия белән матур гаилә корып җибәрәләр. Тормышларын шатландырып, башта Сәгъдәнә, аннан Равил дөньяга аваз сала.

Тирә-якка даны таралган Сатыш мәдрәсәсен тәмамлаган Мөхәммәт бабайны 30 нчы елда Олы Шыңар башлангыч мәктәбенә укытучы итеп билгелиләр. Моңарчы әле балаларга белемне аерым йортларда гына бирәләр. Бабаем, өч йортны берләштереп, башлангыч мәктәп бинасы төзүне оештыра. Көндезен балаларга белем бирсә, кичләрен өлкәннәр белән була ул. Моннан тыш 38 нче елда читтән торып Арча педагогия училищесын тәмамлый...

## Җәйге сабак

Нургалиева Гөлчәчәк Рәшид кызы,
туган тел һәм әдәбияты укытучысы
Мамадыш районының “1 нче урта мәктәбе”

Әй рәхәт тә инде җәй көне! Рәхәтләнеп урамда уйнарга, ял итәргә була. Телисең икән, инеш буена төшеп, балык тот, я булмаса, аяк киемеңне дә салып тормыйча, җылымса суда бака ку... Бакалары да, качышлы уйнагандай, сине үртиләр, әле аяк астында гына сикерешәләр, тотыйм дип үрелсәң, әллә ничек кенә читкә сикерәләр дә, мәрҗәндәй күзләрен елтыратып, карап утыралар.

Әлегә инеш буе тын, көз көннәрендәгечә, шау-шу килүче каз-үрдәкләр дә юк әле биредә. Бибиләр, йомшак йомгак булып, капка төбендәге чирәмлектә генә йөриләр.

Җәй аеның башланып кына килгән мәле. Урамга чыксаң, яшел үлән исеннән баш әйләнә, кояш җылысын кызганмый, учлап-учлап җир өстенә сибә. Мәктәпкә барасы юк, туйганчы ял итәргә була. Ничек шундый рәхәтлекне күрмичә, тоймыйча ятасың инде!

Кечкенә Айнур да, абыйсының җәйге каникулы башлануга, бакчага йөрүдән туктады. Ничек кенә үгетләп карасалар да, балалар бакчасы ягына әйләнеп тә карамады.

– Минем закунный атпускы, 3 ай,– дип бармакларын гына җәйде.

– Ярар инде, калсын, мин дә бит үзем генә калам, бергә-бергә күңеллерәк булыр,– диде абыйсы. Әбиләре эндәшмәде. Үзенең иртәдән кичкә тикле бетмәс вак-төяк мәшәкатьләре өстенә Айнур исемле тиктормасның күпме яңа эш өстәячәген аңламыймы инде Фагыйлә әби? Аңлый, әлбәттә. Айнурны абыйсы гына карап җитешәме соң? Ут борчасы бит ул!...

## Мәдхия

Нургалиева Халидә Әбүзүр кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Азнакай районының “Тымытык урта гомуми белем бирү мәктәбе”

Мин “Мәдхия“ шигыремдә язмыш тарафыннан рәнҗетелгән, әмма тормышта сынмаган, сыгылмаган, инвалид коляскасына утырып иҗат итеп, Тукай, Җәлил премияләренә лаек булган халык шагыйре Фәнис Яруллин шәхесенә, аның бөеклегенә дан

булырдай хисләремне чагылдырдым. Ф. Яруллин иҗаты тәрбияви көче ягыннан искиткеч тәэсирле, аның шәхесе һәрвакыт безнең күңелләрдә. Шигыремнең актуальлеге дә шунда.

Язмыш аны сынаса да,
Ул бөгелеп төшмәде.
Инвалид креслосында да
Армый-талмый эшләде.

Җәлил, Тукай премиясен
Ул бик лаеклы алды.
“Халык шагыйре” булып,
Күңелгә кереп калды.

Дан һәм абруй кешегә
Юкка гына бирелми.
Фәнис абый шәхесенә
Мәхәббәт һич сүрелми.

## Ярлыкарга соңару

Нургалиева Халидә Әбүзүр кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Азнакай районының “Тымытык урта гомуми белем бирү мәктәбе”

Башкорт язучысы Мостай Кәримнең “Ярлыкау” повестен күз яшьләреннән башка укып булмый. Анда Мария Тереза һәм Любомир Зух дигән ике яшь йөрәкнең сугыш вакытында кичергән ачы язмышлары турында сөйләнә, фаҗигале мәхәббәтләре сурәтләнә. Повестьның эчтәлеге бик тәэсирле булганга, мин аны шигъри юлларга әйләндереп, поэма итеп яздым. Инде сугыш беткәнгә 76 ел булса да, фаҗигасе һаман да күңелләрдән җуелмый шул... Повестьның актуальлеге дә шунда дип исәплим.

Мин кулыма повесть алдым...
“Ярлыкау”. Мостай Кәрим.
Мондагы төсле мәхәббәт
Җирдә бар микән , белмим!?

Сугыш чоры. Танкистлар
Бер авылга туктала.
Мария дигән матурны,
Любомир күреп ала.

Сугыш законнары кырыс.
Сугыш ул шундый афәт
Сугыш өчен сөю дә юк
Юк шулай ук мәхәббәт.

## Әнигә хат
(хикәя)

Сафина Алсу Камил кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “129 нчы мәктәбе”

Исәнме әни!

Исәнме минем якыным.

Баш очында утырып сиңа күңелемнән хат язам. Син генә бу хатымны беркайчан укымаячаксың! Җыерчыклы кулларыңа башымны куям, ак чәчләреңне сыйпап, битләреңнән үбәм! Минем өчен дип яшәгән, кызым дип типкән йөрәгеңне тыңлыйм! Әнием....

Күпме кеше гомерен саклап калыр өчен, сайлаган һөнәреңә тугры булып көне-төне чапкан аякларың хәлсез бүген. Ялгыз тормыш арбасын җигелеп тарткан ябык җилкәләрең вакыт-вакыт дерелдәп куя. Матур гына яшәп яткан җиреңнән аяусыз авыру үз кочагына алды сине. Ышанасым да килми, чибәрлегең һәм уңганлыгың белән дан тоткан әнием! Менә бүгенгесе көндә ачы язмыш икебездән берьюлы имтихан ала. “Аз сынадым әле”,– дип уйлавымы, әллә инде “яраткан бәндәмә”,– дип бирелгән сынауны ахыргача үтәүне таләп итүеме?...

## Кәрлә каен күз яше
(хикәя)

Сафиуллина Гөлфия Әнвәр кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Әлки районының “Алпар урта гомуми белем мәктәбе”

Мин яши торган дөнья төрледән-төрле төстә. Шуңа күрә ул бик матур булып күренә. Мамык кебек йомшак буранлы һәм энҗе карларга бай зәмһәрир Кыш, без яратып ашый торган файдалы җиләк-җимешләр, яшелчәләр үстереп биргән алтын кебек асылташка тиң мул Көз, җәннәт бакчасына тиң “уртача табигатьле” мөлаем Җәй һәм Җирне генә түгел, кешеләрнең дә күңелләрен чистарта торган назлы Яз.

Шундый матур сыйфатларга ия булган Кыш, Көз, Җәй һәм Яз бергә җыелып киңәшләшкәннәр дә, барысына да рәхәтлек бирә торган уртак йорт төзергә булганнар. Ә бу йортны яшел төскә буяп бизәргә кирәк диган фикергә килгәннәр. Бу төс барысының да күңеленә хуш килгән.

Шулай итеп, Кыш күп итеп энҗе карларын яудырган, Яз елга-күлләрне изге су белән тутырган, Җәй бар җиһанны җылы бишегенә салып тибрәткән, Көз шул арада бетмәс-төкәнмәс муллык иңдергән.

Ә кешегә Җирдә яшәү өчен тагын нәрсә кирәк соң ?! ...

## Укытучыма

Тимуршина Илгизә Каюм кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “77 нче мәктәбе”

Укытучы һөнәре – җир йөзендә иң гүзәл һәм иң җаваплы һөнәрләрнең берсе. Һәр кешенең, ул тормышта нинди генә зур дәрәҗәгә ирешкән булмасын, белем алуы мәктәп бусагасын атлап кергән көненнән башлана. Ә мәктәптә аны елмаеп, үз баласыдай якын күреп, беренче укытучысы каршы ала. “Үзеңнән соң җирдә мәңгелек эз калдырыйм дисәң – укытучы бул!” дигән бер галим. Хак сүзләр.

Ул зур түгел, әмма олуг үзе,
Гади, ләкин гали сүзләре.
Аның һәрбер сүзе күңелләрдә,
Кояш кебек карый күзләре.

Аны яратмаска мөмкин түгел,
Ул яшәгән дөнья шундый зур:
Анда Тукай, анда Җәлил, Такташ,
Сүзләре дә гүя моңлы җыр…

Туган телебезгә мәхәббәтне миндә укытучыбыз Оркыя апа, Арча педагогия училищесында Гөлсинә апа, Казан педагогия институтында Фоат абый Галиуллин тәрбияләде дип саныйм. «Укытучыма» дигән шигырь санап киткән милләтпарвәр укытучыларга багышлап язылды. Шигыремнең соңгы юлына мин тугры калдым дип уйлыйм.

## Гомернең чәчәге

Тукманова Мәдинә Хәйрулла кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “91 нче мәктәбе”

Элек сабантуйның төп мәзәге ат чабышы белән көрәш иде. Анда нәселле атлар чапмый иде. Колхоз атлары ярыша иде. Мансурга да колхоз председателе ат бирде чабышырга, чөнки ул ат җене кагылган малай иде. Сабан туе җитәргә бер атна кала Макай дигән бияне ашата башлады. Ул аңа атланып чабып, аягын кыздырып кайта иде. Макайның тае бар иде. Ул да аларга ияреп йөри иде. Аңа әнисенең чабуы кызык ахры. Рәхәтләнеп янәшәдә чабып барды. Менә Сабан туе җитте. Тайны, комачауламасын дип, ябып калдырдылар. Унлап ат төзелгәннәр чабышырга. Шунда Макай кешнәп җибәрде. Башын авыл ягына борды. Караса, аның тае чабып килә. Кем чыгангандыр, белгән юк. Ул дә кешни. Килеп җитүе булды, атлар чабырга кузгалдылар. Тай тагылды инде. Чабалар. Мансур өченче булып бара. Шунда әдәм ышанмаслык хәл килеп чыкты – тай алга чыкты бит. Беренче булып чаба. Аның артыннан Макай элдертә иде. Узып киттеләр. Беренче булып килделәр. Аларга карап торган халык егыла-егыла көлде. Колхоз председателе беренчелекне алган өчен бигрәк Макайның таен мактады. Киләсе Сабан туйларына шуны чаптырабыз, диде. Тик чаба алмады шул, бахыр. Әллә теге чабудан өзлекте яшь тай, әллә бүтән бернәрсә булды – көз җитәрәк үлде таебыз.

Әлеге кыйсса нык тәэсир итте. Уйга бу фикер килеп керде. Үзенең әнисе янында үсүен, иркәләнүен, әнисе белән бергә чабышып уйнавын һәм Сабан туенда катнашуын, әнисен беренче урынга чыгару өчен тырышуын тай үзе сөйләргә тиеш иде...

## Әнием эндәшүе

Тухватуллина Гөлнах Миннеәхмәт кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “65 нче мәктәбе”

Әнием яратып дәшкән
Сүзләрне тезеп китсәм.
Тыңлап утырырга сезнең
Түземлек җитәр микән?
Мин шикәр дә, мин бал, май да
Сандугач җәйге таңда.
Бәхет кошы, асыл ташы,
Тәмле җимеш суы да.
Бәгырь кисәге булам мин
Әниемә һәрвакыт.
Ул матур сүзләрне, белмим,
Бетерә кайдан табып?!
Җаным, алтыным, кояшым-
Әйтелмәгән сүз калмый.
Шуларны көн дә кабатлап
Әнием ничек армый?
Йөрәк парәм – балам син, дип,
Күзләремә карый да.
Күңелләргә җылы өрә
Шул сүзләрнең бары да.
Алма булам, хөрмә булып
Куямын кайчакларда.
Шулай эндәшүләреннән
Туймам мин беркайчан да!

## Балачагымның бер көне

Фадеева Гүзәл Хәмзә кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Теләче районының "Олы Нырсы урта мәктәбе"

Яратам да инде җәйге иртәне! Тагын бер яңа көннең тууын күзәтү бик күңелле. Җәен иртә яктыра башлый. Беренче кояш нурлары акрын гына йоклаган җир өстенә сибеләләр. Алар барлыкка килү белән, елга өстендәге томан да ашыкмыйча гына күтәрелә башлый, чирәм өсләрендә миллионлаган утлар кабына. Ләкин җир өстендәге чык озак яктыртмый шул. Һәр минут саен кими бара. Тирә-якка төрле үләннәрнең татлы исе тарала. Һава саф һәм хуш исле.

Иртәнге якта бик тыныч. Әйтерсең лә, җир, ниндидер могҗиза көткәндәй, сулыш та алмыйча тын калган. Менә инде кошларның күңелле чыркылдавы ишетелә, кайдадыр сандугач сайрый. Кошлар да яңа көнне шатланып каршы ала...

"Балачагымның бер көне" хикәясенең темасы – һәр кеше яшь чактан ук нинди дә булса һөнәр үзләштерергә тиеш.

Бу хикәя кешелек тормышы белән табигать арасында булган мөнәсәбәтләрне чагылдырган һөнәрләрнең юкка чыга бару проблемасын өстен куя. Бүгенге көндә умартачылык белән шөгыльләнүчеләр азая бара. Киләчәктә бу эшчәнлекнең бөтенләй юкка чыгуы да бар.

Бу күренешнең, үз чиратында, экологик проблемалар белән дә бәйле булуы бар, чөнки бүгенге көндә дөньяда бал кортларының нык кимүе күзәтелә. Ә бал кортлары тереклек дөньясының яшәешендә мөһим урынны алып торалар. Шунлыктан аларның санын арттыру кирәклеге килеп туа. Бу эш белән бары тик тәҗрибәле умартачылар гына шөгыльләнә ала. Аларның тәҗрибәсен киләчәк буынга мирас итеп тапшыру зарур.

Киләчәктә умартачылык һөнәре кешелек дөньясында иң мөһим һөнәрләрнең берсе булырга мөмкин. Шунлыктан әсәрнең эчтәлеге дә шул проблеманы чишү юлын чагылдыруга багышланган.

## Кеше булып калыйк

Ханнанова Фирдания Мөнәвир кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Зәй районының "М.Х.Хасанов исемендәге гомуми белем мәктәбе"

Кеше җиргә нәрсә өчен килә,
Шушы сорау борчый күңелне.
Тиешенчә дөрес яшибезме,
Ходай биргән кыска гомерне?

Кайчакларда явыз сүзләр әйтеп,
Рәнҗетәбез якын кешене,
Назлы сүзләр, дога уку өчен
Яраткандыр ходай бу телне.

Алтын-көмеш, байлык диеп,
Кеше гомерләре өзелә.
Ә куллар бирелгән безгә
Матур итеп тормыш төзергә..

## Язмышың китабын актардым....

(Ф. Яруллинның “Хәтер төпләрендә утлы күмер” китабын укыгач)

Хафизова Илхамия Мулланур кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “М.И.Махмутов исемендәге 184 нче мәктәбе”

Язмышың китабын актардым...
Уйландым, борчылдым, уфтандым.
Шулкадәр сынаулар үтеп тә
Сер бирмәгәнлегеңә сокландым.

Язмышың китабын актардым...
Кайчак та, аптырап тын калдым.
Кимсенеп яшәлгән җаныңның
Керсез калганлыгына таң калдым.

Язмышың китабын актардым...
Мәхәббәт – бөек хис, ышандым.
Нурсөяң – бар дөньяң икәнен
Белә идем, кабаттан инандым.

Язмышың китабын актардым...
Сыкранды йөрәгем, еладым.
Көчле рух яшәтә, зур сынау ныгыта.
Икән бит. Мин шуны аңладым.

## Тау чишмәсе

Хәйретдинова Роза Җәмил кызы,
туган тел һәм әдәбияты укытучысы
“Сәламәтлеге чикләнгән балалар өчен 9 нчы Зәй мәктәбе”

Таныш сукмак буйлап, үзем дә сизмәстән, чишмә юлына борылдым. Юлда миңа таныш сылу каеннар очрады. Алар бүген аеруча көяз утыралар. Шаян җил, аларның алкаларын күрсәтергә теләгәндәй, үзенең асылмалы бишегендә салмак кына тибрәндерә. Тау итәгендә сап-сары булып үги ана яфраклары, тузганаклар чәчәк атканнар. Яшел келәмдә сап-сары бизәкләр нинди матур! Бу матурлыкны күрми һич мөмкин түгел!

Яраткан тау чишмәмнең челтерәве әллә кайдан ишетелә. Монда бернинди көй дә кирәк түгел. Мин бу тавышны әллә кайдан таныйм. Аяк атлауларымны тагын да ешлатып чишмәмә якынлашам.

Чү, кунак бар түгелме? Әйе, җырчы сандугач та чишмәнең татлы суыннан авыз итәргә булган икән ләбаса. Сандугач чишмә көенә үзенең чүт-чүт итеп сайравын да куша. Бергәләп оркестр оештырганнармы, әллә ярышмы!? Белмәссең? Мин кошкайны куркытмыйм дип, читтән генә бу манзараны күзәтәм. Моны сүз белән әйтеп бетерерлек түгел!

Әһә, миңа да чират җитте. Кушучыма алып саф чишмә суын эчәм. Нинди салкын суы, тешләрне камаштырырлык. Тын гына басып, чишмә җырын тыңлыйм. Аның челтерәве күңелләргә тынычлык бирә.

Челтерә, чишмәкәй, челтерә! Без юлаучыларга үзеңнең шифа – дәваңны бир, безне сөендер. Юлыңнан беркайчан халык өзелмәсен. Синең сихри тавышың тынмасын. Озак еллар челтерә, чишмәкәй!

Таныш сукмак буйлап юлымны дәвам итәм...

## Түбән Аты Шүрәлесе

Хәмидуллина Зөлфия Ясәви кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Арча районының “Түбән Аты урта гомуми белем мәктәбе”

Авылдагы күпбалалы һәр гаиләне безнең дәүләт,
Бушлай җир-кишәрлек белән бүләкләде, дәүләп.
Бик матур җәйге көндә авылыбыздан бер ир-егет
Гаиләсе белән шул җиргә килгән , бер ат җигеп.
Әтиләренең балаларны да ияртәсе килә икән:
“ Әйдәгез , урман якын – җиләк җыярсыз! – дигән.
Урманга килеп кергәч ,бер зат күренә искитмәле:
Яхшылабрак караса егет – бу бит таныш Шүрәле!
“Ир-егет, хәйләләп, кулны кыстың – ышануыма үкенәм.
Менә үч алыр чак житте бит – шатлыгымнан үкерәм.”
“Исәнме-саумы, бер дә үзгәрмәгәнсең бит син, Шүрәле!
Әй, Урман хуҗасы, холкың ничек соң, төзәлмәдеме?
Ә мин үзгәрдем менә: яшь-җилбәзәк егет түгел инде!
Гаярь ир, гаилә башлыгы, исемем шул ук: Былтыр инде.
Җиләк җыеп йөри – болар минем газиз балалар,
Тукай китапларын белгәч, сине тиз таныдылар...

## Күзләр күбрәк ошый миңа хәзер

Хикматуллина Роза Фоат кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “40 нчы гимназиясе”

Күз һәр кешенең күңелендә төрле хисләр уята: кемдер күзгә сөенә, ә кемдер өчен күз сагыш-кайгы белән чагыштырыла. Лирик герой хәсрәт эчендә яшәвен сурәтли. Ышанулар, өметләр үткән көннәрдә калган. Хәсрәт аның гадәти яшәү халәтенә әйләнгән. Герой әлбәттә, үзенең бу халәтенә күнмәгән. Шуның өчен дә бернигә карамастан ул күңелендә язлар көтә.

Көзләр күбрәк ошый миңа хәзер
Ә язларны күптән мин көтмим.
Күңелдәге бушлык, бәхетсезлек,
Язлар белән туры килми күк...

Ышанулар, чиксез ак өметләр,
Ерак калды үткән көннәрдә.
Ходаемнан сәламәтлек сорап,
Яшимен мин сары көзләрдә...

## “Ана һәм мәңгелек солдат”

Хисамиева Рәсилә Рәүф кызы,
рус теле һәм әдәбияты укытучысы
Арча районының “Ашытбаш урта гомуми белем мәктәбе”

Бөек Ватан сугышында җиңүнең миллионлаган кеше гомере барәбәренә яуланган булуын истән чыгармау, тынычлыкның кадерен белү, саклау, туган илнең яклаучылары һәм

саклаучылары булу, баласын югалткан ананың хисләрен чагылдыру, батырлар даны мәңгелек булуын аңлау максатыннан язылган шигырьләрем. Күп еллар үтсә дә, яшь буын, киләчәк буын бәхетле тормышның нинди югалтулар нәтиҗәсендә килүен онытмаска тиеш. Балаларын югалткан аналар, тол хатын-кызлар, "әти" сүзен әйтергә тилмереп үскән балалар. Бу сугыш китергән афәтләр. Тыныч тормышта мондый хәсрәтләр булмасын өчен үткәнеңне белергә, булган матур тормышны сакларга кирәк.

Һәйкәл яны, һәр яз саен ана
Чәчәк сала солдат каршына.
– Җиңәрмен дә, кайтырмын мин ,– дидең
Кайтмадың бит, балам, яныма.

Җыерчыклы куллар назлый сынны
– Салкын түгелме соң, бәбкәем?
Таныдыңмы мине, әби булдым
Агарды бит көтеп чәчкәем.

## Көнләшерлек итеп, яшәп кал!

Шайдуллина Гүзәл Хатмулла кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Алабуга районының "А.Н.Епанешников исемендәге 3 нче мәктәбе"

Бу дөньяда төрле кешеләр бар
Кемдер сине өзелеп ярата.
Кемдер синең якын дустың була
Кемдер синең йөзне каралта.

Көнләшүчеләр аз түгел җирдә
Кемдер ак көнләшү белән көнләшә.
Кемдер инде начар сүзләр сөйләп,
Синең хакта гайбәт өләшә.

Кеше җирдә яшәү өчен туа
Һәрбер кеше яши үзенчә.
Кемдер белем ала, хезмәт итә,
Зиһен туплый үзенә кирәкчә.

Акыл белән җирдә яшә, Кеше!
Уйлан! Эзлән! Тыңла! Белем ал!
Тормыш матур аның кадерен белеп,
Көнләшерлек итеп, яшәп кал!

## Урман әбие

Шафикова Гүзәлия Рәхимша кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Алабуга районының " А.Н.Епанешников исемендәге 3 нче мәктәбе"

"Урман әбие" дип исемләнгән хикәядә авыл тормышы сурәтләнә. Шушы авылда гомер итүче Фатыйма исемле әбинең сагышка төренгән көннәре, төннәре турында хикәя ителә.

Әбинең авыл халкы арасындагы дәрәҗәсе, авылның барлык бала-чагасының әбине хөрмәт итүе турында сөйләнелә.

Хикәянең башлам өлешендә Сылу исемле кызга әбинең җиләклеккә бару юлын өйрәтүе турында языла. Элегрәк авыл халкы тормышын урман белән бәйләп алып барды. Кышлык печән әзерләү, утын хәстәрен күрү, тәмле кайнатмалар ясарга кура җиләге җыю, чикләвек җыюлар – болар барысы да авыл янындагы урманда эшләнде. Урман турында болай хикәяләнә: “Безнең авыл чокыр эчендә урнашкан. Авылдан берәр чакрым ераклыкта урман күренеп тора. Катнаш урман булганга, ул бик куе. Ап-ак күлмәкле каеннар, кырыс имәннәр, ачык йөзле усаклар, сыйлы чикләвек куаклары, мәңге яшел чыршы белән нарат – барысы да бер тату гаилә булып яшәп яталар Норма урманында. Ә Фатыйма әби бу урманның көндәлек кунагы. Әби урманда бер көн күренмәсә, бу агачлар, урман юлы “Кая бүген безнең кортка, авырып киттеме әллә югыйсә?”– дип юксыналардыр, мөгаен.” Авылда яшәүче һәр бала 1 Май бәйрәменә Фатыйма әбигә ияреп урманга менә. Урманга әбигә ияртеп балаларын менгереп җибәрергә әти-әниләрнең берсе дә шикләнми иде. Чөнки беләләр, әбинең балалар алдында абруе зур. Менә шушы урман аланы, анда менгәч умырзая җыеп фотога төшүләр, алып менгән ризыкларны бер табынга куеп, җыйнаулашып утырып ашау балаларның күңелендә мәңгегә калды да инде. Чөнки бу балаларның берсе мин үзем.

Хикәянең төп өлешендә Фатыйма әбинең улы, килене турында сөйләнә. Әбинең улын югалтуы, килененең кайнанасына карата тискәре мөнәсәбәте, оныгының да әбине үз әбисе итеп танымавы тасвирлана. “Урман әбинең бердәнбер юанычы хәзер. Анда ичмаса кошлар тавышы һәм агач яфракларының үзара серләшкән тавышы гына ишетелеп тора. Урманда кайда каен җиләге уңган, быел чикләвек куакларында кишәнкәгә ничәшәр чикләвек төшкән, сарыкларга җыярга кайсы имәндә чикләвек күп, кура җиләге эреме быел, кайсы аланда печән каерылып үскән – авыл халкы бу сорауларга җавапны Фатыйма әбидән сорашып белә.” Фатыйма әбинең күршесендә Сылу исемле кыз да әбигә ияреп күп йөрде урманга. Кура җиләге җыярга да алып менеп китә иде әби Сылуны.

Әбинең урманда баласы белән очрашуны эзләп йөргәнен авыл халкы белмәде. Чөнки ул беркемгә дә күргән төшен сөйләмәде. “Шушы төшне күргәннән бирле, ул урманга сукмакны бетерми, хәтта кыш көннәрендә дә, кар бик тирәнәйгәнче, урманга менә иде. Авылдашлары әбинең урманга бик ешлавының сәбәбен аңламадылар, билгеле. “Кайгысын басар өчен менәдер, бичара, бигрәк бердәнбер баласыннан да язды бит”,- дип сөйләнделәр алар.”

Әбинең гомере урмандагы Заһит аланында өзелә. “Ә бу вакытта үзенең газизе белән кавышкан ананың җаны, өрфиядәй болытлар өстеннән чиксезлеккә таба оча иде. Гаязы сүзендә торды, әнисен алырга Заһит аланына кайтты.”...

## Унбер бөркет

(1944 нче елның 25 нче августында Берлиндагы Плетцензее төрмәсендә җәзалап үтерелгән җәлилчеләргә багышлана)

Шәгәрәева Алинә Илсур кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Казан шәһәренең “Татар телендә белем бирүче 13 нче гимназиясе”

Егерме бише, август. Ә бәгырьне өтә
Көзге ачы җилләр салкыны.
Җирне җәһәннәмгә әверелдергән
Каһәр суккан сугыш ялкыны.

Таң атса да, кояш чыкмас бүген –
Шаһит булмас мондый вәхшәткә.
Унбер бөркет соңгы тапкыр оча,
Палач күзе карый сәгатькә.

Соңгы очыш – бер йөз ундүрт адым –
Камерадан гильотинага…
Мескенләнеп түгел, батыр булып,
Бәрелеп үлә бөркет кыяга…

## Китап

Шәйхулова Миләүшә Фәгыйль кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Азнакай районының "Җиңү бистәсе урта бирү  мәктәбе"

Яшәү күпкә  кызыклырак,
Карале үзең  уйлап:
Тормышыңда әгәр синең
Зур урын тотса китап.
Бала чактан, кечкенәдән
Китап белән дуслаш син.
Якын дустың, сердәшеңә,
Киңәшчеңә әйләнсен.
Авыр булган минутларда
Ул да ярдәмгә килер,
Тынычландыру юлларын
Һәркемнән яхшы белер.
Хыянәтсез, тугрылыклы
Дус булыр ул һәрвакыт.
Аннан  алган ләззәтне
Алмассың хәтта сатып.

## Эчтәлек

I. Фәнис Яруллинның шәхесе һәм иҗаты

Ахметов Нияз. Татар әдәбиятын үстерүдә Фәнис Яруллин иҗатының роле ............................ 3
Ахтямова Ильвина. Фәнис Яруллинның әкиятләрендә уңай һәм тискәре геройлар ................. 3
Ашит Диләрә. Әкият ул тылсым яки хыял дөньясы гына түгел ................................................ 4
Басырова Гүзәл. Фәнис Яруллин шигырьләренә язылган җырлар ............................................ 5
Басырова Эльмира. Фәнис Яруллинның “Кыйгак-кыйгак каз кычкыра”әсәренә анализ.......... 6
Галәветдинова Рузия. Фәнис Яруллин шигъриятендә яшәеш фәлсәфәсе ................................. 7
Ганиев Әмир. Фәнис Яруллин иҗатында бала холкын күрсәткән юмор һәм сатира ................. 8
Гарипов Вильдан. Фәнис Яруллинның “Әнә килә автомобиль” әсәрендә юмор һәм сатира бирелеше........................................................................................................................................ 9
Гарифуллина Азалия. Фәнис Яруллинның ярдәмчеләре.......................................................... 10
Гатауллина Кәмилә. Әдип иҗатында юмор һәм сатира ............................................................ 10
Гиматдинова Илүзә. Татар әдәбиятын үстерүдә Фәнис Яруллин иҗатының роле.................. 11
Җәләева Әминә. Фәнис Яруллин иҗатында балалар дөньясы ................................................ 12
Зәбиров Умар, Газизов Амир. Фәнис Яруллинның бәрәкәтле һәм игелекле иҗаты ............... 13
Зәйнуллина Аделина. Әкиятләрдән олы тормышка.................................................................. 14
Иванов Сергей, Гыйлметдинов Ислам. Фәнис Яруллинның шигырьләре көлдерә дә, тәрбияли дә ..................................................................................................................................................... 15
Кашапова Динә. Фәнис Яруллинның әдәп-әхлак мәсьәләсен күтәргән балалар прозасын инглиз теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләре ............................................................................... 15
Менлишев Егор. Фәнис, син миннән әйбәтрәк.......................................................................... 16
Минһаҗева Айзилә. Фәнис Яруллин әкиятләренең үзенчәлекләре ......................................... 17
Мифтахова Адилә. Фәнис Яруллин юмор һәм сатира остасы .................................................. 18
Муллахметова Лилия. Фәнис Яруллин – драматург .................................................................. 18
Мухетдинов Марсель. Фәнис Яруллин – халкыбызның йөз аклыгы ........................................ 19
Нажарова Айзилә. Фәнис Яруллин иҗатында балалар психологиясенең чагылышы............ 20
Насырова Алина. Фәнис Яруллин әсәрләренең тәрбияви көче ............................................... 21
Рафиков Алмаз. Фәнис Яруллин шигырьләренә язылган җырлар ........................................... 22
Саттарова Аминә. Фәнис Яруллин иҗатында юмор һәм сатира .............................................. 23
Файзрахманова Камилә. Фәнис Яруллин иҗатында юмор һәм сатира.................................... 24
Фахриева Алинә. Әдип иҗатында юмор һәм сатира ................................................................ 25
Хабибуллина Альбина. Фәнис Яруллин һәм аның гаилә дуслары ........................................... 25
Хайбуллова Әдилә. Фәнис, син – сүнмәс йолдыз ..................................................................... 26
Хасбиева Амелия. Җыр калдырыйк ............................................................................................ 27
Шайдуллина Зилә. Татар балалар әдәбиятын үстерүдә Фәнис Яруллин иҗатының роле....... 28
Шакирова Диләрә. Җыр калдырыйк җирдә, нур калдырыйк.................................................... 29
II. Укучылар иҗаты
Абдрахимова Азалия. Туган як .................................................................................................... 30
Акчурина Найлә. Республикам – Татарстан ............................................................................... 30
Ахметзянова Зилия. Әнием .......................................................................................................... 31
Ахметзянова Ясминә. Митрәй гармуны ..................................................................................... 331
Ахметшин Гаяз. Дуссызлык .......................................................................................................... 31
Валиев Хәлил. 41 нең ябык балалары ......................................................................................... 32
Вафина Таңсылу. Татарстан .......................................................................................................... 32
Габделбаров Ислам. Сак булыгыз юлларда!................................................................................ 32
Габдрахманов Инсаф. Яңгыр......................................................................................................... 33
Гатауллина Кәмилә. Кечкенәдән шигырь язам... ........................................................................ 33
Давлетшина Алия. Хыял ................................................................................................................. 34
Зайдуллина Ләйлә. Шагыйрь бәхете.............................................................................................. 34
Закирова Илвина. Эзләр ................................................................................................................. 35
Зиганшина Әминә. Мин тормышка гашыйк ................................................................................. 35
Ибрагимова Фирүзә. Авылыма ...................................................................................................... 36
Каримов Гайсә. Туган телем минем! ............................................................................................ 36

Максимов Евгений. Туган ягым ........ 36
Мустафина Йолдыз. Горурлыгым минем - Кукмарам! ........ 37
Набиуллина Гөлназ. Иң куркыныч сүз ........ 38
Нугуманов Булат. Әбиләргә – кунакка ........ 38
Нуризянова Азалия. Әнкәем ........ 39
Окунева Аделина. Әниемә булышам ........ 339
Сагитова Нурзилә. Аякларым кадакланган минем... ........ 39
Салахова Лилия. Әлкәемнән илһам алам ........ 40
Сафина Алисә. Фәнис абый Яруллин ул... ........ 40
Сафуанова Альбина. Туган телем – татар теле ........ 41
Фарукшина Илзира. Батыр  шагыйрь ........ 41
Хайруллина Эльвина. Хәтер сагында ........ 42
Хадиуллина Дилә. Кыш. Туган ягым кышы ........ 42
Хакимова Әминә. Әнием ........ 43
Хасанова Чулпан. Туган авылым ........ 43
Хисамиева Ландыш. Ана һәм мәңгелек солдат ........ 443
Шакирова Ләйлә. Әбием ........ 44
Шамкина Диана. Күрәчәкне күрми ........ 45
Шангараев Йосыф. Әни йөрәге аша ........ 45
III. Укытучылар иҗаты
Ахмадуллина Р.Ф. Кыр казлары ........ 46
Ахметова Г.А. Мең дә бер сорау. Иртәнге моң ........ 46
Әхмәтҗанова Ә.Ф. Розалар иле ........ 47
Әхмәтҗанова Д.Р. Укытучыма ........ 448
Әхмәтова Р.З. Үги кыз ........ 48
Әхмәтшина Л.Т. Фәнис Яруллинга ........ 49
Борисова Р.В. Күңел халәтем шигырьләремдә... ........ 49
Габдрахманова Н.Ш. Йөрәк кушуы ........ 50
Габдрахманова Р.Ә. Әниемә ........ 51
Галиева Ә.Ә. Шигырьләрем белән ........ 51
Гарипова Л.Г. Аккош язмышы ........ 52
Гәрәева Л.Ә. Бер игелек турында ........ 52
Гилфанова В.Ж. “Һәр ел саен яз җитүен көтәм...” ........ 53
Гыйниятуллина Р.Х. Очрашу ........ 54
Закиров А.М. Шигырьләрем йөрәк түренннән ........ 54
Закирова Г.И. Туган нигез ........ 55
Зарипова Г.Г. Төзәлдеме күңел ярасы? ........ 556
Зарипова Д.Ф. Кайтыгыз ........ 556
Заһитова З.И. “Өметем бар...” ........ 57
Зиатдинова Л.Һ. Вөҗдан газабы ........ 58
Исрафилова Ә.Р. Әнием, кояшкаем! ........ 58
Калимуллина Р.Ә. Тормыш чыганагы ........ 59
Касыймова З.Г. Үз җиремдә ........ 59
Комиссарова Ф.Г. Яңаралар иске яралар. ........ 60
Мансуров М.И. Хаталар өстендә эш ........ 61
Миннехузина Р.М. Фатиха варислары ........ 61
Мөбәракшина З.М. Фәнис абыйга сокланам ........ 62
Мөхәммәтова А.М. Әгәр ул кайткан булса ........ 62
Нургалиева Г.Р. Җәйге сабак ........ 63
Нургалиева Х.Ә. Мәдхия ........ 63
Нургалиева Х.Ә. Ярлыкарга соңару ........ 64
Сафина А.К. Әнигә хат ........ 64

Сафиуллина Г.Ә. Кәрлә каен күз яше........................................................................ 665
Тимуршина И.К. Укытучыма ........................................................................................ 65
Тукманова М.Х. Гомернең чәчәге.................................................................................. 65
Тухватуллина Г.М. Әнием эндәшүе .............................................................................. 66
Фадеева Г.Х. Балачагымның бер көне........................................................................... 67
Ханнанова Ф.М. Кеше булып калыйк .......................................................................... 67
Хафизова И.М. Язмышың китабын актардым… ......................................................... 68
Хәйретдинова Р.Җ. Тау чишмәсе.................................................................................. 68
Хәмидуллина З.Я. Түбән Аты Шүрәлесе ..................................................................... 69
Хикматуллина Р.Ф. Көзләр күбрәк ошый миңа хәзер ................................................ 69
Хисамиева Р.Р. "Ана һәм мәңгелек солдат" ................................................................ 69
Шайдуллина Г.Х. Көнләшерлек итеп, яшәп кал! ......................................................... 70
Шафикова Г.Р. Урман әбие ........................................................................................... 70
Шәгәрәева А.И. Унбер бөркет....................................................................................... 71
Шәйхулова М.Ф. Китап ................................................................................................. 72